ЖИЗНЬ ЗАМЕЧАТЕЛЬНЫХ ЛЮДЕЙ
КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР



# ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША

УДК 821.161.1.09
ББК Ш33 (2=632.3)
Г130

**Шаукат Гадельша – певец родной земли, гордость татарского народа. Жизнь замечательных людей (Күренекле шәхесләр) / Составители: Алишина Х.Ч., Сибгатуллина М.Ш.; отв. ред. Х.Ч. Алишина. – Тюмень: типография «Печатник», 2019.– 184 с.**

**Книга издана при финансовой поддержке
Правительства Тюменской области и Тюменского регионального отделения Всероссийской политической партии «Единая Россия»**

Предлагаемое читателю издание продолжает серию книг «Күренекле шәхесләр» («Жизнь замечательных людей») о выдающихся личностях Тюменской области.

Специальный выпуск серии посвящен 70-летию со дня рождения нашего земляка, ныне проживающего в Казани, талантливого поэта Шауката Гадельшевича Сибгатуллина (лит. псевдоним Шаукат Гадельша).

Шаукат Гадельша – член Союза писателей Республики Татарстан с 1999 года, автор 9 сборников стихов: «Ярык мөгез» (1997), «Ядрә тигән» (1998), «Сөмән кадыйм» (2000), «Җилгә моң дыңгычлыйм» (2003), «Аучы җыры» (2004), «Чоңгыл» (2006), «Иман капка ачканда: шигырьләр» (2011), «Табигать баласы» (2014), «Себерем – үз җирем» (2019), лауреат премии Союза писателей Республики Татарстан имени Хади Такташа, награжден медалью в честь 1000-летия Казани.

Цель издания – познакомить читателей с творческой деятельностью выдающегося писателя современности, его трудами и литературой о нем.

В книгу вошли материалы о жизни и творчестве поэта, опубликованные в печатных средствах массовой информации, школьных и вузовских учебниках, литературных энциклопедиях, научных изданиях. Сборник включает работы, посвященные научному анализу произведений Шауката Гадельши и определению его места в татарской литературе.

Издание снабжено иллюстрациями, на которых отображены обложки всех изданий литературных трудов нашего замечательного земляка. Оно включает стихи, посвященные Шаукату Гадельше, а также стихи, написанные поэтом в честь друзей и земляков.

Адресуется широкому кругу читателей.

**Ответственный редактор**
Доктор филологических наук профессор **Х.Ч. Алишина**

**ISBN 978-5-4266-0172-7**

© Алишина Х.Ч.
© Тюменский государственный университет
© Типография «Печатник» (оформление)

# ПРЕДИСЛОВИЕ

Шаукат Гадельша является одним из ярких и своеобразных представителей татарской поэзии. В его лирике находят отражение фольклор, особенности быта сибирских татар, природа Сибири и актуальные проблемы современного общества. Для языка произведений Шауката Гадельши характерно использование индивидуальных авторских тропов, народность и богатство изобразительных средств.

Поэт Шаукат Гадельша внес определенную новизну в изображение родной природы, тесно увязав пейзажную лирику с философской. Образы птиц в стихотворениях Шауката Гадельши приобретают иной смысловой оттенок. Поэт расширяет возможности использования образов природы, наполняя их новым содержанием.

В образах животных в поэзии Ш.Гадельши воплощается идея материнства. Среди них в его поэзии особо выделяется образ оленя. Стихотворения Ш. Гадельши, где отражены образы животных, – это кодекс народной морали, например, он утверждает, что смерть каждого животного – это прекращение жизни вообще. В таких стихах поэта сквозным мотивом проходит тревога за лес, так как лес – это дом для всего живого. В стихотворениях «Сагая карт урман» («Остерегается старый лес»), «Электә бит, самолетлар очса…» («И раньше, когда пролетали самолеты»), «Урманнарга кабам» («Зажгу леса»), «Заман агачлары» («Современные деревья») и др. лес выступает как единое целое, а деревья, птицы, звери – его составляющие. Сожженный лес с животным миром для автора соотносим с погубленной жизнью. Таков основной мотив стихотворения «Поши аткач» («После охоты на лося»).

В стихах Шауката Гадельши, которые можно отнести к пейзажной лирике, скрыт философский смысл. Размышления о смысле жизни, думы о прошлом, сегодняшнем и будущем делают творчество поэта широкомасштабным, исполненным глубокого смысла. Стихотворения «Болан күзе» («Олений глаз»), «Болан баскан эзләргә» («На следы оленя»), «Кинәт кенә купты давыл» («Очень резко поднялся вихрь»), «Сорап куйгалый иде…» («Иногда спрашивал…»), «Күл йөрәге» («Сердце озера», «Карчык зары» («Жалоба старухи») являются отражением философских воззрений поэта о смысле жизни. Пустота и оглушающая Тишина в стихах Шауката Гадельши противопоставляются Жизни, Красоте, Надежде: даже смерть, по сравнению с этими понятиями, кажется естественнее.

Поэт Ш.Гадельша развил в современной татарской поэзии тему Сибири, которая раскрывается через ряд мотивов. Один из них – мотив охоты и охотника. В таких стихотворениях, как «Йөз яшьлек аучы» («Столетний охотник»), «Аучы зары» («Жалоба охотника»), «Аучы

җыры» («Песня охотника») перед читателем открывается необычный, экзотический мир леса, создается несколько чуждый для нашей поэзии образ охотника – защитника лесов и животного мира.

Живущий и работающий в Казани выходец из сибирских татар Шаукат Гадельша обращается своей поэзией к родным местам, родным людям. Его стихи сродни народным дастанам. В этой связи в стихах Ш. Гадельши заметное место занимают фольклорные образы сибирских татар. Помимо этого поэт, будучи носителем сибирско-татарской ментальности, анимизирует природу, что является одним из основных творческих приёмов его поэзии. В Казани вышли его поэтические сборники «Ярык мөгез» («Разбитый рог», 1997), «Ядрә тигән» («Попала дробь», 1998), «Сөмән кадыйм» («Рублю прорубь», 2000), «Җилгә моң дыңгычлыйм» («Конопачу ветер мелодией», 2003), «Аучы җыры» («Песня охотника», 2004), «Чоңгыл» («Водоворот», 2006).

О Шаукате Гадельше еще только начали говорить и писать литературные критики. Мы с великой благодарностью отмечаем весомый вклад в теорию татарского литературоведения, который внесла доктор филологических наук, профессор Казанского федерального университета, действительный член Академии наук РТ Дания Загидуллина. Но, насколько нам известно, все научные и научно-популярные статьи о Ш.Г. Сибгатуллине пока написаны на татарском языке, а литературная Россия ждет рецензий, выполненных и на русском языке. И замечательные его стихи еще не переведены на русский язык. В Сибирь творчество Шауката Гадельши пришло из Казани. На родине Гадельша стал известен благодаря публикации стихов в областной газете «Яңарыш», которой он регулярно оказывает меценатскую помощь. В Казань, где утвердиться в писательских кругах очень сложно, Шаукат Гадельша пришел из Сибири… Несмотря ни на что, талант проложил себе дорогу, о чем свидетельствует внимание профессоров Казанского университета и молодых исследователей с кафедры татарского языка, литературы и методик их преподавания Тобольского педагогического института (филиал ФГАОУ ВО «Тюменский государственный университет»)

В последние годы в ряды молодых ученых, успешно изучающих творчество поэта, органично вступила дочь поэта. Так, в 2014 г. по нашей просьбе Мадина Шавкатовна опубликовала великолепную статью «Шаукат Гадельша: о некоторых страницах жизни поэта»[1].

При подготовке к юбилею отца Мадина Шаукатовна обнаружила в архивах заметку Булата Сулейманова «Хәерле юл сиңа, якташ!», обнародованную 13 ноября 1969 г. в газете «Татарстан яшьләре». Совсем

[1] Сулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч.-практ. конф. «Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы /под общ. ред. Х.Ч. Алишиной/. Тюмень: Печатник, 2014.– 325 с.

юный, наивный, двадцатилетний паренек из таежной сибирской глубинки по имени Шаукат сумел оседлать Пегаса! А старший товарищ земляк Булат с восторгом приветствует его, радуется, что есть кому представить в Казани Сибирь, снимает перед ним шляпу: «Себер татарларыннан тагын бер яшь шагыйрь – Шәүкәт Сибгатуллин килеп чыкты. …Хәзерге көндә ул ерак Төньякта Салехард шәһәрендә яши. Үзенең әйтүе буенча, Шәукәт 1966 елны беренче тапкыр кулына каләм алган. Шәүкәтнең шигырьләренә, беренчедән, сабыйларча беркатлылык хас булса, икенчедән, образлы итеп әйтергә тырышу чагыла. «Татарстан яшьләре»нә Шәүкәт шигырьләр генә түгел, тагын алты дәфтәр кыска хикәяләр дә алып килгән. Шәүкәт русча да яза. Аның юморескаларын, кыска хикәяләрен, очеркларын Салехард шәһәрендә чыга торган округ газеталары яратып бастыралар. Мин Шәүкәтнең «Татарстан яшьләре»нә килгән шигырьләре һәм хикәяләре белән танышып чыктым. Алар мине куандырды. Безнең сафка Себер татарларыннан тагын бер яшь язучы килә. Хәерле юл сиңа, якташ!» В этих словах – весь Булат! Добрый и щедрый, великий и простой, искренний и светлый. Таким был и остается в памяти народа Булат Валикович Сулейманов! Именно таким является и его младший собрат по перу – Шаукат Гадельшович Сибгатуллин.

Шаукат Гадельша дружил не только с Булатом. Он обрел себе новых друзей среди видных членов Союза писателей РТ, талантливых поэтов и прозаиков, кандидатов и докторов наук, лучших специалистов- литературоведов Татарстана. Высокую оценку поэтическому дару Гадельши дают Газинур Муратов, Галимзян Гильманов, Госман Садэ (Зайнетдинов), Мударрис Аглямов, Нияз Акмал, Рабит Батулла, Радиф Гаташ, Рашат Низами, Рифа Харрасова, Ркаил Зайдулла, Роберт Ахметзян, Роберт Миннуллин, академик АН РТ Загидуллина Д.Ф., профессор КФУ Сайфулина Ф.С., доцент ТГПИ Фаизова Л.Х., многие другие, в том числе земляки, члены кружка “Әдәби Төмән” при газете “Яңарыш” Тюменской области. Научные статьи, обстоятельные рецензии и отзывы, материалы, собранные в книге под названием “Жизнь замечательных людей. Шаукат Гадельша”, рождают в душе чувство гордости, невольно подводят к мысли: “Этот человек достоин премии имени Габдуллы Тукая”.

***Алишина Ханиса Чавдатовна,***
*доктор филологических наук, директор Центра тюркологии, профессор кафедры общего языкознания института социально-гуманитарных наук Тюменского государственного университета, член Российского комитета тюркологов, член Союза писателей Республики Татарстан, член Союза журналистов Российской Федерации, почетный член Академии наук Республики Татарстан, заслуженный учитель школы РТ, почетный работник высшего профессионального образования РФ*

## БИОГРАФИЯ

Поэт Шаукат Гадельша (Сибгатуллин Шаукат Гадельшович) родился 16 сентября 1949 г. в деревне Киндер Нижнетавдинского района Тюменской области.

Дед поэта Сибгатуллин Гишам Сибгатуллович (1877–1937) – мулла в четвертом поколении, в 1912 году переселился из Тетюшского уезда Казанской губернии в деревню Ново-Булгары Нижнетавдинской волости Тобольской губернии. В Ново-Булгарах служил муллой, управлял кожевенной мастерской, владел стадами овец, лошадей, другого скота и хорошим домом. В 1937 г. Гишам Сибгатуллович был раскулачен, репрессирован и расстрелян. Реабилитирован в 1989 году. В период реабилитации внук одного из репрессированных Хатыф Шамсутдинов на собственные средства разбил в деревне Киндер парк памяти жертв политических репрессий, в котором установлен обелиск с фамилиями всех репрессированных жителей деревни Киндер, в том числе деда поэта.

Отец поэта Сибгатуллин Гадельша Гишамович (1918–1987) – участник Великой Отечественной войны, служил санитаром, переводчиком немецкого языка. Гадельша Гишамович за боевые заслуги был награжден медалями Великой Отечественной Войны, в том числе Орденом Великой Отечественной войны II степени. После Великой Отечественной Войны отец поэта был участником советско-японской войны. Вернувшись в 1948 году в Тюменскую область, обосновался в д. Киндер, работал пастухом, сторожем на ферме. Отец поэта владел арабским, немецким, чувашским, татарским языками, стремился получить образование и профессию, но, будучи сыном репрессированного муллы, сталкивался с враждебным отношением и препятствиями со стороны представителей власти, в том числе в вопросах образования, поэтому получить образование и профессию не смог.

Мать поэта Фархия Алимовна (1924–2009) – сирота, инвалид детства по зрению, домохозяйка.

У поэта 4 брата – Аухат (1951–2006), Нурислам (1959–2008), Ильгизар (1964–2007), Саетгали (1955 г.р.) и сестра Гульчихан (1961 г.р.). Брат Саетгали проживает в д. Сетово Тобольского района Тюменской области, а сестра Гульчихан – в с. Вознесенка Венгеровского района Новосибирской области.

Детство поэта проходило в тяжелых условиях. Семья поэта жила в однокомнатной избе очень бедно. По воспоминаниям поэта, для того, чтобы пойти в первый класс не босым, он все лето на свалках искал себе обувь и пошел в школу в разных по цвету и размеру, собственноручно заштопанных сандалиях. Из-за отсутствия теплой одежды в пер-

вом классе поэт часто пропускал занятия в школе, поэтому был оставлен на второй год. Поэту часто приходилось ходить в школу и вовсе босым. Учился хорошо, по отдельным предметам на «отлично». Поэт с детства тянулся к знаниям, любил подолгу читать и чаще всего читать приходилось по ночам при свете луны из-за отсутствия в доме свечей. Рано проявились способности к математике. Поэт с легкостью решал примеры из школьной программы и дополнительные задачи по математике. И старшеклассники, и одноклассники и даже учителя обращались к нему за консультациями по математике. Он всегда был отзывчивым и дружелюбным, никогда не отказывал в помощи. Дом поэта был всегда полон занимающихся математикой детей.

Шаукат Гадельша первые стихи начинает писать в возрасте 12 лет. Его первые опубликованные работы – заметки в газете «Яшь ленинчы (Юный ленинец)».

Окончив в 1965 г. восемь классов, поэт поступает в сельское профессионально-техническое училище № 7 г. Ялуторовска Тюменской области на специальность «Электромонтер». Завершив обучение в училище, устраивается работать в колхоз в Нижнетавдинском районе. В 1968 г. поэт переезжает в г. Салехард и работает на рыбоконсервном заводе в должности электромонтера.

В 1969 г. Шаукат Гадельша во время отпуска в первый раз приехал в город Казань и познакомился со своим земляком – основоположником сибирско-татарской литературы, первым профессиональным поэтом Тюменской области Булатом Сулеймановым, который позднее во время приезда в Казань всегда старался встретиться с Шаукатом Гадельшой.

Первые стихи поэта были опубликованы в 1969 г. в газете «Татарстан яшьләре». В 1969–1971 гг. Шаукат Гадельша активно участвует в работе литературного объединения молодых русских писателей «Северное сияние» в г. Салехард. Русские поэты переводят его подстрочники. В 1970 г. поэт отправляет свои подстрочники на конкурс в Институт литературы им. М. Горького и становится его победителем – ему предлагают поступить в институт без экзаменов. Но поэт не смог воспользоваться данным предложением из-за отсутствия на тот момент полного среднего образования.

В 1971 году Шаукат Гадельша приезжает в Татарстан на строительство КамАЗа и за один год учебы оканчивает 9 и 10 классы в вечерней школе рабочей молодежи. В Набережных Челнах он знакомится с Мударисом Аглямовым, Равилем Файзуллиным и другими татарскими писателями и поэтами. В это же время становится одним из организаторов и активным членом литературного объединения «Лейсан».

В 1973 г. Союз писателей Республики Татарстан направляет поэта на учебу в Казанский государственный университет на отделение татарской филологии. В университетские годы поэт знакомится с Газинуром Муратовым, Мухамметом Магдеевым, Галимжаном Гильмановым, Робертом Миннулинным, Лябибом Лероном, Хайдаром Гайнутдиновым, Рафисом Курбановым, Ркаилом Зайдуллиным, Джавдетом Сулеймановым, Мударисом Валеевым, Хатипом Миннегуловым, Робертом Ахметзяновым, Разилем Валеевым и другими писателями, поэтами и публицистами. Во время учебы в университете вместе с Мударисом Валеевым руководит студенческим литературным объединением «Әллүки».

В 1977 г. поэт возвращается на родину в Тюменскую область, работает в совхозе «Новоникольский» в должности главного энергетика, секретаря партийной организации. До сих пор односельчане помнят и любят с гордостью, большим уважением рассказывать, как он, молодой электромонтер, мельком взглянув на схемы, в которых с трудом разбирались инженеры, запускал новые элеваторы и АВМ (агрегаты витаминизированной муки).

В 1981 г. снова вернувшись в Казань, Шаукат Гадельша работает литературным сотрудником в «Блокноте агитатора». С 1982 г. с появлением семьи в жизни поэта установилась стабильность. Поэт завершает обучение в университете. С 1983 г. работает в должности прораба, затем старшего прораба и начальника участка в строительном управлении. Из-за частой перемены мест жительства и работы поэт потерял порядка 200 своих стихотворений, поэтому свои книги он выпускает намного позже, чем мог бы. Первый сборник стихов «Ярык мөгез» («Разбитые рога») выходит в свет только в 1997 г.. Его стихи публикуют в казанских газетах «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», тюменской областной газете «Яңарыш», журналах «Идель», «Казан утлары».

Благодаря своему таланту, профессиональному мастерству, высокой трудоспособности и организаторским качествам поэт в 1998 г. организует свое электромонтажное предприятие – ООО «Арекс». В сложные постперестроечные годы многие потерявшие работу специалисты нашли в его фирме достойную зарплату, смогли содержать семьи. Под его руководством электрифицировались многие промышленные и жилые объекты Казани и ее пригородов. В Татарстане он является одним из лучших специалистов по электрификации гражданского и промышленного строительства.

Шауката Гадельшу знают не только как грамотного специалиста и талантливого поэта, но и как доброжелательного и отзывчивого человека, готового всегда прийти на помощь друзьям, коллегам, односель-

чанам. Поэт занимался благотворительностью, оказывал материальную помощь мечетям как в родной деревне, так и в Татарстане, церквям в Санкт-Петербурге, Нижнем Новгороде, Киеве, журналам, газетам и другим организациям.

На протяжении всей жизни кроме литературного творчества поэт увлечённо занимался общественной деятельностью. Как было упомянуто выше, в разные годы поэт был активным членом различных литературных объединений, с 1971 г. был членом КПСС, с 1988 г. – членом профсоюза работников строительства и промстройматериалов, в 1995 г. был выдвинут кандидатом в народные депутаты Вахитовского районного Совета народных депутатов Республики Татарстан, с 2001 г. – членом Всероссийского общества автомобилистов, с 16 лет – членом различных охотничье-рыболовных обществ, в том числе с 2004 – охотничье-рыболовного общества Республики Татарстан при ОГО ФСО «Динамо».

В свободное время поэт увлекался садоводством, рыбалкой, охотой, сбором грибов, изучением флоры Республики Татарстан.

В 2009 г. Шаукат Гадельша перенес инсульт. После этого поэт перестает читать литературу и писать стихи. В трудное время поэта морально поддерживали земляки – д.ф.н., профессор ТюмГУ Алишина Ханиса Чавдатовна, редактор газеты «Яңарыш» Сагитова Алсу с коллективом газеты, журналист Диляфруз Фахретдинова, д.ф.н., профессор КФУ Хатип Миннегулов, казанские писатели Рафис Корбан, Газинур Морат, Ркаил Зайдулла, Лябиб Лерон и многие другие.

В 2016 г. поэт перенес второй инсульт. Здоровье Шауката Гадельши после реанимации, длительных курсов лечения, реабилитации, поддержки семьи и друзей стабилизировалось. Поэт после семилетнего перерыва вновь начинает писать стихи с новыми чувствами, эмоциями и восприятием мира.

В настоящее время творчество поэта изучается в школах и высших учебных заведениях – Тюменском государственном университете, Тобольском педагогическом институте им. Д.И.Менделеева, Казанском (Приволжском) федеральном университете. Сведения о биографии и творчестве поэта включены в учебные пособия, энциклопедии, справочники и образовательные программы. Творчество Шауката Гадельши привлекает к себе внимание лингвистов и литературоведов. Изучается язык его произведений, устанавливаются характерные для его творчества закономерности словоупотребления, основные темы и мотивы творчества. По творчеству защищены две кандидатские и одна докторская диссертации.

Шаукат Гадельша – член Союза писателей Республики Татарстан с 1999 г., автор 9 сборников стихов: «Ярык мөгез» (1997), «Ядрә

тигән» (1998), «Сөмән кадыйм» (2000), «Җилгә моң дыңгычлыйм» (2003), «Аучы җыры» (2004), «Чоңгыл» (2006), «Иман капка ачканда: шигырьләр» (2011), «Табигать баласы» (2014), «Себерем – үз җирем» (2019), лауреат премии Союза писателей Республики Татарстан имени Хади Такташа, награжден медалью в честь 1000-летия Казани.

В настоящее время проживает в Казани. В 2019 г. отмечает 70-летие. Несмотря на состояние здоровья, активно пишет стихи.

***Мадина Сибгатуллина***

## О СЕБЕ

(Үзем турында үзем)[2]

Ул чакта каеннар безнең авылга биектән аккан текә яшел шарлама булып ябырылалар иде. Тавыкларның иң яратып күкәй сала торган урыннары бакча башларына сыенган куе куаклар булды. Менә мин шундый мул тәбигатьле авылда иң ярлы гаиләдә ачлы-туклы, иске-москы киеп үстем. Кармак таягы күтәреп торырлык хәлгә җиткәч балык тотарга йөрдем. Аякларым кар ерырлык күтәрелгәч, куянга, кыр тавыкларына тозаклар кора башладым. Барганда – кайтканда хыялга, уйга чума идем. Нигә минем кием иске, итек тишек? Бер штан киеп йоклыйм, шуның белән мәктәпкә барам, урамда уйныйм. Өебез бик кечкенә. Ашаганыбыз бәрәңге, ул да бетеп куя. Әти дә, әни дә – кызганыч. Әти – рухы сынган кеше иде. Бабайны совет власте атып үтергән.

Болыннарда, елга буйларында, урманда ялгызым йөри торгач, минем тамакка моңнармы, аһәңме тыгыла башлады. Алар тышка бәреп чыктылар. Мин сузып сузып кычкырам, көйләп җырлап җибәрәм. Җанга рәхәт: очынып куям, я исерткеч кайнарлыкта йөзәм.

Бер көн кичен гөмбә җыярга яраткан күрше абый безгә керде.

– Шәүкәт, урманда яныңа килергә курыктык. Яшелле-мөшелле тавышлар чыгарыпуладыңмы, шыңшыдыңмы, еладыңмы син?

– Җырладым, – дидем мин, оялып.

– Җырларның сүзләре була бит.

Шуннан соң сүзләр белән нәрсә күрсәм шуны җырлый башладым. Күбрәк агачларга, үләннәргә, кошларга эндәшеп җырлыйм.

Онытылмаган шул чактагы җырларымның менә берсе:

*И каен, зифа каен,*
*Чыбыгыңнан күп кайгым.*
*Ник мин ач, ник ярлы мин,*
*Һаман, һаман да саен?*

Мин урманнан кайтканда капка төбебездә гөмбәче күрше абый тора:

– Ну, җырладын! Гөмбә җыеп йөргән хатыннар сине тыңлап еладылар. Синнән шагыйрь-җырчы мазармы чыгачак.

Шәүкәт Гаделша, 2007

[2] Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Дүртенче китап = Писатели нашего детства: Библиографический справочник. Книга четвертая. – Казан: Мәгариф, 2008.– 255 б.

## МАТЕРИАЛЫ О ТВОРЧЕСТВЕ ПОЭТА, ОПУБЛИКОВАННЫЕ В ПЕРИОДИЧЕСКОЙ ПЕЧАТИ И КНИГАХ

### Булат Сөләйманов

### ХӘЕРЛЕ ЮЛ СИҢА, ЯКТАШ![3]

Моңа кадәр Себер татарларының үз язучылары булмады. 1997 елда Тоболда татар телендә «Ленин юлы» исемле район газетасы каршында 30 дан артык яшь автор үсеп килә иде. Ләкин алар арасыннан бер мин генә Татарстан күләменә чыга алдым. Ә калганнарының ни сәбәптәндер тавышлары ишетелми башлады.

Һәм менә кетмәгәндә Себер татарларыннан тагын бер яшь шагыйрь – Шәүкәт Сибгатуллин килеп чыкты. Шәүкәт Төмән өлкәсе, Түбән Тауда районы, Киндерле авылында 1949 елда туган. 1968 елда Ялуторовский шәһәрендә электромонтерлар әзерләү курсын тәмамлаган. Хәзерге көндә ул ерак Төньякта Салехард шәһәрендә яши. Үзенең әйтүе буенча, Шәукәт 1966 елны беренче тапкыр кулына каләм алган. Шәүкәтнең шигырьләренә, беренчедән, сабыйларча беркатлылык хас булса, икенчедән, образлы итеп әйтергә тырышу чагыла. «Татарстан яшьләре»нә Шәүкәт шигырьләр генә түгел, тагын алты дәфтәр кыска хикәяләр дә алып килгән. Шәүкәт русча да яза. Аның юморескаларын, кыска хикәяләрен, очеркларын Салехард шәһәрендә чыга торган округ газеталары яратып бастыралар.

Мин Шәүкәтнең «Татарстан яшьләре»нә килгән шигырьләре һәм хикәяләре белән танышып чыктым. Алар мине куандырды. Безнең сафка Себер татарларыннан тагын бер яшь язучы килә.

Хәерле юл сиңа, якташ!

**Галимҗан Гыйльманов,**

татар язучысы, шагыйре, драматургы һәм әдәбият белгече,
Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

### ШАГЫЙРЬНЕҢ УРМАНЫ[4]

Себерне татар кешесе элек-электән нindiдер бер шомлылык һәм серлелек белән, шул ук вакытта иң тирән геннарында, ягъни җан һәм

[3] Булат Сөләйманов. Хәерле юл сиңа, якташ! // Татарстан яшьләре.– 1969.– № 136 (5134), 13 ноябрь. – Б. 4.

[4] Гыйльманов Г. Шагыйрьнең урманы // Ярык мөгез. – Казан: Татар кит. нәшр., 1997. – Б. 3–10.

тән күзәнәкләрендә оеп яткан яшерен тартылу хисе белән кабул итә. Борынгы Кучум хан заманнарын сагыну да бар бу хистә, шулай ук 30 елларда сөрелгән меңнәрчә татарларның канлы күз яшьләре катыш рәнҗешләре, каргышлары да төшеп калган аңа.

Шәүкәт Гаделша да Себердән. Аның шигъри җаны да шушы ике капма-каршы хистән укмашып яралган: атасы ягыннан бабасы сөрелгән Казан татары булса, анасы ягыннан бабасы борынгы Себер ханнары нәселеннән яралгы алган. Шагыйрь үз нәселенең, тарихын «Сазлык» шигырендә ачкан да биргән:

*Мулла бабам куылганда*
*Алтынын күмгән имеш,*
*Чалдан бабам ачтан үлгән,*
*Камыш чәйнәгән килеш…*

Рәсәй Себере шушы ике татар кешесенең язмышын бер төенчеккә бәйләп сазлыкка батырган. Ул әле дә, аларның оныкларын йотам дип, туймас авызын ачып тора…

Шагыйрьне мин бик күптәннән беләм. Казан дәүләт университетының татар бүлеге каршында оешкан «Әллуки» әдәби берләшмәсенең 70 нче еллардагы старостасы иде Шәүкәт. Ул чакта «Әллуки»гә йөргән дистәләгән каләм әһеле бүгенге көндә билгеле генә язучы шагыйрь, әдәбиятчы булып җитеште, кайберләре Язучылар Берлегенә алынды, хәтта берничә китап бастырып өлгерде. «Әдәби түгәрәкнең башында торучы Шәүкәт кая булды соң?» – дип сорарсыз. Югыйсә әдәбият мәйданында Роберт Миңнуллиннар, Фәннур Сафиннар белән бер чордарак пәйда булырга тиешле калам иясе иде ул. Менә хикмәт: иң өметлеләрдән саналган бу исем 80 елларда матбугат битләрендә күренмәс булды, басмага әзерләнгән шигъри җыентыгы да дөнья күра алмады…

Шәүкәт туган җиренә – Төмән якларына, Тобол буйларына кайтып киткән икән. Хикмәтле хәлләр моның белән генә бетми әле. Шагыйрьнең, җаны Казаннан Себергә дип чыгып киткән китүен, әмма Тобол буйларына кайтып җитә алмаган. Дөресрәге, аның тәне кайткан, әмма асылы, җаны Казан белән Себер арасында бәргәләнеп йөрүендә булган. Соңыннан шагыйрь бу халәтен шигырь итеп яза:

*Пышылдый Себердә*
*Бүрән күл камышы:*
*– Ашыктың, ашыктың…*
*Пышылдый Казанда*
*Кабан күл камышы:*
*– Ялгыштың, ялгыштың…*

*Ишетәм төннәрен,*
*Бергә кушам да*
*Бу ике тавышны:*
*– Ашыктың, ялгыштың,*
*Уйный качышлы*
*Язмышың, язмышың…*

Икенче бер шигырендә шагыйрь: «Язмышымның дәрьясы – Казан, Төмән арасы», – дип белдерә. Читтә туган һәр татар кешесе кебек, Шәүкәт тә күңеле белән олы драма кичерә. Тарихыннан төп-тамыры белән өзеп алганнар аны, ә киләчәген… бирмәгәннәр…

*Кайсы якта черегән*
*Ыруымның казыгы?*
*Яшьнең иң гөнаһсызын*
*Кайсы якка агызыйм?..*

*…Казан, Төмән арасы –*
*Мәгънәм минем, канатым.*
*…Эх, үлеп булса икән,*
*Бар буена капланып!*

Үзе Себердә, туган төбәгендә яшәсә дә, шагыйрь Себерне аңлап бетерә алмый. Әллә аның үзен аңламыйлармы? Танымаслык булып асылын үзгәрткәнме әллә ул? Драма дәвам итә:

*Яшьле керфегемә кунды*
*Хәлсез күбәләк.*
*Әйтерсең лә, үзем түгел, –*
*Кайткан күләгәм,–*
*дип ачыргалана ул.*

Мондый халәттә шагыйрь озак яши алмый, әлбәттә. Дуамал күңеленә, яшьлек хыялларына ихтыярый буйсынып, Шәүкәт кабат Казанга юл ала. Татарның төп мәркәзенә кайтып, кеше күзенә күренеп-беленеп тормаган гади генә хезмәткә урнаша – төзелештә электрик булып эшли башлый. Филолог-әдәбиятчы белгечлеге буенча университет тәмамлаган шагыйрь кыска гына вакыт эчендә мастер, прораб хезмәтенә куела, бугенге көндә ул төзелеш трестының участок башлыгы вазифасын башкара.

Әмма, Казанга кайткан Шәүкәт бу юлы җан тынычлыгы тапкандыр, дисәк, нык ялгышырбыз. Хикмәтле хәлләр дәвам итә: ул үз җанын әле иҗтимагый хәрәкәт эченә ташлый, әле бөтен барлыгы, асылы белән табигать, урман, аучылык стихиясенә бирелә…

Күптән түгел генә Табигатьнең күзеннән сикереп төшеп, Казанына кайткан шагыйрьнен, җаны кабат бабалары җиренә омтыла, сагышлана, хәсрәтләнә, тыпырчына:

*Бик зур шәһәр, төн уртасы.*
*Күктә ярым ай.*
*Берешкән, хәер сораучы*
*Хәлсез сабыйдай…*

Бердәнбер юаныч: эт улавы… Борынгылар эт улавын иминлеккә, изгелеккә, нәсел дәвамына юраганнар. Шагыйрь шуны тойган:

*Бик якын, күңелгә якын*
*Этнең улавы…*
*Кыргыйларча моңланумы,*
*Әллә елаумы?*

Ниһаять, авторның җанын борчып торган сәбәп аңлашыла башлый. Әйе, ул һаман үз урынын таба алмаган, үз асылына төшенмәгән хәлдә, үз максат-хыялларын ачыкламаган килеш яши икән әле… Һаман шул ук хәл: яшәешнең тарихка киткән очы да, киләчәккә алып барганы да анык түгел. Эт улавы аша шул аңлашыла булса кирәк:

*Ерак китеп яңгырый ул,*
*Сагаеп калам;*
*Ай артында елый ахры*
*Борынгы бабам…*

Шагыйрьнең мондый киеренке халәте «Көзнең киеренке минутлары» дигән шигырьдә аеруча гыйбрәтле чагылыш тапкан:

*Йөгереп кенә китәр идем лә мин,*
*Кузгалырга нидер җитеп бетми;*
*Әллә Казан тәмам торткын итте,*
*Әллә Себерем онытты инде?..*

Бүген дә менә шулай ике ут арасында яшәп ята шагыйрь. Нәкъ менә шушы язмышы белән Шәүкәт безнең буын шагыйрьләренең берсенә дә охшамаган. Ул бөтен барлыгы, асылы белән үзенчә, Шәүкәтчә. Бер караганда аңарда чын табигатьтән иңгән самимилек, беркатлылык шаккаттырса, икенче караганда шул ук табигать кануннарына таянып чыгарган гомумиләштерүләре, фәлсәфи фикере әсир итә. Әлбәттә, аның әхлакый сурәтенә табигатьтән иңгән тагын бер сыйфатны ягарга тиешбез: ул безнең, чорга ят дәрәҗәдә гадел зат. Исеме дә аның – Гаделша бит. Бу исемне ул Себергә икенче кайтуында әтисенең истәлеге итеп алган. Чынлап та, шактый үзгәреп, акыл җыеп кайта ул бу юлы. Баеп кайта. Күңелен тутырып кайта. Шуңа күрәме, бик тиз генә ачылып китә алмый. Минемчә, ул бермәлгә моң-сагышына тыгылып кала, хис-тойгыларының йомгак очын таба алмый интегә… Урман елгасы кебек. Нәни генә чишмәдән башланган урман инеше дә бик авырлык белән юл эзли, әмма, бер көч алгач инде, туктатам димә! Шәүкәт белән дә шулай:

70 нче еллардан башланып киткән кечкенә инеш бүген егәрле, көчле агымлы урман елгасына әверелгән.

Әйе, Шәүкәт Гаделшаның иҗатын бары тик Себер урманнары белән генә тиңләргә мөмкиндер: моңлы да ул, шомлы да, горур да. Нәрсә булмас тайга урманында?!

Әнә – аның күлендә бер пар үрдәк йөзеп йөри: «Мин үстердем бер үрдәк, Син үстердең бер үрдәк… »

Шулай гади генә башланган мәхәббәт шигырендә борынгы-лыктан килүче образ-символ яңара: *үрдәк* – төркиләрнең нәселыру фалы, җир дөньясын яраткан изге җан иясе бит…

Әнә – бер үгез болан чабып үтте… *Үгез болан* – Себер, Урал төркиләре өчен шулай ук дөньяви символ. Бер риваять искә төшә: Кояшны иртән Үгез Болан үз мөгезләрендә күтәреп менгерә, кичен шул мөгезендә алып төшә, имеш… Шәүкәт урманындагы бу боланның мөгезе зәгыйфьләнгән, ярык! Ул ярыкта җил уйный, җитмәсә, ана боланның чакыру авазына охшап сызгыра… Үз мөгезендәге сызгыруга алданып чабучы үгез болан үлемгә дучар ителгән. Буш сызгыру – буш нәсел…

Шагыйрьнең әйтергә теләгәне кисәтү булып яңгырый: без әнә шул үгез хәлендә түгелме, ярык мөгез тавышына алданып яшәмибезме?

Шәүкәт Гаделша иҗатында очраклы образ юк. Менә *куян.* Шулай ук кояш, яктылык, нур, димәк, яшәү символы.

*Урман шәрә, җил туңдыра,*
*Кеттерә кары.*
*Куянның тун алыштырып*
*Алданган чагы,–*

дип башланган гади генә шигырь укучыны тирән гомумиләште-рүләргә алып китә, зиһенне киеренке бер хәлгә китерә:

*Үзем ак ниятләр булып,*
*Шартларга торам.*
*Заман гына кара төстә,*
*Шуңардан куркам.*
*Мин кемең, дип,*
*Халкым, ничә*
*Уйланып торам;*
*Ашыгып тун алыштырган*
*Куяның булам…*

Бу юлларны укыгач, уйламас җиреңнән бүгенге хәлебез хакында да, мөстәкыйльлегебез турында да уйланып куясың…

Әнә – йөз яшьлек аучы йөри урманда. Кеше тарафыннан таланган, җәрәхәтләнгән меңьяшәр урман йөз яшьлек аучы карттан да алдарак җан биреп ята…

Әнә – сабыен ияртkән ана болан. Күзләрендә дөнья: ак болыт, кояш, үлән, чишмә, чык бөртеге… Тукта! Ә монысы – мылтык тавышы. Үлгән сабые янында басып торган боланның күзләрендә нәрсә бар дип сорыйсызмы? «Дөньябызны йотарлык бушлык!» – ди шагыйрь.

Бүген Урман (Яшәеш) куркыныч хәлдә. Шагыйрь әсәрдән-әсәргә, юлдан-юлга шушы уйдан котыла алмый бара.

*Реактивлар үкереп керә хәзер*
*Туган ягым күгенә…*
*Урманнарым җанын биреп яткан*
*Сугым кебек тибенә…*

Шагыйрьнең үзенең дә урман белән мөнәсәбәтләре катлаулы. Урманын сөйгән аучы кебегрәк. Бер караганда, ул – бу урманның бер күзәнәге кебек, аңа керешеп, берегеп яши. Бу бигрәк тә аның «Сердәшләр булганга…» дигән шигырендә ачык чагыла:

*Өертэ, йөгертә*
*Үзенең зур йөген.*
*Белмәссең, кырмыска –*
*Яшьлегемдер минем!..*

Икенче караганда, ул урман белән аңлаша алмый интегә. «Карурманда» шигырендә ул аеруча нык өзгәләнә: «Җанына тынычлык эзләп («Хәятым җене») урманга килгәч, табалмый китә ул…

*Кайда син, кайда,*
*Хәятым җене?*
*Килгән идем бит*
*Күрим дип сине?..*

Уйнарга, җилләрне җыеп бәйрәм итәргә чакыра, «кузгатыйк бәхәс яшәү хакында», ди. Ләкин «Хәят җене» юк та юк…

*Әллә качтың син,*
*Куркып заманнан?*
*Ахры, сине дә*
*Заман алдаган…*

Заман белән Язмыш бәхәсенә килеп чыга шагыйрь: «Бу – Язмышныц Заман белән йөз тырнашкан мизгелләре…» («Ачу чыкты»). Әлеге бәхәс шагыйрь өчен бик авыр бирелә. Чөнки ул – урман җанлы, табигать җанлы зат, димәк, мәҗүси рухияткә ия кеше. Шуңа күрә заманга ул бик сак, хәтта шомланыбрак карый:

*Тонык кына яңгырый азан:*
*«Яңа заман, яңа заман!»*
*Ә мин, бүре баласыдай,*
*Карурманга карыйм һаман…*

Шул рәвешле, Шәүкәт Гаделша иҗаты нигезендә даими киеренкелек сиземләнә. Шагыйрь табигатьне яклап чаң суга, баш күтәрә, эмма, шул ук вакытта, үзенең чын табигатьтән шактый ерак киткәнен дә яхшы аңлый…

Укучыга Шәүкәт Гаделшаның шигъри җыентыгын тәкъдим итәр алдыннан тагын ике үзенчәлек хакында әйтеп китмәкче булам. Бу китапта очраган образ-сурәтләр, поэтик детальләр беркемне дә кабатламый, хәтта, бүгенге укучы өчен күпмедер дәрәҗәдә чит-ят тоелырга мөмкин. Шагыйрь үзенә генә хас шигъри дөнья тудыра алган. Дөресрәге, ул борынгы бабаларыбыз мирасыннан, хәтта мәҗүсилек, ыруглык тәгълиматыннан килүче образ-сурәтләргә заманча мәгънә, фикер салып эш итә белә. Аерым очракта ул Үрдәк, Кыр казы, Торна, Болан, Аю, Поши, Эт, Бүре, Куян, Әтәч тотемнарының борынгы мәгънәләрен искә төшерә, урман белән бәйле мәҗүси ышануларны яңарта, яисэ шул ук Урман, Җил, Күк, Су дөньясы белән бәйле илаһи рухларга мөрәҗәгать итә, өченче бер очракта борыңгы мифларның төп сюжетларын яңарта. Бер генә мисал. Шәүкәт Гаделша, Җир астына – Караңгы Дөньяга төшә торган мифик кое хакындагы риваятьне китереп, бүгенге заманның образлы портретын тудырырга омтыла:

*Әйтерсең лә, төпсез кое –*
*Йотты мине төшенкелек…*
*(«Рухыма»)*

*– Кое диимме,*
*Әллә яшел төн?*
*(«Кар урманда»)*

*Эзләттерә җир тишеген,*
*Елата ул шайтаннарны.*
*(«Ачу чыкты»)*

Шагыйрь ышана: бу коедан чыгарга мөмкин әле. Бөтен өмет милли рухта, фидакарь йөрәктә, дөресрәге, рухи ныклыкта. Автор үз Рухына болай дип эндәшә:

*Инде Сәмруг кошы бул да*
*Югарыга күтәр мине.*
*Менгән чакта хәлең бетсә,*
*Ашатырмын йөрәгемне…*

Ниндидер бер мәлдә шагыйрь чын шаманга әверелеп китә. Әле ул елан кабыгының көле белән «сихерләнә», әле «кәлтә сихере»нә тап була… Мондый магик йола бөртекләре шулай ук җыентыкның мәгънәви егәрлеген арттыралар, милли колоритып көчәйтәләр.

Тагын бер үзенчәлек: Шәүкәт Гаделшаның күп әсәрләре борыңгы халык дастаннары үлчәмендә иҗат ителгән. Бу үзенчәлекнең дә бүгенге Татар Шигърияте портретына матур бизәк булып ягылачагына шик юк.

Кыскасы, укучы кулында – соңгы елларда нәшер ителгән шигырь җыентыкларының иң кызыклысы. Аны Себер татары Шәүкәт Гаделша иҗат иткән. Ягъни, үз милләттәшебез, үз кардәшебез һәм рухташыбыз.

**Галимҗан Гыйльманов**

татар язучысы, шагыйре, драматургы һәм әдәбият белгече,
Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## КӨЙГӘ КАЙТУ[5]

Газинур Моратов Шәүкәт Гаделшаның иҗатына багышлап язган шигырен «Көй чакыру» дип атаган. Шагыйрь шагыйрьне тоя шул. Әйе, шагыйрәнә күңел сизгерлеге белән Газинур Шәүкәт иҗатының мөһим бер үзенчәлеген ачып бирә алган:

*Кошлар эзен укый күктән,*
*Укый үлән ымын да.*
*Бер мәҗүси шаман сыман,*
*Көй чакыра ырымлап…*

Чынлап та, Шәүкәт шигырьләрен көйсез-аһәнсез укып булмый кебек. Текстка күз салу белән тамак төбендә ниндидер бер төен

[5] Гыйльманов Г. Көйгә кайту // Ядрә тигән. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1998. – Б. 73–76.

хәрәкәткә килә һәм, билгеле бер ритмга төшеп, борынгы шаманчылык дәверләреннән калган магик көй-аһәңне суза баш-лый…

*Дә-ә-һшәтле-е чытырда-а-п…*
*У-у-ча-а-к талпына-а-а…*
*Я-ә-шь себе-е-р татары-ы-ы…*
*Я-а-та-а янында-а-а…*

Бу очракта шигырьдәге һәр авазның сыйфаты үзгәрә. Әһәмияте арта. Мәгънәсе гадәти сөйләмдә генә биреп булмый торган төсмерләргә байый. Бигрәк та сузык авазлар нык үзгәрә – аларның яңгырашына тартык авазлар аһәңе килеп кушыла: «а» авазы «а-гъ» яисә «гъ-а» булып, «ы» авазы «ы-гь» яисә «гъ-ы» булып ишетелә. Тартык авазлар, киресенчә, ниндидер интонация-аһәнгә буйсынып, сузыла, «көйләнә» башлыйлар: «р-р-р», «н-н-н» һ. б.

Көйләп укыла торган әсәрләрдә шигырь юллары күпчелек очракта сузык авазларга тәмамланалар. Инде тартыкка тәмамланган очракта да авазлар сузылыбрак бетәләр. Менә Шәүкәтнең «Күл йөрәге» дигән шигыре:

*Бителем тулы*
*Табан балык…*

Ә беләсезме, Себер татары бу юлларны бөтенләй башкача укый, дөресрәге, көйли: «Бителем-м-м тулы-ы-ы табан-н-н ба-лыгъ-гъ-гъ…»

Әлбәттә, мондый көйле шигырьләрне «дастан шигыре» үлчәмендә язу кулайрак. Тын-сулыш, аһәң, көй шуны таләп итә. Шаукәт Гаделша иҗатында да, язма әдәбият традицияләре белән янәшә, халык авыз иҗаты традицияләре көчле агым булып бара. Күп очракларда соңгысы өстенлек тә алып китә әле:

*Җил учакны йөземә*
*Капларга ниятли.*
*Нарат мине күтәреп*
*Атарга ниятли…*
*(«Йолдызга менимме?»)*

Сүз дә юк, шигыренең мондый хасиятен шагыйрь үзе дә белә. Ул хәтта, аерым очракларда, кайбер шигырьләренә «Тамак төбе белән җырлана» дигән искәрмә дә бирә. Мәсәлән, «Нигә аттым?» исемле шигыренә ул шундыйрак искәрма биргән. Шуннан бер өзек:

*Нидер җитми*
*Минем җанга,*
*Төбәп аттым*
*Ак томанга…*

Сиздегезме, укый барган саен тавыш-аһәп үзеннән-үзе тамак төбене төша, ниндидер серле-тылсымлы, әмма бераз шомлырак кубыз көен хәтерләтә башлый: «Сырт кабар-р-тты куа-а-к, үлә-э-н-н… Кош-ш дөн-н-нья-а-сы купты-ы-ы күлдә-е-эн-н-н…» Бу мәҗүси кубыз тавышын шагыйрь үзе дә һәрвакыт тоеп тора. Тоймаса, «Беренче кар» шигыренә: «Кубыз көенә озын җыр» дигән искәрмә бирмәс иде…

Сорау туа: каян килә соң Шәүкәткә бу көй-аһән? Тамак төбе белән көйләнә торган җыру-шигырь? Әлбәттә, анасының имезгән сөтеннән, эчкән суыннан, үскән урманыннан, авыл картларының, бер өйгә җыелып, төн буе җыру көйләп утыруларыннан… Төрки бабаларыбызның мәҗүси ышануларыннан, борынгы шаман йолаларыннан, «күк теле»ннән, «урман теле»ннән, «киек теле»ннән килә… Шәүкәт шигырендә гел шул: әле урман шавы, әле су чылтыравы, әле тау иңрәве, әле яралы үрдәк яисә ятим болан кычкыруы… Ул, башкалар кебек, дөньяны күреп кенә, аны матур, төгәл, җете сурәтләргә төшереп кенә калмый, ул аны «ишетә»… Ул табигатькә, димәк, чынлыкка, дөнья асылына якынрак тора. Ниһаять, ул көй белән аңлаша һәм аңлата ала: елый, сулкылдый, иңри яисә шат аһәң белән көлә, елмая… Әмма һәр очракта да ниндидер тетрәндергеч дәрәҗәдә моңлы һәм шомлы көй гипнозын сизми мөмкин түгел.

Шәүкәт – бәхетле шагыйрь. Ул табигатькә, борыңгылыкка, үз ыру-халкының магик йолаларына аң-зиһен белән генә аңлап булмый торган көй кыллары аша бәйләнгән. Кем белә, аның күңеле аша безнең күңелләргә күчеп яңгыраган бу көйләр – милләтебезнең асылын билгеләгән иң тәүге, иң изге сыйфат-хасиятләр белән бик матур, бәлки, иң соңгы очрашу мөмкинлегедер?

**Мөдәррис Әгъләм,**

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## СЕБЕР МОҢЫ[6]

Шәүкәт Сибгатуллин – себер татары. Кыяфәте белән дә. Рухыҗаны белән дә. Моннан егерме еллар элек Чаллы район газетасында

[6] Әгъләм М. Себер моңы // Шәһри Казан.– 1997.– 17 гыйнвар. – Б. 5.

миңа бер бәйләм шигырьләр бирделәр. Әгәр себер татарлары белән аралашмаган, ул якларда булмаган булсам, теле чатак, әдәби түгел, дип читкә алып куяр идем. Бу очракта мин аны дулкынланым укыдым. Үзен эзләп киттем. Төзелештә эшли икән.

Шигъри дөньясы анын үзенчә – себерчә. Миң аңа татар дәреслекләре табып бирдем. Ул гаять тырыш шәкерт булып чыкты. Үз гомерендә татарча бер дәреслек тә күрмәгән Шәүкәт кыш буена әзерләнде – шикләнеп кенә барса да, бик яхшы билгеләренә Казан университетының татар бүлегенә укырга керде. Әдәби телдә – Казан арты телендә язарга күнегә алмады. Бик тә газапланды.

Берзаман янадан пәйдә булды. Төзелешкә эшкә керде. Гаилә корды. Дөнья басты. Шигырьләрен бастырмаса да, яза килде. Соңгы вакытта үзенең яңа китабын әзерләде. Ул һәрвакыт шигъри даирә белән аралашып яши. Өлкән каләмдәшләрен бик тә хөрмәт итә. Шагыйрь Фәннүр Сафинны җирләп бер атна да үтмәде, аңа чардуган куйдыю

Менә аның бер бәйләм шигырьләре. Алар башкалабыз Казанда яшәүче Себер җырчысы хакында күбрәк сөйләр.

**Мөдәррис Әгъләм,**

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

## ШИГЫРЬ АТЛЫ ЯДРӘ ТИСӘ...[7]

Шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның яңа китабы дөнья күрде. «Ядрә тигән» дип атала.

Узган ел ул безне «Ярык мөгез» дигән беренче китабы белән сөендергән иде. Моннан ун-унбиш еллар элек бу, әлбәттә, әдәбиятыбызда зур вакыйга буларак кабул ителгән булыр иде. Газета-журнал битләрендә бәяләмәләр чыгып, язучыларның ел йомгакларында исеме телгә алынган, арага кызыклы һәм үзенчәлекле шагыйрь килгәне билгеләп үтелер иде. Әмма ул искитмәле көннәр сагынып сөйләргә генә калды. Яңа китап чыгамы -юкмы, талантлы каләм иясе пәйда буламы – бу инде бүген беркемне дә кызыксындырмый. Шәт, шуңадыр да ачылып кына килә торган яшьләребез ялтырап китәләр дә үз эчләренэ йомылалар. Нәкъ Тукайдагыча:

*Бара милләет, бара абыныр-абынмас,*
*Сүнәэ яшьләрдә уй кабыныр-кабынмас.*

7 Әгъләм М. Шигырь атлы ядрә тисә… // Мәгърифәт.– 1998.– № 45 (357), 7 ноябрь. – Б. 5.

Чыннан да, шигърияттә ир-егетләр бөтенләй күренмиләр. Күренсәләр дә – ялтырап китәләр дә… сүнәләр. Югалалар. Комга сеңгән су шикелле кибеп, торфка әйләнгән җәмгыятебезгә сеңеп бетәләр. Шулай да аксакаллар бик үҗәтләрен, бик тә талантлыларын канатландырып, өметләндереп саклал килә алдылар. Инде хәзер алар да бу мөмкинлектән мәхрүм. Үзләре дә матди яклауга мохтаҗ…

Шундый мәхшәрле зилзиләдә шигъриятькә яңа көч, яңа дәрт белән әйләнеп кайтучылар да бар. Шагыйрь Шәүкәт Гаделша – әнә шулардан. Әдәби хәрәкәтнең эчендә кайнаган каләм ияләре аны Шәүкәт Сибгатуллин дип, инде хәттидән беләләр. Университетта укыган елларында аның үзенчәлекле иҗатына Мехәммәт Мәһдиев игътибар иткән иде. Бер бәйләм шигырьләрен, хәерле юл теләп, көндәлек матбугатка да тәкьдим итте.

Бу егет университетта татар теле һәм әдәбияте бүлеген тәмамлады. Филолог та, укытучы да булып китмәде. Белемен шул өлкәдә алса да, бу аның табигатенә хас түгел иде.

*Көлсәгез – көләрсез, дусларым, –*
*Бу сәер?*
*Себернең тынгысыз*
*Черкиен сагынам.*
*…Черкиләр тәнемә, йөземә*
*Яратып кадала.*
*Куанам: димәк ки, тамырдан*
*Сәламәт кан ага.*

Һәм ул Себергә кайтып китте. Төрле оешмаларда, совхозда җитәкче эштә эшләде. Сабыр холыклы, бер караганда беркатлы һәм юаш күренгән Шәүкәттә кешеләрне туплау сәләте бик көчле. Ул тирәюньдәгеләрне ышандыра белә. Ярдәмчелеккә ярдәмчелек белән җавап бирү аңарда ерак юлга чыккан юлчылардан, аучылардан, балыкчылардан ук килә. Борынгы бабаларыннан ук. «Себер татары» шигырендә бу хакта бик әйбәт әйтелгән: «Ишкәгемне киң каерып тирән бастырамын», чөнки көймәдәшкә җиңел була, «Учак яксак, чүмәшәмен очкын очкан якка», чөнки учакташы төтен йотмый, җайлап кына ята. «Киек атсам, үзем сорап алам кабыргасын». Чөнки «итлерәге калсын».

*Бирәм соңгы серәмкәне (шырпы),*
*Соңгы телememне.*
*Күрәм кеше күнелләрен,*
*Тыңлап күңелемне.*

*Кызганмыйм да, үкенмим дә, –*
*Рәхәтләнеп калам.*
*Себер татарларын шулай*
*Яраткан бит Аллам.*

Шәүкәт, Себер татарларына хас булганча, табигать баласы буларак, бик тиз ышанучан. Әнә шул ышану аны бик яшьләй коммунистлар партиясе сафларына алып килгән. Чөнки, аның аңлавынча, илгә, халыкка хезмәт итәр өчен фиркале булу кирәк. Аның, ышануынча, бу мәҗбүри дә. Ә менә шигырьдә бу хакта ул беркайчан да кагылмады. Бары тик ата-бабаның гореф-гадәтләренә һәрвакыт тугры калып, аларның дингә булган мөнәсәбәтләрен ихтирам итте. Моны мин – каләмдәшем, якын дустым Фәннүр Сафинны җирләгәндә, бик тә ачык күрдем. Бик соң гына ишетеп, җеназасы якынлашканда гына килеп керде. Табутка карап, мөлдерәп торды-торды да, кырт кына борылып, күрше бүлмәдән егетләренә чылтыратты. Ялтыратып шомартылган ләхет такталары китерделәр, каберенә ләхет алынды. Зираттан без киткәндә, койма аръягында калган кызыл материя белән табутын кабер казучылар күтәреп китеп баралар иде инде. Бер атнадан Фәннур дустының каберен тимер челтәрле чардуган әйләндергән иде.

Шәүкәт белән без Чаллыда таныштык. Җитмешенче елларда, КамАЗ төзелеше башланган иде. 1963 елда, әле без мәктәпләрдә укыганда, шагыйрь Хәниф Хөснуллин Чаллы район газетасы каршында әдәби берләшмә оештырган иде. Хәзер ул «Ләйсән» исемен йөртә. Әйтеп китәргә кирәк, бу исемне аңа Шәүкәт тәкъдим итте. Быел ул берләшмәгә 35 ел, «Ләйсән» исеме бирелгәнгә – 25 ел. Редакциягә, әдәби берләшмәгә килгән шигырьләрне күзәтү ясарга миңа да биргәлиләр иде. Берсендә: «Менә бу шигырьләрне карап чык әле, үзе татарча да сыман, матур гына дарләре бар», – дип, берничә шигырь бирделәр. «Күп сүзләре аңлашылмый», – дип тә өстәделәр. Берничә мәртәбә Себер татарларында филологлар экспедицияләрендә булганым бар иде. Шигырьләрне кызыксынып, яратып укыдым. Соңгы вакытларда шигъри почта «Карамыйча язы, көзенә… Ура! Ура! КамАЗ төзелә!» кебек шалтыравык юллар белән тулы иде.

*Бителем тулы табан балык.*
*Күтәреп торма судан алып.*
*Бител селкенә, тыпырчына -*
*Күпме балыкның җаны чыга.*
*Җибәр дигәндәй дулкын дулый,*
*Күл акчарлагы ачы елый.*
*Җил ярсып суга яңагыма,*
*Таллар кизәнә як-ягымда.*
*Куркыбрак карыйм бителемә, –*
*Күлнең йөрәгенме элдем мәллә?*
*…Акчарлак арттан елап барды -*
*Балыкны күбрәк тоттым, ахры.*

Шигырьдә – безнең классик үрнәкләрдән аермалы буларак, себер сөйләме. Аларның, риваятьләрендә яңгырап киткән әйтемнәр агышы.

Киттем Шәүкәт Сибгатуллинны эзләп. Төзелештә монтер булып эшли икән. Тулай торагына киттем. Шигырьләренә карап мин аны безнең Казанда чыккан китапларны бөтенләй укымагандыр, дип уйлаган идем. Чаллы китап кибетләрендә булган бөтен татар китаплары аңарда бар.

– Мин язсам да, Казанча язмам инде, әкә! – дип куйды Шәүкәт. Әкә! Себер татарлары өлкәннәргә шулай эндәшә. Бу сүз Шәүкәт белән бергә Казанга да килде. Миңа ябышып та калды. Хәзер бер буын яшьләр миңа шулай эндәшә.

Мин егетне Казанга димли башладым. Университетка, татар бүлегенә. Әлбәттә, ул мәктәптә татарча укымаган. Татар китапларын да даими рәвештә әле хәзер генә укый башлаган. Татар теле, әдәбияты буенча дәреслекләр юнәттек. Яшь шагыйрь ушлы һәм үҗәт булып чыкты.

Бер мәртәбә Казан университетынын тулай торагына барып чыксам, Себер егете инде укып йөри икән. Ул бирeдә биш ел укыды, үзеннән яшьләр белән. Әмма инде 8 март, 9 май, 7 ноябрь һ.б., һ.б. даталарга шигырь язарга күнеккән даирә аны кабул итмәде. Аның табигатьтән ургылып чыккан шигырьләреннән тәгәрәп көлде. Мөхәммәт ага Мәһдиев тә ярдәм итә алмады. Шәүкәт үҗәт иде. Үтә дә үҗәт иде. Үз-үзеннән бер адым да чигенмәде.

*Йөрәк кыстый,*
*Тәнем кыстый,*
*Күңел кыстый,*
*Җаным кыстый.*
*... Исем китми*
*Бу дөньяда*
*Кыстаучылар*
*Күп булганга.*

*Ымсынмыйм да*
*Булыйм бары*
*Исән генә.*
*Ятып җылы*
*Томаннарга*
*Ләззәт алам,*
*Моңым ага.*

Шәүкәтебезнең китабына язылган ахыр сүзендә әдәбият белгече Галимҗан Гыйльманов хаклы рәвештә билгеләп үтә:

«Шәүкәт Гаделша иҗатында да, язма әдәбият традицияләре белән янәшә, халык авыз иҗаты традициялэре квчле агым булып бара. Күп очракларда соңгысы алдырып алып китә әле:

*Җил учаклы йөземне*
*Капларга ниятли,*
*Нарат мине күтәреп*
*Атарга ниятли.*

Соңгы елларда безнең уку йортларына татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдән яшь каләм ияләре килә. Алар да үзләренең йөзен, үзенчәлекләрен саклап, әдәби телебезне баетсыннар иде. Шәүкәт Гаделша иҗаты – моңа үрнәк.

Чөнки аның йөрәгенә шигырь дигән ядрә тигән.

**Госман Садә,**
татар шагыйре, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

## СЕБЕР КАДӘР СЕБЕР СЫЯ ШИГЫРЬГӘ[8]

Себергә тартым, калын-калын урманлы Урал тавы итэгендэ, яшел чирам юрганнарга төренеп үскәнгәме, әллә шигъриятнең тарту көче зур булгангамы, бер тын, бер сулыш белән укып чыктым чордашым, чалдон егете Шәүкәт Гаделшаның «Сөмән кадыйм» дигән өр-яңа шигырьләр китабын. Әйе, чалдон дип ялгыш әйтмәдем, Себер татарларын шулай дип тә йөртәләр. Шәүкәт Гаделша – җаны, тәне, каны белән чын Себер егете. Безнең шигърияттә табигатьнең (бу урында урман табигатенең дип әйтү дөрес булыр) нечкәлеген сизгер тоеп, аның сулышын тоеп яза алучылар, һай, сирәктер. Табигать аңа, үзен аңлаучы шагыйрьгә илһамны бөртекләп, учлап кына түгел, илаһи уптым итеп күпләп биргән.

Мисалларммы? Моңа бөтен китап үзе мисал. Шулай да кайбер шигырь юлларына тукталып узыйк. Шагыйрь «Урманнарга кабам» дигән шигырендә ничек итеп, ни рәвешле тайгаларда янгыннар чыгуын тасвирлый. Шагыйрьнең үзенә дә күп тапкырлар янгын сүндерүдә катнашырга туры килгән.

*Өскә агач аугалады,*
*Кузгә күмер төшкәләде.*
*Аяк-куллар, кызган тәннәр*
*Сөяккәчә пешкәләде.*
*Бабалардан калган урман –*
*Туган якның йөрәге бит.*

Ничәмә-ничә янгыннар кабынып та, шагыйрынең авылдашлары аны саклап калган. Хәзер исә хәл бүтәнчә: чит телләләр агачларга тамга сугып йөри. Шагыйрь йөрәге чаң суга!

---

[8] Садә Г. Себер кадәр Себер сыя шигырьгә // Шәһри Казан.– 2000.– № 25 (271).– 30 июнь. – Б. 5.

*Авылдашлар күз яшерә:*
*«Нишлик инде… шундый заман».*
*Гарьлегемнән янгын булып*
*Тиздән урманыма кабам.*
Инде килеп «Сусар» шигыренә күз төшерик:
*Алдар идем бу тормышны,*
*Сусар булып булмый бит.*
*Кысан бәхет куышлары –*
*Сыеп кына булмый бит.*
Яисә әлеге юлларны бергәләп укыйк:
*Үз көемне көйләп*
*Беркатлана бирәм.*
*Күзләр сай булса да,*
*Куңел ай-яй тирән.*

Шәүкәтнең иҗатына бу юлларны укып та гашыйк булырга мөмкин. Ул гаять бай, үзеннән бигрәк күңеле вә йөрәге бай: аның җанына селәүсенле, аюлы, саесканлы, сусарлы, төлкеле, кешле, тиенле, мәңге яшел наратлы, чыршылы, кыскасы, колач җитмәс бөек су-җир – Себер сыйган. Шигырьләре да шул хакта сөйли, шул хакта җырлый.

## Газинур Морат,

татар шагыйре, журналист һәм публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Муса Җәлил премиясе, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләге лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

### ЧАЛДУН[9]

Мин Шәүкәт белән беренче мәртәбә 1973 елда таныштым. Шул елны «Татарстан яшьләре» гәзитендә аның бер шәлкем шигырьләре басылып чыкты. Яшь шагыйрьне гәзит укучыларга Мөхәммәт Мәһдиев үзе тәкъдим иткән иде. Остазның сүзеннән аңлашылганча, егет Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып йөри икән. Укырга КамАЗ төзелешеннән, бай тормыш тәҗрибәсе туплап килгән. Кыскасы, шигъриятtә үз сүзен әйтәчәк, өметле егет күренә. Бик күп прозаиклардан аермалы буларак, шигъриятне тирәнтен аңлаучы сизгер җанлы Хәлфә яшь шагыйрьнең потенциаль җегәрен чамалаган, күрәсең.

[9] Газинур Морат. Чалдун // Җәяүле кошлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б.202–209.

Миңа, ул чакта 7 нче сыйныфта укучы һәм шигырь белән җәнләнә башлаган малайга да, Шәүкәтнең шигырьләре шундук якын, үз булып китте. Бигрәк тә «Тукран» дигәне куңелгә ныклап кереп урнашты. Бер укуда истә кала торган гади дә, самими дә һәм шул ук вакытта яңача яңгырашлы да шигырь иде ул.

Тагын өч елдан миңа «Тукран» авторының үзе белән дә очрашырга, аралашырга, хәтта якынаеп китеп, ахириләр булып яшәргә дә насыйп итте. Университет тулай торагында тәүге кат очрашканда, Шәукәт инде 27 яшьлек ир-егет иде (ләкин, ни хикмәттер, минем аңа беркайчан да «абый» дип эндәшкәнем булмады. Белмим, әллә үз яшеннән шактый яшь күренгәнгәме, әллә инде субординация саклыйсы килмәгәннәнме. Хәер, эле миннән яшьрәк егетләрнең дә Шәүкәткә «абый» дип эндәшкәннәре бик сизелми. Ә Ркаил Зәйдулла, әбзисен бөтенләй малайсытып, Шәүки, дип кенә җиффәрә). Чит-ят күздән яшереп кенә шигырь язучы Илдар Хөснетдин (авыр туфрагы җиңел булсын) белән бер бүлмәдә яшәп яталар. Лекцияләргә барырга бигүк атлыгып тормыйлар, үзләре кайдадыр эшләп тә йөриләр. Өстәвенә Шәүкәт факультетта активист та булып санала икән. Ни әйтсәң дә, акыл утырткан, дөнья күргән егет ич, әле житмәсә, коммунист та. Ә үзе без күреп ияләнгән кырыс чырайлы, җитди сүз генә сөйләүче коммунистларга бер дә охшамаган. Карсак буйлы, каратут йөзле, дәү башлы, киң маңгайлы, ат өстеннән төшмәгән ерак бабайларыныкыдай төрки аяклы бу самими егет кинолардагы япун самураена ныграк тарткан иде. Сөйләшүенә караганда, Күчем ханның киңәшчесе булырлыгы да бар. Ялгышмасам, без 1 нче курста чакта ул әле университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге каршындагы «Әллүки» иҗат берләшмәсенең җитәкчесе дә иде. Сары томшыклы «даһи»лардан гына гыйбарәт Язучылар берлеге рәисе, ягъни мәсәлән.

Бераздан Шәүкәт, көтмәгәндә-уйламаганда, укуын ташлап, дөресрәге, читтән торып уку бүлегенә күчеп, туган төбәгенә – Төмәненә кайтып китте. Анда ул башта кайсыдыр колхозның партоешма секретаре, аннары баш энергетигы булып эшли. Имтиханнар вакыты җиткәч, бик фырт кына кыяфәттә Казанга килеп чыга (ни әйтсәң дә, нәчәлник кеше бит), еш кына безнең бүлмәгә туктала иде. Ә без төннәр буе аның Себер мажараларын тыңлап ятып, иртән лекциягә барырга да соңга калгалый идек. Шулай килеп-китеп 10 еллап гыйлем эсти торгач, Шәүкәт, ниһаять, «мәңгелек студент» яшеннән чыкты һәм Казанны ташлап бөтән китмәскә булды.

Белмәссең, әллә шул коммунистлыгының берәр файдасы тиде, әллә инде 16 яшеннән Салехардта электрик булып эшли башлавы ярдәм итте – Шәүкәт укытучы-филолог дипломы белән бер төзелеш трестының участок җитәкчесе итеп билгеләнде. Кайчагында күнелгә,

әллә бу чалдун, төп вазифасын онытып, дөнья куарга ниятләде микән, дигән икеле-микеле уйлар да килгәли иде. Ләкин ыгы-зыгылы эш тә, тормыш мәшәкатьләре дә, шөкер, Шәүкәтне иҗаттан, шигырьдән аера алмады. Мәгәр андый хезмәтнең язу-сызу эшенә зыяны да тими калмагандыр, әлбәттә.

Содгы 3–4 ел эчендә Шәүкәт Гаделша бер-бер артлы өч китабын бастырып чыгарды («Ярык мөгез», Татарстан китап нәшрияты, 1997, «Ядрә тигән», «Матбугат йорты» нәшрияты, 1998, «Сөмән кадыйм», «Матбугат йорты» нәшрияты, 2000). Үз хисабына, гаиләсенең авызыннан өзеп дигәндәй. Дөрес, ул бүген аягында нык басып торучы, акчаны эшли, таба белүче эшкуар, үзе оештырган төзелеш фирмасы җитәкчесе. Бер караганда, шигырь язу аңа хәзер бер мавыгу, хобби ише нәрсә генә булырга тиеш кебек (ә Шәүкәт үзе нык мавыгучан адәм: киекләрнең холык-фигылен яттан белүче оста сунарчы да ул, азу ярган балыкчыгөмбәче дә. Нишлисең, Себер каны, Себер холкы үзенекен итә, билгеле). Ләкин бу очракта нык ышанып әйтергә мөмкин: баксаң, Шәүкәткә эшкуарлыгы, беренче чиратта, шагыйрьлеген раслау өчен кирәк булган икән. Чөнки бүген казна хисабына китап чыгару аны язуга караганда күпкә кыенгарак туры килә. Әгәр Шәүкәт әлеге китапларының дөньяга чыкканын кул кушырып көтеп утырса, бәлки, аларны пенсиядәге яшь шагыйрь чагында да күрергә насыйп әйләмәс иде. Ә ул 50 яшьлегенә үз-үзенә менә дигән бүләк әзерләде һәм татар шигъриятендә, заманча тел белән әйтсәк, шундук үз «сайт»ын булдыруга иреште. Алай гына да түгел, аның иҗаты, миңа калса, татар шигъриятендә уникаль бер сәхифә, вакыйга булып саналырга лаек.

Хикмәт шунда ки, бездә язу өслүбе җәһәтеннән мотлак оригиналь шагыйрьләр алай күп түгел. Поэзиябездә игезәк шагыйрьләр, игезәк шигырьләр тулып ята. Әгәр әсәренең авторы күрсәтелмәсә, бериш шагыйрьләрне бер-берсеннән бөтенләй аерып та булмас иде. Ә Шәүкәт бу яктан иң бәхетле шагыйрьләрнең берседер, мөгаен, чөнки аның хәтта иң уңышсыз дигән шигырьләре дә, безне Чалдун әкә язды, дип кычкырып тора.

Шагыйрь бар булмышы белән Табигать баласы. Ул, Табигатьнең үзе кебек, цивилизация, аның җимергеч көчләре белән һәрвакыт каршылыкта яши. Еш кына аның шигырьләре дә шомартылмаган таш, юнылмаган агач шикелле табигый халәттә була, һәм алардагы ритм, рифма, цезура чатаклыклары да ничектер колакка ятышсыз булып тоелмый, күзгә кергән черки кебек, күңелнең куз алмасын бимазалап тормый.

Черки дигәннән, бу дөньяда черкине үз итеп, хәтта ки яратып язган-тасвирлаган берәр шагыйрь булды микән? Ә менә Шәүкәт Себер мәчкәен сагынуы турында сәер шигырь язган. Дөресрәге, ул безнең ише, рәтле-башлы урман-су күрмичә далада үскән кешеләр өчен сәер

инде. Мәгәр Себер урманының үлән-агачлары, җәнлек-бөҗәкләре белән сер бүлешкән, шатлык-кайгысын уртаклашкан, үзен дә шуларның иш-туганы дип исәпләгән шагыйрь өчен аны үлемнән коткарырга теләп, үләннәрнең кан бирергә дип чиратка басуы да, танавын галәмгә суз-ан пошиның күктәге йолдызларны сибелгән тозга охшатуы да, Айда әрләннәрнең ком ишүе дә, чикерткә тигәнәккә бәрелеп егылгач, куркышып бер читкә өелгән ак болытлар да, сөйкемле кыз күргәч, йерәккәенең кәлтә теле шикелле келт-келт итүе дә, хатын-кызның күкрәгең ак кыр тавыгы белән чагыштыру да, кырмыска тәненә сыенып, җылынып ятмакчы өмет тә, Казан күгенең улын имезеп ләззәтләнгән болан күзенә охшавы да – барысы да бик табигый тоела. Таң алдыннан урманда ауда йөргәндә кайсыдыр авылдан азан тавышы ишеткәч тә, аңа биек чыршы – мәчет манарасы, ә серле эңгергәэ чумган куак, ботаклар Коръәндәге хәрефләр, аять-сүрәләр булып күренә башлый. Ул аларны укырга азаплана, ләкин шунда тумыштан динсез, надан икәнлеген исенә төшерә:

*Тонык кына яңгырый азан:*
*«Яңа заман, яңа заман!»*
*Ә мин, бүре баласыдай,*
*Караңгылыкка карыйм һаман.*

Бу инде әлифне таяк дип тә белмәүче заманның тәкъва булып күренергә тырышучы монафикълары кыла торган дога түгел. Бу – күңелен җилбәгәй җибәргән, намуслы шагыйрь сүзе. Хәер, бар вөҗүде белән Табигатькә береккән кеше Күккә дә якынрак торадыр ул.

Шәүкәт үз нәсел-нәсәбен шактый этрафлы белә. Аның 1867 елда Тәтеш өязендә туган Гишам бабасы (әтисенең әтисе) югары дәрәҗәле рухани була. Ул динчеләрнең рәсми карары белән Себер татарлары арасында дин, мәгърифәт тарату өчен җибәрелә. Төмән өлкәсендәге Болгар, Тура авылларына нигез салучыларның да берсе Гишам хәзрәт булуы билгеле. Ләкин хәзрәт вәгазь укып кына йөрмәгән, хәзергечә әйтсәк, бизнес белән шөгыльләнергә дә вакыт тапкан. Әйтик, ул сагыз кудыра, күн эшкәртә торган кечкенә фабрикалар тоткан, күрше-тирә халыкны эш белән тәэмин иткән. Андый булдыклы кешеләрнең язмышы да билгеле инде. 1937 елда 70 яшьлек Гишам бабайны да атып үтерәләр. Ләкин һич тә фабрика тотканы өчен түгел, ә милли эшчәнлек алып барганы өчен. Һәрхәлдә, «дело»га шулай теркәлгән, ди. Моннан берничә ел элек Шәүкәт Төмәнгә кайтып, ул «дело »ны өйрәнеп тә килгән иде.

Шагыйрь үзенең бабалары хакында «Сазлык» дигән шигырендә менэ ничек яза:

*Мулла бабам куылганда*
*Алтынын күмгән, имеш.*
*Чалдун бабам ачтан үлгән,*
*Камыш чәйнәгән килеш.*

Шәүкәтнең әнисе ягыннан бабасы Алим атлы чын себер татары була. Балыкчылык белән шөгыльләнә. Ә үзе 1922 елда ачтан үлә. Ни аяныч, шагыйрьнең бер бабасы сазлыкка алтын яшерергә мәҗбүр ителә, ә икенче бабасы шул ук сазлыкның камышын чәйнәп җан бирә. Ә моның сәбәбе нидә соң? Шигырьнең ахырында әлеге сорауга да җавап тәгаенләнә:

*Бәхет басармы халыкны*
*Шундый сазлыклы илдә?*

Аңлашыла ки, бу – табигый сазлык түгел. Ул сазлыкны кешеләр барлыкка китергән. Шуңа күрә аны киптерергә кирәк, сазлык – ул империя, тоталитар система, халыкларны сортларга бүлү, кеше кадерен белмәү, дөньяның ярты байлыгы өстендә утырып та, хәерче хәлендә яшәү, дигән сүз. Әнә шул сазлыкны киптергән тәкъдирдә генә халык бәхеткә тиенергә мөмкин.

Соңгы вакытта Шәүкәт үзе дә партия билетын ерак-карак яшереп куйды бугай. Чөнки аңлады: яхшы шигырь язар өчен дә, бәрәкәтле бизнес белән шөгыльләнер өчен дә КПСС яки КПРФ әгъзасы булып торуның бер хаҗәте дә юк икән. Киресенчә, ул сине коммунистик идеология читлегендә бәхетле киләчәгебез турында гына сайраргa мәҗбүр итә. Әйтик, әгәр партия заманы булса:

*Дулкыннар очлана*
*Калкып тирәннән.*
*Әйтерсең Ермакның*
*Шлемын кигәннәр,* –

дигән шигъри юллары өчен коммунистик цензура Шәүкәткә ни дияр иде икән? Ә бит шигырьдә Себерне канга батырган бандит, юлбасар, соңыннан үзе дә суга батып үлгән Ермак турында сүз бара. Ул исә коммунизм идеологлары өчен һәрвакыт Русия патриоты, ватанпәрвәр булды.

Шәүкәт Гаделша иҗатының тагын бер кызыклы үзенчәлеге бар. Гәрчә үзе озак еллар сул күкрәк кесәсендә партбилет йөртсә дә, аның партия, коммунизм, Ленин, бәхетле бүгенгебез, якты киләчәгебез турында бер кәлимә дә язганы юк икән. Үз иҗатын да, татар шигърия-

тен дә чүпләмәгән, ахыргача ихлас булып кала алган, ә андый кызыл шигырьләр язуны икейөзлелек галәмәте, дип санаган, димәк. Бу очракта да аны көфер сүз язудан Табигатьнең бер нарасый баласы булып, һәр үләнне, бөҗәкне, кошны, җәнлек-җанварны үз тиңе, ахире, яшьтие, сердәше санап яшәве саклагандыр. Шуңа күрә дә ул бүген Табигатьтә гармониянең бозылуын, аны ерткычларча талауларын үзенең шәхси фаҗигасе буларак кабул итә:

*Быел кайтсам туган якка:*
*Чит телләләр урманнарда.*
*Наратларга, усакларга,*
*Каеннарга суга тамга.*

*Авылдашлар күз яшерә:*
*«Нишлик инде… шундый заман».*
*Гарьлегемнән янгын булып*
*Тиздән урманнарга кабам.*

Кискенрәк әйтелгән, билгеле. Ләкин синең көенеч-кайгыларыңны да, сөенеч-шатлыкларыңны да аңлый белгән урманыңа бер көн килеп, чит-ят кавемнәр хуҗа булып алса, гарьлегеңнән янгын булып та дөрләрсең, яшен булып та яшьнәрсең.

Шәүкәтнең мәхәббәт лирикасы да беркемнекенә охшамаган. Лирик каһарман дигәнебез кайсыдыр бичәгә сөю аңлатканда да, кайсыдыр бичә ана елышканда да шагыйрь артык нәзакәтләнеп, чәчәклечуклы сүзләр эзләп тормый – тормышчан, ягъни табигыйрәк өслүбтә язуны мәгъкульрәк күрә. Бу да аның самимилегеннән, ихласлыгыннан килә булыр.

Шагыйрь тормыш-яшәешнең үтә дә нечкә, нәзберек мәсьәләсен – «мәхәббәт өчпочмагы»н да гаҗәеп дәрәҗәдә табигый һәм үзенчә хәл итә. Шуңа күрә әлеге шигырьне тулысынча китерсәм дә, укучым аны укыганда ялыкмас, дип уйлыйм:

*Елгыр атлар кура саен,*
*Ат карагы булалмаем.*
*Бичәм ята чәчем сыйпап –*
*Сиңа барып куналмаем.*
*Алка итеп, йөзек итеп*
*Күрәм төннең алтын аен.*

*Бичәм ята аңа карап –*
*Сиңа бүләк итәлмаем.*
*Белмим, мине ниең тарта?*
*Әллә җаның, әллә каның?*
*Бичәм ята ирнен тешләп,*
*Сине уйлап куйган саен.*

Шәүкәт бер шигырендә, алагаем зур чуртан каптыргач, сөенеченнән:

*Бөтен Себергә*
*Мин – бердәнбер хан! –*

дип белдерә. Әгәр Себер ханлыгы торгызыла калса, шагыйрьнең хан булып тора алачагына шик юк, билгеле. Шәүкәт ханның шигырь белән язылган ярлыкларын укып, халык, әй, кинәнер иде, мин сиңайтим. Ә инде җитдирәк уйлап бакканда, ул бүген чыннан да Себер дигән шигъри патшалыкның бердәнбер төмәнбашы түгелме соң? Әйе, Булат әкә Сөләйман дөньядан кичкәч (урыны җәннәттә булсын), Шәүкәт татар шигъриятендә иксез-чиксез Себернең бердәнбер вәкаләтле вәкиле булып калды. Ләкин берүк соңгы могиканы булырга гына язмасын иде.

Әйе, шагыйрь җаны-тәне белән Себергә, аның табигатенә, кешеләренә береккән. Әмма ул халкыбызны төрле ыру-кабиләләргә бүлгәләп, алардан аерым милләт укмаш-тырырга ниятләп йөрүчеләргә теләктәшлек итүдән бик ерак тора. Шагыйрь типтәр-мишәрнең дә, керәшен-башкортның да, себер, әстерхан, кырым, ногай, казан татарының да бер Ана балалары булуына аз гына да шикләнми. Бер шигырендә Шәүкәт үзе дә:

*Казан, Төмән арасы –*
*Мәгънәм минем, канатым, –*

дип яза. Ә сыңар канат белән очып булмаганын, кем-кем, ә Чалдун әкә бик яхшы белә…

**Диләфрүз Фәхретдинова,**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты,
Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## КАДЕРЛЕ АВЫЛДАШЫМ МИНЕМ[10]

*«Йөгереп кенә кнтәр идем лә мин,*
*Кузгалырга нидер җитеп бетми;*
*Әллә Казан тәмам тоткын итте,*

Әллә Себерем онытты инде?» май бәйрәменә дип Киндерлегә кайткач, авылдашларым миңа бериичә көн элек Казаннан күршем Шәүкәт абыйның кайтып килгәнен әйттеләр. Мин бала чагымнан ук Шәүкәт абыйның, туган якка кайткач, кармак белән гел елга буена балыкка төшүен хәтерлим. Безнең йорт яныннан узганда елмаеп әти белән

[10] Фәхретдинова Д. Кадерле авылдашым минем // Яңарыш.– 1998.– № 40 (564), 15 май. – Б. 2.

исәнләшә, эскәмиягә утырып алар бер-береннән хәл-әхвәл сорашалар. Икәвенең сөйләшкәндә гел бер тема: урман, елга, балык, җәнлекләр. Әти, сунарчы буларак, аңа Себер урманнарын сойли. Шәүкәт абыйның урман, табигать белән саташуын бөтен авыл белә. Ул Бизим, Луговое, Киндерле елгаларын, Саргач-бил, Черек, Белое, Татаурка, Лапкынды күлләрен, Бүрән, Пилорам, Мирон сазларын әллә ничә кат өйләнгәндер, мөгаен.

Шагыйрь  бу кайтуында авыл халкына бүләк итеп үзенен яңа басылып чыккан шигырь китапларын алып килгән. Кулымда ике китап. Беренчесе – «Ярык мөгез» исемле, икенчесе – «Ядрә тигән». Шушы китапларны ачып Шәүкәт абыйның шигырьләрен укый башлагач, күңелем тулып күздән мөлдерәп яшь акты. Шагыйрьнең моңача шундый матур. Себер теле белән язылган шигырьләре белән таныш булмаганлыгыма үкендем.

Шәүкәт Гаделша улы Сибгагуллинның шигырьләрендә урман шавы, әле су чылтыравы, әле тау иңрәве, әле яралы үрдәк яисә ятим болан кычкыруы чагылдырылган. Ул шигырьләрендә дөньяның матурлыгын җете сурәтләргә генә төшереп калмаган, ул көй белән аңлата алган. Иҗатында ниндидер тетрәндергеч дәрәҗәдә моңчы һәм шомлы көй гипнозын сизми мөмкин түгел.

Ике ут арасында яшәп ята шагыйрь. Язмышы аны чит җирләргә алып киткәнгә, бик каты туган якларын, Себерен сагына. Аның туган җиренә булган көчле мәхәббәте хакында китапны ачып шигырьләрен уку белән күрәбез. Шагыйрьнең иҗатын бары тик Себер урманнары белән генә тиңләргә мөмкин. «Моңлы да ул, шомлы да, горур да. Нәрсә булмас тайга урманында?!» Исеме дә аның – Гаделша. Бу исемне ул туган якка кайткач әтисенең истәлеге итеп мәрхүм Гаделша абыйдан алган.

Казанда Шәүкәт абый башта электрик булып эшли. Филолог-әдәбиятчы белгечлеге буенча университет тәмамлап, кыска вакыт эчендә мастер, прораб хезмотенә куела, бүгенге көндә ул төзелеш трестының участок башлыгы вазифасын башкара.

«Ядрә тигән», «Ярык мөгез», китапларын укыганнан соң авылдашым өчен горурландым.

Безнең Киндерледән шушындый талант чыкканына сокландым, чын күңелемнән шатландым, йөрәгемдә әллә нинди әйтеп булмый торган хисләр уянды. Мин авылымны болай да яратам, ә шигырьләрдән соң туган җиремә мәхәббәт икеләтә артты.

**Люция Хабибуллина,**
татар мәдәнияте һәм мәгарифе эшлеклесе, танылган Гарифуллиннар педагогик династиясе вәкиле, атказанган мөгаллим, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты, Россия һәм Татарстан журналистлар, себер татар язучылар союзлары әгъзасы, сугыш һәм хезмәт ветераны

## ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША ШИГЫРЬЛӘРЕНӘ АНАЛИЗ[11,12]

Тормышка, яшәешкә гашыйк Киндерле шагыйре Шәүкәт Гаделша милләтебезнең асылын билгеләп, тирән эчтәлекле шигырьләр яза. Аның шигырьләре гүзәллекне аңларга, табигать ямен, рухи матурлыкны тоярга ярдәм итеп, югары әхлак, туган илгә бирелгәнлек рухында тәрбияли торган шигырьләр. Шагыйрь Казанда яшәсә дә, туган ил сулышын тоеп, тормыш агышын сизеп яши. Ш. Гаделша дөньяны үз авылы Киндерленең балыклы күлләре, төпсез, тирән сазлыклары, шау-чәчәкле болыннары; шомлы да, серле да булган тайга урманнары аша таныш белергә омтыла. Шагыйрь матурлыкны авылының казүрдәкләре, урманының төлке-мазары, куяннарыннан эзли. Шуларны бер бөтен итеп, гади кешенең рухи бөеклеген саллы итеп сурәтләп бирә белә. Туган ил, Ватан-ана образы абстракт бер төшенчә генә булып калмый, ул авыл кешеләренең уй-хисләренә, күңелләренә туган авыл табигате, иген-кырлары, сазлык-күлләре, урманы рәвешендә урнаша.

*Нурлы күзләр, сөремсез йөз*
*Күрергә мин сусадым.*
*Рәхәтләнеп күзгә карап*
*Килә сорыйсыларым.*
*Балык ничек? Иртә-кичен*
*Ауларга тыгыламы?*
*Капканнарга төлке-мазар*
*Бик теләп сугыламы?*
*Ничек анда таң атканда*
*Сулый наратлар шавы.*

*Юкәдәнме, ефәктәнме*
*Атларыгыз тышавы?*
*Туган авыл урамнарын*
*Ялгыз башым мин үтәм.*
*Капка төптә тәмәкеле*
*Берәр ирне күр икән.*
*Нишли ирләр? Ниләр уйлый,*
*Качып капка артына?*
*Җырларыма көч, моң кирәк*
*Капкаларны ачарга?*

Бу шигырьдә шигъри строфалар лирик геройның кичерешләренә бәйле рәвештә кешенең рухи халәтен төрле яклап ачу максатында язылганнар. Табигать турындагы хисләр, тирә-яктагы кешеләр турында һәм

[11] Хабибуллина Л.Б. Шәүкәт Гаделша иҗаты // Яңарыш.– 2002.– 1 февраль. – Б. 3.

[12] Хабибуллина Л.Б. Туган як әдәбияты (Литература родного края): учебное пособие для учащихся 5–11 классов / на тат. Яз. / под ред. Х.Ч. Алишиной. 2-е изд., доп. И перераб. – Тюмень: Типография «Печатник», 2015. – С. 329–338.

шагыйрьнең үз шәхесе турында уйланулары бер бөтен булып, шигъри һәм кичерешләрдә чагылыш таба. Бер мисал: Кайберәүләр миңа

*Кырын карап куя,*
*Казан каласында коргангадыр оя.*
*Юк, мин кыенсынмыйм,*
*Бозны тишә бирәм*
*Күлгә тир тамызып,*
*Суын эчә бирәм.*
*Кырын карашларга*
*Мин күнеккән инде.*
*Алар Казанда да сыный күптән мине.*

*үз көемне көйләп,*
*Беркатлана бирәм.*
*Күзләр сай булса да,*
*Күңел, һай-һай, тирән.*
*Бозны тишә-тишә,*
*Күлне иләк иттек.*
*Күп балыкны эзләп,*
*Башка күлгә киттек.*

*(«Яртыясак»)*

Аның шигырьләрендә табигать тә, тире-яктагы дус-ишләр, авылдашлар да, үзе дә бар, анда бөтен тирә-юнь сыйган, дөнья һәм аларга шагыйрьнең мөнәсәбәте чагылган. Шигырьдә халык рухын тирәнтен аңлау, авторның шигъри уй-кичерешләре урын таба.

Ул бүгенге тормыштагы олы социаль-әхлакый үзгәрешләрне, зур яңалыкларны үткәннәр фонында гомумиләштереп бирә.

*Күзләремне кат-кат уам:*
*Туган ягым түгел мәллә? –*
*Шарак шаулап торган җирдә*
*Йолкыш бушлык күренә лә.*
*Кая гына элим икән*
*Арган рухны, карашларны,*

***

*Кемнәр шулай туган җирнең*
*Җан җелеген актаралган?*
*Шундый җаннар туа бары*
*Җен яраткан аналардан.*
*(«Аллам ишетмәгән»)*

Илдә, табигатьтә үзгәреш-яңарышларны сынландырырга омтылыш, табигать-тереклек өчен борчылып язган шигырьләреннән берсе бу.

*Күл өстендә ялгыз үрдәк,*
*Канатына ядрә тигән.*
*Очасы юл ерак иде*
*Шәһәрләрдән, диңгезләрдән.*

*Талпынгалап карый да ул,*
*Канатына ядрә тигән.*
*Кайсы явыз, булдыксызы*
*Аңа төбәп атты икән?*

Табигать, тереклек өчен борчылу аның күп кенә шигырьләрендә күрене. «Урманнарга кабам» шигырендә шагыйрь җирдәге, табигатьтәге, кеше әхлагындагы үзгәрешләрне күреп борчыла.

*Быел кайтсам туган якка:*
*Чит телләр урманнарда*
*Наратларга, усакларга*
*Каеннарга суга тамга.*
*Янгыннан да куркынычырак*
*Күзләренең йөгерүләре.*
*Сорыйм моңсу авылдаштан:*
*– Рөхсәт сорап керделәрме?*
*Авылдашлар күз яшерә:*
*«Нишлик инде ... шундып заман».*
*Гарълегемнән янгын булып*
*Тиздән урманнарга кабам.*

*(«Урманнарга кабам»)*

Олы борчылуын сискәндерерлек итеп, тәэсирле итеп сурәтли шагыйрь. Шул ук шигырендә урманны янгыннан коткаручылар турында «бу яшенле хәбәр, йөрәкләргә кереп шартлый, сикереп тора түшәгеннән үлеп яткан күрше карты», «Өскә агач аугалады, аяк-куллар, кызган тәннәр сөяккәчә пешкәләде», һ.б. күренешләр укучыны да ваемсыз калдырмый, тереклекнең язмышы, аны саклауда кешенең җаваплылыгы тагы артырга тиешлеге, кешенең әхлаклылыгы турында уйландыра.

*Бабалардан калган урман –*
*Туган якның йөрәге бит!*
*Ансыз*
*Безнең йөрәкләрнең*
*Кешелеккә кирәге юк.*

*(«Урманнарга кабам»)*

Урманның кешелек тормышында тоткан урыны, бу хәзинәдән башка тереклек тә була алмый дигән бүгенге көн өчен актуаль теманы Ш. Гаделша әхлакый-фәлсәфи гомумиләштереп сүрәтли.

Киндерле сазлыкларында, урманнарында төрле юллар, төрле буыннар язмышы ята. Шагыйрь әнә шул буыннарны тоташтыра торган тарихи җепләрне, әхлакый катламнарны эзли, шуларга игътибарын юнәлтә.

*Кайсы сазлык суырган*
*Сукмагын бабамнарның?*
*Каенда – сөяк төсе*
*Күмелеп калганнарның,*
*Кайсы ягына карап*
*Минем бабам елаган.*

***

*Кыпчакмы мин? Монголмы?*
*Кәһәр суккан татармы?*
*Кайсы якка кайтам да,*
*Кайсы якка барамын.*
*Казан, Төмен арасы –*
*Мәгънәле минем, канатым.*
*(«Язмышымның дәрьясы»)*

Хис һәм фикер бердәмлегендә, тирән кичереш нигезендә язылган мондый шигырьләрдә гражданлык хисләре чагылыш таба, тормышка фәлсәфи бәя бирелә. Шагыйрь бер әсәрендә үткән белән бүгенгенең ни рәвешле тоташуын ачу юлында эзләнсә, икенче шигырендә бугенге белән киләчәкнең бәйләнешенә игътибарны юнәлтә.

Шәүкәт Гаделшаның шигырьләре арасында аналар, балалар турында бик матур, тирән мәгьнәле шигырьләр бар. Хис-кичерешләр белән язылган «Улы карт анасына хат язды» шигырен укыганда, намуслы, кешелекле, гадел, нечкә күңелле ана күз алдына килеп баса.

*Улы карт анасына хат язды:*
*«Әгәр көннәр артык кызу булса,*
*Кара көйсә, шиңсә һәр ягың,*
*Җыяр идем, әни, синең өчен*
*Аккошларын бөтен дөньяның.*
*Очар иде алар баш очында,*
*Тезелешеп, салмак тирбәлеп.*
*Кочар иде сине, назлар иде*
*Ак канатның йомшак җилләре.*

***

*Җыяр идем, әни синең өчен*
*Төлкеләрен туган ягымның.*

***
*Туннарыннан иркен чатыр ясап,*
*Яшерер идем сине җилләрдән.*

***
*Ялгыз ана кыска җавап язды,*
*Күз яшенә хатын чылатып:*
*«Ишектәге тотка төште, улым,*
*Каксаң иде шуны бер кайтып ...»*

*(«Хат»)*

Баласы ташлаган, ялгызлыкка дучар булган ананың берничә сүз белән язган тирән эчтәлекле җавап хатын укып, күңелләр тетрәп китә. Бүген аналарын ташлаучы, тотнаксыз, юлдан язган балалар күбәйгән елларда ана горурлыгын югары күтәреп күрсәтә шагыйрь. Гаделшаның бу шигыре үз баласы турында барысын белеп, тоеп торучы горур, намуслы анага тирән мәхәббәт уята.

Шәүкәт Гаделшаның шигъри юлларында (башкалардан шуның белән аерыла да) күңеленнән бөркелеп чыккан юмор, күңел юморы белән сугарылган лирик шигырьләре туган җиргә, аның кешеләренә, гүзәл табигатенә мәхәббәт тәрбияли.

*Карыйм да чибәрнең*
*Йөзенә, учына,*
*Чыгырдан чыгардай*
*Йөрәгем очына.*
*... Эх, ятарга кызның*
*Пычагы астына.*
*Кырмасмы картлыкның*
*Кабыгын аз гына?*

*(«Басмада»)*

«Тозак кора идем», «Сазлык», «Себер татары», «Ядрә тигән», «Язмышларның дәрьясы», «Төш» кебек шигырьләрендә халкыбызның соңгы 10 ел эчендәге кичергәннәре, уй-тойгылары, тормыш вакыйгалары, үзгәрешләре җанлы шигъри сурәтләрдә чагылыш таба. Ул авылын, табигатен, кешеләрнең психологиясен кече яшьтән белә, ул аларга хәзер дә гашыйк. Туган жирләре, аның басулары, урманнары, тургай тавышлары, сандугач сайраулары, иркә һәм эшчән кызлары, тыйнак һәм батыр егетләре, авыл агалары якын да, кадерле да аңа.

*Киек атсак, үзем сорап*
*Алам кабыргасын,*
*Итләргә, миңа түгел,*
*Сунардашка калсын.*
*Бирәм соңгы серәнкәне,*
*Соңгы телememне.*
*Күрәм кеше күңелләрен,*
*Тыңлап күңелемне.*
*Кызганмыйм да, үкенмим дә –*
*Рәхәтләнеп калам.*
*Себер татарларын шулай*
*Яраткан бит аллам.*
*Ай астында кыр-урманда*
*Кышын йоклап кара.*
*Шунда себер татарыдай*
*Сузып җырлап кара.*
*(«Себер татары»)*

Авылда яшәп, авыл мохите белән канәгатьләнә алмаган, үзендә әдәби көч, дәрт-дәрман сизгән егетне татар мәдәнияте үзәге үзенә тарта. Шәүкәт Гаделша улы Сибгатуллин Казанда яши. Үз халкының, заманының рухын, уй-омтылышларын, зәвыгын нечкә тойган һәм шуларны үзенчәлекле иҗатында гәүдәләндергән шагыйрьне аңлап була.

**Нияз Акмал,**
шагыйрь, прозаик, журналист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

## БЕЗГӘ БАЛЫК ЭЛӘКМИ…[13]

Узган елгы саннарның берсендә, кышкы ау сезоны ачылган бер көннәрдә, без шагыйрьләр Шәүкәт Гаделша белән Газинур Моратның ауга чыгулары, икесенә өч куян атып алулары хакында язган идек. Икесенә өч куян атуларын хәтта фоторәсем аша да дәлилләвебез юкка гына түгел иде: ауга бер чыгуда җан башына бер генә куян атарга рөхсәт ителгәнлеге хәбәрдар кешегә бик тә мәгълүм. Өч куян атылганлыгы турында фотофакт биреп, без ул чакта тәгаен сорау куйдык: Аучылар җәмгыяте һәм Язучылар берлеге нәрсә карап ята?

Әлеге вакыйга нәрсә белән беткәндер – белгән юк. Әмма, менә бу рәсемнәрдән бик яхшы күренгәнчә, исемнәре югарыда телгә алынган әлеге дә баягы шагыйрьләр ауга йөрүдән һич тә туктамаган. Бу юлы

[13] Акмал Н. Безгә балык эләкми… // Мәдәни җомга.– 2003.– 14 март. – Б. 13.

алар балык ауларга чыкканнар. Шәүкәт Гаделша да, Газинур Морат та еш кына: «Безгә балык эләкми…» – дип җырларга ярата. Ләкин сизгер укучыны мондый җыру белән генә алдап булмас! Күрәбез ки, Газинур Морат әле генә шактый зур судак балыгын тартып чыгарган, ә Шәүкәт Гаделша исә, ашыга-ашыга, инде икенче уентыны тишеп маташа! Алай гына да түгел, урман буендагы учак, учак өстендәге уха шулпасы аларга балыкның бик теләп эләккәне турында сөйли. Инде килеп, шуны гына әйтәсе кала: «Безгә балык эләкми…» дип җырлыйлар икән, бу шагыйрьләргә һич кенә дә ышанмагыз! Балык ул, киресенчә, безгә генә эләкми…



**Ркаил Зәйдулла,**
татар язучысы, шагыйрь, прозаик һәм публицист, Муса Җәлил премиясе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан язучылар бүлеге әгъзасы

## КУРКЫТМАГЫЗ КОШЛАР АВАЗЫН. 2002 ЕЛ ШИГЪРИЯТЕНӘ БЕР КАРАШ [14]

Соңгы елларда безнең шигърияттә ике бик кызыклы шагыйрь пәйда булды. Аларның берсе Шәүкәт Гаделша – Себер ягында туып үскән егет. Ул безгә шул якның исен, әле мәҗүсилектән тәмам чыгып

[14] Зәйдулла Р. Куркытмагыз кошлар авазын: 2002 ел шигъриятенә бер караш // Казан утлары.– 2003.– № 7. – Б. 152.

бетмәгән җанын алып килде. Шәүкәтнең язу манерасы да бөтенләй бүтән – ул безнең гарәп-фарсы әдәбиятларына тоташкан бай әдәби мирасыбыздан бигрәк, борынгы төрки шигърияткә, фольклорыбызга таяна шикелле. Аның рухы тере табигатькә береккән:

*Менә монда болан ауган –*
*Ята-ята усак булган.*
*Әнә анда куян яткан –*
*Ята-ята куак булган.*

*Үсә каен, нарат, балан,*
*Күрәм тагын эт шомыртын.*
*Агач кочып уйланамын:*
*«Мин егылсам, ни булырмын?»*

**Рәдиф Гаташ,**

шагыйрь Татарстан Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

## ШИГЫРЬДӘГЕ СЕБЕР ДӘ – ҮЗЕБЕЗНЕКЕ[15]

Шәүкәт Гаделша исеме шигърият сөючеләргә инде шактый таныш. Һәм, Булат Сөләйман кебек үк, Себер татарларының олуг татар шигырендәге тансык бер вәкиле буларак, икеләтә кадерле, аерым дикъкатькә лаек, дип исәплим мин. Ялгышмыймдыр… Моңарчы Себер ягыннан Казанга килгән олуг шәхесләрне искә төшерик. Юк, өйләнергә килгән «Себер бае»н түгел – «безнең шәһәрнең серләрен» белеп, күреп, ул фәкыйрьнең гайрәте чигә, кире иленә кайтып китә… Әйе, сәүдәгәрләрне, Эрбет кебек атаклы базар урыннарын да әйтмим. Беренче чиратта уема Рәшит Ибраһимов кебек атаклы шәхес килә, татарны уяту юлында «тарихи кыңгырау» булып, бөтен дөньяны урап чыккан, мөселманлык һәм татарлык байрагын хәтта Япониядә дә югары күтәргән, искиткеч энергияле-дәртле, тынмас көрәшче җанлы, сәях рухлы казый бабабыз ул! Менә кемдә булган атаклы «Себер ныклыгы»! Аның юлын дәвам итүчеләр – галимнәр, бигрәк тә тарихчылар, фольклорчылар булды: Хәмит Ярми, Фатих Урманче, янә Флора ханым Урманчелар…Гаҗәеп рухи байлыклар – үзенчәлекле дастан-

[15] Рәдиф Гаташ. Шигерьдәге Себер дә – үзебезнеке // Яңарыш.– 2003.– № 85–86 (1128–1129), 24 октябрь. – Б. 7.

нар, әкиятләр, җырлар калыкты, гүяки гасырлар төпкеленнән бүгенге шигырь нигезендә яткан борынгы мифлар, төркичелек атрибутлары, тәңречелек, мәҗүсилек сурәтләре кайтты. Язма әдәбияттән, Ислам һәм Көнчыгыш традицияләреннән үзгә борынгы ташъязмалар, әнкә ватан – Алтай, Себер мәдәниятләре телгә килгәндәй булды.

Һәм бу – һичшиксез, шагыйрьләргә, бүген без яңа китабына күзәтү ясарга җыенган Шәүкәт Гаделшага да карый. «Җилгә моң дыңгычлыйм» дип атала аның яңа китабы («Идел-пресс» нәшрияте, 2003 ел). Исеме бераз сәеррәк. Әмма Шәүкәтче, Себерче: моңа кадәрге китаплары да «Ярык мөгез», «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм» дип атала иде. Исемнәрендә үк – Себер мохите, табигате, аучылык, балыкчылык дөньясы… Өр-яңа шигъри дөнья! Моны Шәүкәт әле яшь чакта университетта укып йөргәндә үк тоеп алдылар. Хәсән ага Туфан, сөенеп, яшь егетнең җилкәсеннән кагып, фатиха бирде; укытучысы Мөхәммәт Мәһдиев җылы кереш сүз язып, бер бәйләм шигырьләрен яшьләр гәзитендә бастырды *(шул* шәлкемнән – агач чукып утыручы тукран һәм шуны санап ярын көтүче егет образы хәтердә калган). Бераз югалып, күзгә күренми дә торды Шәүкәт. Баксаң, ул туган якларында эшләп, чыныгу алып, Себер шигъриятен җанына ныграк сеңдереп, рухи үсеп, ныгып кайткан икән. Хәзер дә әллә нинди төзелешләрдә прораб, «түрә булып», без белмәгән хезмәт-тормыш эчендә кайный. Әмма яза, күп яза, китап арты китап белән сөендерә. Иң мөһиме, әлеге Себер дөньясы – тарихи татар дөньясының бер өлеше, һич аерылмас рәвештә, шигырьдә чагыла. Яңа китабында да шулай. Анда – безнең тарих, һич тә үзгәрмәгән, милли аң-рух, тере хәтер ята.

*Ята монда хәзинә,*

ди Шәүкәт, Себер ханлыклары чорыннан калган матди һәм рухи байлыкларга ишарәләп. Ләкин кагылмый:

*Иректән мәхрүм халыкның*
*Ирексез алтыны да,*

ди ул. Аның сызлаулары тирәннән, без һич көтмәгән яктан килеп чыга:

*И Себер татары, ни диим?*
*Бары тик Ермакны, Күчемне*
*Тарихта калдырыр өченме*
*Дөньяга, бу җиргә син килдең?*
*Икенче бер шигырьдә шагыйрь:*
*Моң-зарларны тыңлыйм да мин, күңел елый,*
*Ия түгелмен күк үз-үземө*
*Дан җырларга гына кала – Себер*
*Татарның мәүс түземең – ди.*

*Һәм:*
*Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында*
*Учак ягып бераз ятканым бар.*
*Сүлпән булды, ахры, учакларым –*
*Өермәләр килеп капмадылар.*

Әмма мондый уйлар, настроение белән генә шигырьне чын сәнгатьчә югарылыкка күтәреп булмас иде. Юк, Шәүкәттә иң үзенчәлекле, башкалардан аерып торган сыйфат – әнә шул Себер җиренең, табигатенең җаны булып, шуңа әверелеп, уйлый, сөйли белү сәләте. Мәҗүси шигърият, урман, ташлар, елга-күлләр, күк, Тәңре теле бу! Әнә нәрсә ди ул «Мәҗүси зары»нда:

*Акыл гына тыя:*
*«Аңламаслар сине,*
*Бу – Аллалы дөнья».*

Һәм әнә нинди каршылык яши икән яшь кешенең, димәк, шагыйрьнең дә җанында:

*Юк, Аллама үпкә*
*Белдерәсем килми:*
*Өнем... агачтан сын*
*Юнәтергә димли.*
*Мин табынсын диме?*

Рафаэль Бәзертдинов укыса, тәңречелек дияр идеме моны, әллә мәҗүсилекме? Бәлки, шаманчылык дияргәдер? Потка табыну чорлары бик еракта калган бит инде. Себер кешеләре канында тибәме соң әллә ул үткән ерак чорлар? Игътибар итик әле:

*Тамырымда каным гөлт-гөлт итә,*
*Ылысларда нурлар ыңраша.*
*Берсе – карт наратта, берсе – миндә,*
*Тыңла: ике шаман ымлаша.*

Әйе, бу – табигатькә табыну, аның аша пакьләнү, рухи тазару һәм башкаларны да имләү, мөгаен. Менә шуңа күрә дә, агач ботаклары шикелле тырпаеп, кочакта тырнап торган шигырь кытыршылыкларын да – шигъри дөньясының бербөтен булуы, барсы да бер мәҗүси Матурлыкка – Шигърият белән бәйле кырыс тормыш чынбарлыгына буйсынган эчке бер көч оныттыра, әсир итә кебек.

*Йоклый Себер татары,*
*Карга чумып, уралып.*
*Боз астында, тирәндә*
*Тончыга… алтын балык.*

Менә шундый сурәтле киная! Ә якташы портреты?

*Маңгаенда җыерчык –*
*Табан балык чумарлык.*
*Йөзендәге кырыслык –*
*Елан коты очарлык.*
*Күзендәге кысыклык –*
*Ташның суын сыгарлык.*

Ләкин нинди якын, үз ул шагыйрь җанына! Тыңлыйк әле аны:

*Шул якташтан җаныма*
*Канәгатьлек үрелә:*
*Туган якның иң үзәк*
*Тамыры булып күренә.*

Сүз җаеннан: никадәр генә мәркәз Казанны, Татарстанны яратмасын, аңа рәхмәтле булмасын, Себердән килгән шагыйрь җаны барыбер бу як табигатен, кешеләрен, хәтта дусларын, аларның далага хас холкын, гадәтләрен гаҗәпләнебрәк тасвирлый (Газинур Морат белән ауда йөрүе турындагы шигырен генә укыгыз әле!), һаман үзе күнеккән мохит, үзен үстергән һава – аураны сагына кебек:

*Күк томан эчендә «дөп тә дөп»,*
*Тышаулы елгырлар килә күк.*

Әмма… тагын каршылыклы уй, цивилизация китергән аянычлы төсмерләр:

*Әнә шул атларны чүктереп атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Шуңа да ул «ат авызын тыңлый», ә ат авызында тирән кое… анда – җил, кайсы гасырдан ул?

*Ат белән маңгай терәшеп,*
*Әллә бер еларгамы?*
*Ир еласа, димәк, күпне кичереп тетрәнү халәте анда!*

*И ай, мә, кадал, дип, хәнҗәрдәй*
*Очланып, сузылмый син торчы!*
*– ди бу күңел.*
*Яки бөтенләй яңача сурәт туа:*
*Бу арада ай-яй кыен*
*Замандашым карт ага.*
*Кычкыра алмый газаплана –*
*Тиздән, ахры, агара…*

Мисаллар күп булды бугай, әмма бу шагыйрьдә бик сирәк мәхәббәт шигырьләренең дә фольклорча төгәл, матур һәм мәҗүси сурәтләр белән үрелүен әйтеп узасы килә:

*Алка итеп, йөзек итеп*
*Күрәм төннең алтын аен.*
*Бичәм ята аңа карап –*
*Сиңа бүләк итәлмаем,*

– ди лирик герой, ерак сөйгәнен яшерен генә уйлап. Яңача бит!

Шәүкәтне күреп белгән, аралашкан кешеләр бу шагыйрьнең шәхес буларак та киң күңелле, юмарт, ярдәмчел һәм чын милли җанлы, тәвәккәл ир-егет икәнен яхшы беләләр, дип уйлыйм.

*Күрәм кеше күңелләрен –*
*Тыңлап күңелемне,*
*– ди ул үзе бу хакта.*
*… Рәхәтләнеп калам.*
*Себер татарларын шулай*
*Яраткан бит Аллам,*

– дияргә дә онытмый. Күбрәк булсын шундый шәп егетләребез, дип тә өсти алабыз без, шагыйрьне инде укып та белгәннәр, каләмдәшләре…

Ә шагыйрь турында дуслары-кордашлары Г.Морат һәм Р.Зәйдуллаларның бик матур фикерләр әйтеп язып чыкканы хәтеремдә. Ш.Гаделша иҗаты турында сөйләшү – шагыйрьләр остаханәсе утырышы да бик җанлы узган иде, ансын да онытмыйм. Фикерләр кызыклы, әмма бердәм иде: бүгенге татар шигырендә – Себер исеме белән тансык, матур шигъри дөнья тудырган үзенчәлекле шагыйрь Шәүкәт Гаделша да бар. Яңа китабын укыгач та, шул фикерем ныгыды: әйе, шагыйрь – бар, һәм ул дәвам итә. Игътибар итик, укыйк без аны! Ә «Себер – үзебезнеке» ул! Безнеке.

**Роберт Әхмәтҗан,**
шагыйрь һәм публицист, Г.Тукай
исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның
атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

## ҖИРСҮ[16]

*(Ырулар рухына шигъри дога)*

Шәүкәт Гаделша дигән шагыйрьнең иҗатын беренче шигырьләреннән алып күзәтеп барам. Әлеге шагыйрь, беркемгә дә охшамаган гаять үзенчәлекле иҗаты, темалары һәм иҗат алымнарының яңалыгы белән үзенә җәлеп итте. Шигърияткә ул җиңел генә килде дип булмый, ул аңа «кайта-кайта» килде дияр идем. Чөнки, студент елларында ук үзенчәлекле шагыйрь килә дип көткәндә, кинәт, башлангыч «мирасын» төяп, үзенен Төмәненә, аныц урман-кулләре, җәнлекләре дөньясына кайтып китте. Әмма бу «югалу» тикмәгә генә булмаган икән, шөкер. Шәүкәт Гаделша бу юлы әйтерсең лә Себер Иленең зәңгәр урманнарын, җәнлекләре дөньясын, могҗизалы төннәрен, нәсел-ыруының фатихасын, йолаларын, гаять бай халык иҗаты мирасын төяп кайтты! (Бу урында шагыйрь өчен «кайту»мы, «килүме» булгандыр?) шигърияткә булгач, әлбәттә, «кайту» була инде! Аның «Ярык мөгез» дигән беренче шигырьләр китабында күңелгә тирән уелып кергәне утә дә кыен язмышка тап булган болан иде. Шәүкәт Гаделша, уеннан уймак дигәндәй, үзе дә сизми калып бугай, реаль күзәтүләрен гомумиләштереп, боланның классик образын тудыра алды. Анда: «Йөгерә ата болан, куакларны ярып; җанына тынгы бирми мөгездәге ярык. Җил иссә, кубыз булып суза башлый ярык, ана болан чакырган авазлар чыгарып…».

Менә шул табигый инстинкт чакыра, куа газаплый болан бәгырькәйне! Ниһаять, ул чакыру авазын куып тоталмыйча егыла. Нинди фаҗига! Шагыйрь бу образдан гаять оста файдаланып, шигырьне көтелмәгән гомумиләштерү белән очлап куя – үзен шул болын үгезенә тиңләп: «шул үгез хәлендә бит, дуслар, мин үзем дә. Ахыры, ярык булган хыял-мөгезем дә!» – дигән тирән мәгънәле фәлсәфи нәтиҗә ясый. Шагыйрьнең мондый табышлары кайбер шигырь сөючеләрнең күзләренә чалынмый калмады, әлбәттә. Әмма мондый табышлар Шәүкәт Гаделша иҗатында ялгызак түгелләр, алар – бихисап. Монна исә әлеге иҗатка игътибар күбрәк кирәклеге аңлашыладыр.

Соңрак дөньяга килгән «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм», «Җилгә мон дыңгычлыйм» дигән шигырь китапларын да укучылар күрми

[16] Әхмәтҗанов Р. Җирсү // Аучы җыры / Ш. Гаделша. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 5–10.

калмагандыр. Шигырьләренең уникальлелеге, алардан яңача сурәт, аһәң, сурәтләү чараларының байлыгы – үзе бер кабатланмас поэтик дөньяны тудыра. «Әлбәттә, шигъри сурәт эчке халәттән туа. Әмма тышкы форма ул әле бары бизәк кенә. Әгәр дә без Шәүкәт Гаделша дигән шагыйрьнең иҗат хосусиятен, аның асылын аңларга-аңлатырга телибез икән, иң элек ул яшәгән мохиткә үтеп, шул җисми вә рухи дөньяны аңларга тиеш булабыз. Чөнки, һәр мохитнең, тирәлекнең үз тормышы, үз биокыры барлыгын, ә моның шагыйранә шәхес психологиясенә тирән йогынтысы зур икәнлеген исбатлап торасы юк: әйтик, сандугачның сайрый торган үз талы бар икән, ул да яраткан тирәлегендә генә сайрый. Табигатенә карап моңы үзгәрә сыман. Себер, Төмән яклары бездәгедән кырысрак, әмма мул табигатьле, анын үз куены, үз моңы… Минем табигый кыргый мохитнең күңелхис дөньясына тәэсирен Төньяк Казагыстанның язгы ярсу болганчык Иртешенә карап уйланып утырганда тойганым-кичергәнем бар. Иртеш, Тубыл елгалары – олуг тарих үзәне! Кошлар язмышыдай татар халкының гомерлек миграциясе кайдан килә? Русиянең борын-борыннан килгән колониаль сәясәтенең кыргый «Җимешләре» болар. Вак милләтләрне, бу очракта татарларны таркатып, даими күчереп утыртып, аларны бер төбәккә туплап, үзенә бер «көтүлекләр» ясап, шул рәвешчә табигый «ау зоналары», «тыюлыклар»га охшаш резервацияләр булдыру аркасында килеп чыккан болар. Моннан исә патша режимы күзәт-челәренә ошбу милләткә «күз-колак» булып тору күпкә ансатлаша. Мондый резервацияләргә бары төрле миссионерлар гына кыю үтеп керә алган. Урман-күлләр-сазлыклар куенында утырган Себер татарлары җирлегендәге төрле серле-серле, мәҗүсилеккә якын атамалар, ырымнар, тотемнарга табынулар әнә шул ыруглыкка якын яшәештән барлыкка килгәндер. Татар гомер-гомердән җир асларына төшеп эшләгән, мартен ялкыннарына руда беләን бергә кергән, Демидов металл заводларында, алтын приискаларында бил бөккән, Петр патша заманында лашманчы булып кораб төзелеше өчен имән урманнарын кисеп тураган, Петербургның нигезенә татарның сары сөякләре түшәлгән. Тарих кая китсен ди? Шунысы да бик мөһим бу урында: шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның атасы ягыннан бабасының сөрелгән Казан татары булуы, әнисе ягыннан бабасының исә Себер ханнары нәселеннән килеп чыгуы мәгълүм шәҗәрә әнә шундый. «Җан тартмаса да, кан тарта», – ди халык. Шәүкәт Гаделша моны сизеп яши, әнә шуңа да аның Себер ханы Күчүм кебек, туган туфрагына аяк терәп яшәргә, горурланып сөйләшергә хакы бар! Моңа мисаллар аның иҗатында тулып ята. Аның лирик герое һәрчак юмарт холыклы, кешеләргә ярдәмчел:

*Бирәм соңгы серәнкәне,*
*Соңгы телememне.*
*Күрәм кеше күңелләрен,*
*Тыңлап күңелемне.*
*Кызганмыйм да, үкенмим дә,–*
*Рәхәтләнеп калам.*
*Себер татарларын шулай*
*Яраткан бит Аллам.*

Шагыйрь үз ягын, үз тарихын белә генә түгел, ул аны һәр күзәнәге белән сиземли, тоя. Шагыйрьнең рухи табигатен ул яшәгән табигатьтән аера алмыйсың. Шагыйрь табигатьне «өстән» яки «тышкы яктан» гына тасвирлаудан ерак, үзенең туган төбәген, халкы яшәешен, аның тарихын әледән-әле иҗтимагый-сәяси югарылыкка күтәрә, шигырьләр чынбарлыкка якынлаша, чорның чалымнары күз алдында пәйда була:

*Күк томан эчендә «дөп» тә «дөп»,*
*Тышаулы елгырлар килә күк…*

***
*Җилфердәп китмәсме сөңгедә*
*Күчүмнең ак кыллы бунчагы.*
*Болгана каршымда күк томан.*
*Белмимен: артымы, алдымы?*
*Атларны чүктереп атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Шагыйрь табигатьнең яшерен серләрен ачарга омтыла, моны ул булдыра алуына да ышана. Әмма, мәҗүсилек калдырырга ярамый дигән кебегрәк нәтиҗә ясый. Шигъри мантыйгын Себернен хуҗасы – чын Себер татары дигән нәтиҗә-фикергә китереп ялгый:

*Сизә күңелем, әй, сизә:*
*Ята монда хәзинә.*
*Күчүмнеңме? Кайсы ханның?*
*Әйтә алмыйм хәзергә.*
*Сизсәм дә кайда ятканын,*
*Теләмим кагылырга.*
*Иректән мәхрүм хатынның*
*Ирексез алтыны да.*

Әйе, Шәүкәт Гаделшаның иҗаты хакында, шигъриятенең хикмәтле яклары, гомумән, татар поэзиясендә Шәүкәт Гаделша феномены хакында фикерләр дә булмады түгел. Әмма аны өстән-өстән әйтеп китү бер хәл, ә менә чынлап торып әлеге иҗатны фәнни яктан өйрәнү Себер татарларының поэтик тел җәүһәрләрен өйрәнүгә дә зур өлеш кертер иде. Киләчәктә әлеге эш үз галимнәрен дә табар әле, бәлки. Эш җиңеләер: фольклор экспедицияләре белән ерак Төмән төбәкләренә дә барып чыгасы юк – халык иҗаты бизәкләрен шул ук Шәүкәт Гаделшаның иҗатыннан күпләп чүпләргә мөмкин! Чыннан да, шагыйрьнең кайсы гына шигырен алсаң да, һәрберсендә бер табыш, шигъри «орлык», фикри оеткы – шуларнын һәркайсы кабатланмас халык авыз иҗаты гыйбарәләренә якын. Фәнни эзләнүләр өчен бу үзенә бер «чирәм җир» кебек әле. Шагыйрьнең һәр шигырендә кешенең рухи халәте табигать халәтенә ярашлы, тәңгәл рәвештә җанлана:

*Камышка камыш ышкыла,*
*Җилсез-нисез ышкыла –*
*Әйтерсең яшеренеп яткан*
*Ат табуны пошкыра.*

Яки менә әлеге ярашу-тәңгәллекне тагын да җетерәк раслаучы юллар:

*И, Казаным!*
*Шатлык килде!*
*Аяз күгең охшый бүген*
*Улын имезеп ләззәтләнгән*
*Болан күзенә…*
*И, Казаным,*
*Кайгы килде…*
*Аяз күгең охшый буген*
*Чебен күреп киерелгән*
*Елан күзенә.*

Табигать аһәңен, аның психологик сурәтен әнә шулай гаятъ оста, нечкә тоемлый шагыйрь.

Себернең кыргый табигатен, аның халкын сагынып җирсү – шагыйрь иҗатының төп лейтмотивы. Ул хис-тойгыны, шулардан кабынган шигъри утны шул җир-туфракның бердәнбер аборигены сыман, шигырьдән шигырьгә күчереп кабыза бара, аңа сүнәргә һич ирек бирми! Ә бу ут исә, шагыйрьнең Иҗат Чырагына әйләнеп, отыры көчәя генә бара.

Шәүкәт Гаделшаның ике рухи төбәккә – Казанга һәм Төмәнгә тартылуы бик тә табигый хаҗәт:

*Кайсы якта черегән*
*Ыруымнын казыгы?*
*Яшьнең иң гөнаһсызын*
*Кайсы якка агызыйм?*
*...Казан, Төмән арасы –*
*Мәгънәм минем, канатым...*

Шагыйрь иҗатындагы тагын бер характерлы вә әһәмиятле якны: аның хис-тойгыларының импульсив булуын, әмма нәкъ әнә шул ягы белән кыйммәтле икәнлеген әйтергә кирәктер: чөнки аларда табигый информация мул. Икенче терлерәк, образлырак итеп әйтсәк, «иләнмәгән, кисәкле алтын, самородок» кайчак мохитне, тарихилыкны ачыграк чагылдыру сәләтенә ия. (Бу очракта, әлбәттә, Себер татарларының яшәешен, ырым-йолаларын, иҗатын, тарихын ачу ягыннан.)

Шәүкәт Гаделшаның иҗаты хакында язган кайбер мәкалә авторлары аның мәҗүсиләргә хас тасвирына игьтибар иттеләр. Минемчә болайрак: һәрбер шагыйрьдә азмы-купме мәҗүсилек рухы яши. Чөнки шагыйрь Табигатькә башкаларга Караганда да күбрәк бәйле. Ул аның иҗатына, яшәешкә азык бирә. Ул илаһиятне, шигьриятне турыдан-туры Ходай Бакчасы булган Табигать-Анадан ала. Аны шагыйрьнен Музасы дигәннәр. Муза, музыка, аһәң!..

Шагыйрьнең аһәңнәрен тыңлыйк:

*Яшь торна оча алмый,*
*Тилмерә үзәндә.*
*Тәпие чорналган*
*Энәле үләнгә...*
*...Йөгерә ач төлке*
*Торнаны кабарга.*
*Алдарак мин чабам –*
*Коткарып калырга.*

Яисә менә гаҗәеп тыгыз, гыйбарәгә якын халәт:

*Чумышалар балыклар:*
*Алтын, көмеш төслеләр.*
*Кичә баткан бәхетне*
*Бик тырышып эзлиләр.*

Шагыйрь табигатьне – агачларны, суларны, хәтта ташларны җанландыра, илаһилаштыра. Менә шигъриятнең узеннән үк туган тотемнар белән эш итү ысулы килеп чыга инде. (Бу яктан чын Табигать уллары булган Америка индеецлары яшәешенә ишарә дә җиткән.)

Табигый ки, цивилизациядән никадәр ерагаеп, табигатькә шулкадәр сыенып яшәсәң, бу сыйфатларның тагын да көчәюен исбатлап та торасы юк.

Шунысы куанычлы: татар шигъриятендә өр-яңа, гаять үзенчәлекле, уникаль шагыйрь Шәүкәт Гаделша китаптан китапка үсә, ныгый, тирәннән ачыла, укучысына якыная бара. Аның тынгысыз карашы, тәвәккәл сунарчы кебек, ерак-еракка, яңа иҗат офыкларына төбәлгән. Һичшиксез, шагыйрь шул офыкларга барып җитәр, яңа биеклекләргә менәр дип ышанам. Чөнки аның мөмкинлекләре моңа ышандыра алырлык.

Укучы хөкеменә тәкъдим ителгән ошбу сайланмалар рәвешендә дөнья күргән яңа җыентыгы шагыйрьнең гомер тәҗрибәсенә, тынгысыз олы хезмәтенә нигезләнгән беренче күләмле китабы. Иҗади эзләнүләр нәтиҗәсе булып дөньяга китап тууы – Шагыйрьнең тууы кебек күркәм вакыйга, иҗат бәйрәме ул!

Шәүкәт Гаделшаның шигърияте легендалар вә дастаннар иле – Себернең җир-суына, урман-күлләренә, киек-җәнлек дөньясына, ырулары рухына Шигъри Дога булып ишетелә! Киләчәктә мондый игелекле шигъриятнең кайтавазлары буласына да шигем юк.

**Диләфрүз Фәхретдинова,**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты,
Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## ҖИЛГӘ МОҢ ДЫҢГЫЧЛЫЙМ[17]

*И, Себер татары: ни диим?*
*Бары тик Ермакны, Күчемне*
*Тарихта калдыру өченме*
*Дөньяга, бу җиргә син килдең?*

Шәүкәт Гаделша

Шушы көннәрдә «Яңарыш»ның якын дусты, ярдәмчесе, Казанда яшәүче себер шагыйре Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) редакциягә бүләк итеп үзенең дүртенче китабын җибәрде. Соңгы берничә ел эчендә аның «Ярык мөгез», «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм» дигән китаплары дөнья күргән иде, ә менә бүген шагыйрьнең яңа бастырылган «Җилгә моң дыңгычлыйм» исемлесен кулыбызга алырга насыйп бул-

[17] Фәхретдинова Д. Җилгә моң дыңгычлыйм // Яңарыш.– 2003.– № 75–76 (1118–1119), 19 сентябрь. – Б. 7.

ды. Ул бу китабында үзенең яңа шигырьләрен туплаган. Аларда рухи матурлык, югары әхлак, туган илгә мәхәббәт, табигать яме күрсәтелгән. Шигырьләрне укый башлау белән күзгә Себер рухы, аның табигате, кешеләре, аларның гореф-гадәтләре, йола-холыклары ташлана. Шагыйрь табигать матурлыгын туган җире Киндерлесенең каз-үрдәкләре, этләре, төлкеләре, куяннары, шаулап торган каеннары, иген-кырлары, сазлык-күлләре аша тасвирлаган.

*Бик матур бер авыл бар –*
*Менә шунда мин туган…*
*Алан саен-карлыган,*
*Агач саен кош кунган.*
*Кычытканнар, әремнәр –*
*Әйтерсең, генераллар,*
*Нурга ничек балкырга*
*Әмер биреп торалар.*

Шушы юлларда шагыйрьнең туган җирнең байлыгына соклануы, аның белән горурлануы күрсәтелә. Туган илнең кычытканнары, әремнәре дә кадерле бит, аларга тиң берни юк сыман.

«Җилгә моң дыңгычлыйм» дигән җыентыктагы шигырьләрдә табигать тә, тирә-яктагы дус-ишләр, авылдашлар да, автор үзе дә бар, анда бөтен тирә-юнь сыйган һәм аларга шагыйрьнең мөнәсәбәте чагылган.

*Син дә, Фатих, сизәсеңдер:*
*Ничек тиз үтә вакыт?!*
*Әле кайчан гына сазда*
*Без чөрәгәйләр аттык.*

Шәүкәт Гаделша озак еллар Казанда яши, ел саен туган авылына Корбан чалырга кайтып авылдашларын куандырып китә. Якташлары аңа чын күңелдән рәхмәтле.

Чит җирдә яшәгән кеше генә кече Ватанының нинди ямьле, тансык, кадерле икәнлеген аңлый. Шәүкәт абый да Себергә бик сагына, аның сулышын тоеп, тормыш агышын сизеп яши. Моны без аның шигырьләрендә күрәбез:

*Олау-олау яфрак ява*
*Юл буенда каеннан.*
*Очка менгән борындыктан*
*Сызгырмавьн ялынам.*
*Ләззәт булып оча тора*

*Ашыгуның ялкыны.*
*Очкан казлар миннән сорый*
*Борынгы җыр, ялынып.*
*Үзем дә бит телим аны -*
*Көтәм сусап, сагынып.*
*Китәр идем туган якка*
*Яңрашына салынып.*
*Каеннардан яфрак ява.*
*И ява ла олаулап!*
*Сызгырмаган борындыкка*
*Баш иямен, олылап.*

Ләкин ничек кенә туган ягын яратса да, Казан аның иҗади Ватаны. Монда Шәүкәт Гаделшаның шигърияткә булган олы юлы башланган, китаплары дөнья күрде. Ул Татарстан язучылар берлеге әгъзасы. Без үзебезнең Себер шагыйребез белән горурланырга, аның иҗатын хөрмәт итәргә тиешбез.

**Азат Сәгыйтов,**
Төмән өлкәсендәге *«Яңарыш»* газетасы беренче баш мөхәррире
(2005 елга кадәр)

**Р.КОРБАН: «ИҖАТ ЧИШМӘГЕЗ САЕКМАСЫН!»**[18]

«Яңарышшың алдагы саннарында белдергәнебезчә редакция каршында оештырылган «Әдәби җомга» иҗат клубының чираттагы утырышында күренекле Казан шагыйрьләре Рафис Корбан, Газинур Морат һәм Шәүкәт Гаделша катнаштылар. Аларның максаты – безнең Төмән шагыйрьләре белән танышу, профессиональ гәп кору һәм практик ярдәм күрсәтү иде.

Төмәнгә сәяхәтләре турында Казан шагыйрьләре әле бәлки үзләре дә язып җибәрерләр газетага. Ләкин алар инде үз фикерләрен әйтеп кайттылар.

– Ерак Төмән җирләрендә милләттәшләре безнең шулай бердәм, дус-туган һәм нәкъ татарча кунакчыл булып яшәүләренә без бик шат, – диделәр өчесе дә бер аваздан. – Иң куанычлысы – милли йөзебезне югалтмыйча, туган телебездә барыгыз да матур сөйләшәсез, үз телебездә чыга торган татар газетабызга шигырьләр, матур-матур мәкалатләр язасыз, җыр – моңнарыбызны, милли традицияләребезне онытмыйсыз икән. Рәхмәт сезгә ерак-якын туганнарыбыз…

---

[18] Сәгыйтов А. Р.Корбан: «Иҗат чишмәгез саекмасын!» // Яңарыш.– 2004.– № 6 (1153), 6 февраль. – Б. 1, 2.

Ни-нәрсә күреп, нидән чыгып алар мондый фикергә килделәр соң?

Татарстан кунакларын җирле эшмәкәр, татар җанлы милләттәшебез Рәшит Сафит улы Сәламов үзенең Ямбай янынннан уза торган олы юл буенда күнгән түгел заманча итеп төзелгән заправкасының кунакханәсендә урнаштырды. Һәм аларга сый- хөрмәт күрсәтеп, ике кон буена үзенең шәхси машинасында теләгән җирләренә йоретте. Хөрмәт күрсәтте, үзен дә, безне дә татарстанлыларга таныттты. Кунаклар һәм барлык редакциябез исеменнән Рәшит Сафит улына шундый миһербан-шәфкатьлелеге өчен зур рәхмәт әйтәсе килә.

Төмән татарлары белән очрашу иң беренче Ямбай музееннан башланды. Һәм музей директоры Венера Әдиятовна Биктимерова киләчәк барлык очрашуларга да дөрес тон бирде. Музей каршында оештырылган «Милли моңнар» җыр ансамбле ханымнары кунакларны җыр белән каршыладылар, җыр җырлап озатып калдылар. Җылы милли очрашуда авыл советы рәисе Хәмзә Мисбах улы Бандуков та катнашты. Ул шагыйрьләргә истәлек итеп Булат Сөләймановның шигырьләр җыентыгын бүләк итте. Музей хезмәткәрләре Айния ханым Алтынгузина, Роза ханым Алимбаева һәм Венера апа үзе дә тирән эчтәлекле итеп музейның экспозицияләре ту рында сөйләделәр.

Менә нинди сүзләр язып калдырган шагыйрь, А.Алиш премиясе лауреаты, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире музейдагы «Отзывлар» дәфтәрендә: «Ямбай музеен күреп, мин, Казан артында туып-үскән егет, үземнең бала чакка, үз туган авылыма әйләнеп кайткандай булдым.

Рәхмәт сезгә шулай татар тормышын тулы, матур итеп чагылдырган музей төзеп, халкыбызга тарихыбызны искә төшереп торганыгыз өчен.

Изге эшегездә зур уңышлар телим».

Ямбайда булып, әле яңа гына ачылган мәдрәсәне күрми китсәләр, билләһи, гөнаһ булыр иде. Без анда кергәндә шәкертләр барысы да үзлектән генә дәрескә хәзерләнәләр иде. Укулар әле алдан планлаштырылганча тулысынча алып барылмый икән.

Әлегә безгә гарәп графикасын, тәҗвид өйрәтәләр, *– дип сөйләделәр шәкертләр.* – Укытучылар әлегә аз. Татар, рус телләре, тарих – география әлегә укытылмый…

Ә уку-укыту эшләрен алып бару өчен барлык шартлар да булдырылган. Җылы, якты бүлмәләр, заманча яңартып эшләнгән торак, ашханә – болар барысы да укуларны беренче көннән үк тулы канлы итеп алып бару өчен эшләнгән.

Татарстанда заманча итеп матур төзелгән мәчет-мәдрәсәләр күп, ләкин мондый борынгы искиткеч күркәм мәчетләрдә әле булганыбыз юк иде, *– диештеләр шагыйрьләр барысы да.*

Икенче очрашу – шагыйрьләрнең Төмәнгә килүенең төп максаты – «Яңарыш» каршында оештырылган «Әдәби җомга» иҗат клубы әгъзалары, Төмән шагыйрьләре һәм язучылары белән иде. «Мәдәни җомга» газетасының соңгы санында «Бездә – «Мәдәни җомга», Төмәндә – «Әдәби җомга» бар» дигән язма бастырылган. Әйе, бездә – «Әдәби җомга»!

Җомга көнне редакция күптән түгел күчкән яңа бинадагы редакторның зур гына бүлмәсенә Казан шагыйрьләре белән очрашырга килгән зыялылар барысы да сыймадылар, икенче бүлмәдә урнашып, ишек аша тыңларга мәҗбүр булдылар.

Килгәннәрнең барысының да исемнәрен атап тормыйча, ниндидер сәбәп белән килми калганнарның бик күп нәрсә югалтулары турында гына искәртәсе килә

Очрашу алдан планлаштырылганча барды. Башлап сүзне кунакларга бирдек. Алар, кыскача үзләре белән таныштырып, шагыйрьләребезгә шигъриятнең төп кануннарын, таләпләрен, җирле шагыйрьләрнең шигырьләрендәге уртак җитешсезлекләрне әйтеп үттеләр.

Тәнкыйтьләргә килмәдек, ярдәм итәргә килдек, – диде Рафис Корбан. – Әмма шуны әйтергә кирәк: рифмалаштырылган дүртьюллыклар әле алар шигырь дигән сүз түгел. Эчтәлек ягына да игътибар итәргә кирәктер. Менә безнең бу килүебез, сезнең үзегез белән якыннан танышып, шигырьләрегезне тыңлап, бергә-бергә уртак фикергә килү. Охшаган, җитлеккән шигырьләрегезне үзебез белән алып, бәлки, берәр җыентык кебек нәрсә дә бастыру уебызда бар…

Җирле шагыйрьләребез Заһит Акбүләков, Фәхриҗамал Утяшева, Гөлнур Хәйруллина, Клара Кучковская, Рәкыйп Ибраһимов, үзләренең кайбер шигырьләрен сөйләп, казанлыларны әсир иттеләр. Бик ошады аларга ул шигырьләр, кайберләрен үзләре белән Казанга алып кайтып киттеләр.

Очрашу бик җанлы, кызыклы үтте. Хәнисә ханым Алишина, Люция апа Хәбибуллина Татарстан шагыйрьләре һәм аларның шигырьләре турында өстәмә мәгълүмат бирделәр. Ә Шәукат Гаделша шундук үзенең Хәнисә ханыма багышланган шигырен укыды. Вакыт кысынкылыгы аркасында әле күп әйтелмәгән сүзләр, файдалы фикерләр әйтелмичә калдылар.

Шул көнне Казан кунакларын өлкә Думасы рәисенең урынбасары Г.С. Корепанов һәм шәһәр Думасы депутаты Р.С. Зиһаншин белән очрашу да көтә иде.

Очрашуны, Ришат Сабировичның тәкъдиме буенча. Кырынкүл мәктәбендә оештырдык. Бу безнең шәһәрдә бердәнбер саф татар укытучылары гына эшли торган әлегәчә иске мәчет бинасында урнашкан мәктәп. Шуңа күрә анда, һәр очрактан файдаланып, яңа мәктәп төзү проблемасың яңартып тору кирәк иде.

Һәм очрашуда сүз шуның турында да барды. Укытучылар, укучылар үзләренең сәләтләрен, казанышларын күрсәтеп, аларның да яңа мәктәп бинасында укырга лаеклы икәннәрен депутатларга һәм еректан килгән канакларга да күрсәттеләр. Депутатлар икесе дә хәлләреннән килгәнчә ярдәм итәчәкләрен белдерделәр.



***Кырынкүл авылы шәһәр депутаты Р.С.Зиһаншинның сайлау округына керә. Укытучылар сөйләве буенча, ул авыл халкы өчен дә һәм бигрәк тә мәктәп коллективы өчен бик күп эшләр эшләгән һәм дә эшли. Иске мәчет бинасында гына урнашкан булуына карамастан, мәктәп шактый гына җиһазландырылган, җылылык кертелгән, уку әсбаплары белән тәэмин ителгән.***

Боларның барысы өчен дә мәктәп коллективы шәһәр Думасы депутаты Р.С.Зиһаншинга үзләренең рәхмәтләрен белдерделәр.

Өлкә Думасы депутаты Г.С. Корепанов үзенең кунаклар алдындагы чыгышында азсызыклап тагын шуны әйтеп узды:

– **Мин,** – диде ул, – өлкәбездә татар хәрәкәте колач җәйгән елларда милли эшләр комитетында эшли идем. Татар теле-радиосын, газетасын ачуда да катнаштым һәм татар җәмәгатьчелеге белән дә күп эшләдем. Ә хәзер инде өлкә Думасына миңа яңадан шул эшләр белән якыннан шөгыльләнергә туры килә. Татарстан белән әкренләп булса да элемтәләр ныгый. Сезнең вәкилләр безгә, без сезгә еш кына барып-килеп йөрибез. Шуңа күрә Татарстан вәкилләре – күренекле шагыйрьләрнең безгә килгәнен ишеткәч, мин, әле бүген генә Мәскәүдән кайтып, сезнең белән очрашырга килдем. Рәхмәт сезгә – «Яңарыш» газетасы кунакларына, безнең җирле шагыйрьләребезгә ярдәм кулы сузуыгыз өчен. Киләчәктә дә шулай бергә-бергә эшлисе иде…

Саф татар кунакчыллыгын күрсәтеп, Кырынкүл мәктәбе укытучылары кунакларны үзләре өйләреннән пешереп алып килгән татар милли ашлары белән сыйладылар. Депутатыбыз Р.С.Зиһаншин да татар кунакчыллыгының иң югары үрнәген күрсәтте, ике көн буена «Газель» машинасы кунакларны Төмән шәһәре һәм районы буенча йөртте.

## И.Ф.КАРГАПОЛОВ: «ТАТАРЛАР ХЕЗМӘТ ЯРАТАЛАР»

– Казан кунакларына Талымханны күрсәтмәсәк, бу бик зур хата булачак, – дигән тәкъдим ясады безгә Ә.Х.Каюмов, аларга нәрсә күрсәтү турында сорау тугач.

31 көнне без иртән иртүк инде агрофирма директоры И.Ф.Каргаполовның кабинетында идек. Алар безне җирле хакимият башлыгы Н.Ф.Березин белән бергә каршы алдылар. Танышып, хуҗа безгә кыскача гына хуҗалык эшләренә экскурсия ясаганнан соң, сораулар туды.

Татарлар сездә бармы соң? Алар белән мөнәсәбәтләрегез ничек?

Минем өчен, дуслар, татарлар да, урыслар да юк. Мин кешене бервакытта да милләтенә карап бүлмим, – диде И.Ф.Каргаполов. – Ә инде татарлар турында сорыйсыз икән, шуны әйтергә тиеш. Татарлар хезмәт яраталар, тырышып эшлиләр. Әгәр син татарны дус итә аласың икән, ул синең иң якын, тугры дустың булачак. Ул синең өчен тау җимереп эшләргә дә риза. Ә татарларның ничек эшләүләрен һәм аларның эшләренең нәтиҗәләрен күрү өчен сезгә без бүген Талымхан авылын күрсәтәчәкбез…

Һәм без Талымханда! Анда безне бүлекчә җитәкчесе Раил Юскаев һәм мәдәният йорты директоры Раиф Сабиров каршы алдылар һәм иң башлап күлгә балык тоту процессын тамаша кылырга алып төшеп киттеләр. Кыш көне боз астыннан елым тарту – ул бик тә мәшәкатьле, шул ук вакытта үтә кызыклы да тамаша.

Җылым (елым) белән балык тоту балыкчылар өчен авыр хезмәт кенә түгел, зур осталык та сорый алардан. Ә инде гомердә (якташыбыз Шәүкәт Сибгатуллиннан башка) ул процессны күрмәгән Казан шагыйрьләренә бу чыннан да искиткеч тамаша булды. Елым канатларында беренче чорагайлар (щука) – загонщиклар да күренә башлагач, кызыксыну икеләтә артты. Нинди генә төр балык юк мәтнәдә (мотня) – алабутасы да, чуртаны да, шыртлакасы (ерш) да, хәтта кыслалар да бар икән бу күлда

Ләкин табан балык (кәрәкә) бу күлдә юк, чуртан ашап бетерә, – ***диде Шамил абый Юскаев.*** – Табан күрше күлләрдә генә. Ә менә суы чиста һәм төбе комлы булганга монда кыслалар яши…

Күлдә алган тәэсирләре турында мөгаен кунаклар үзләре язарлар, ә мин, шунда туктап, истәлеккә төшкән фотосүрәтләрне тәкъдим итәм.

«Яңарыш»та Талымхан балалар йорты, мәдәният сарае һәм яңа мәктәп турында шактый язылды. Балаларның барысын да карап чыккач, шагыйрьләр барысы да:

Татарстанда мондый мәктәпне күргәнебез юк, – диештеләр. Ә Шәүкәт, горурлыгын эченә сыйдыра алмыйча:

Менә бит, менә бит ничек яшиләр якташларым, – дип шатланды. – Мин 60 нчы еллар башында биредә башланган кызу эшләрне күргән идем. Ләкин алай да болай ук булыр дип һич күз алдыма китергәнем булмады.

Тырыш хезмәт нәтиҗәсе инде болар барысы да…

Казан кунаклары белән очрашырга теләүчеләр бик күп иде. Ләкин аларның кыска вакытка гына килүләре сәбәпле, барысы белән дә очраштырып булмады.

Алай да тагын ике җирдә булып, үзләре әйтүенчә «ләззәт хисләренә коенып» кайттылар шагыйрьләр. Балалар иҗат үзәге «Этнос»та башлап аларны аның «хуҗабикәсе» Венера ханым Хәйруллина үзенең нәфис-нәзакатле төс-кыяфәте һәм ягымлы сүзләре белән әсир итсә, ә инде үзәкнең бизәлеше, балаларның (бигрәк тә Эльвира Янбаеваның) җырлары, олы яшьтәге дөнья чемпионы З.Х. Низамовның үзе җиһазландырган махсус теле-радио кабинетта эшләве таңга калдырды.

Милли мәдәниятләр сараендагы татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Т.С.Мирасов күрсәткән себер фольклоры үрнәкләре шагыйрьләргә шулай ук бик ошады. Шундук «Әхтәмушкә ләрнең җырларын аудио-видео тасмаларга төшереп калырга кирәк дигән тәкъдимнәр булды.

Гомумән, кунаклар бик риза һәм шат булып киттеләр Төмәннән.

**Дания Заһидуллина,**

әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы фәннәр академиясе академигы, хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасы фәннәр академиясе вице-президенты, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премиясе лауреаты

## ШИГЫРЕНДӘ – СЕБЕР КИҢЛЕКЛӘРЕ[19]

Туксанынчы елларда әйләнә-тирәбездә һәм әдәбияттә башланган үзгәрешләр проза кебек иҗтимагый яңалыкларга сизгер зур жанрга гына түгел, поэзиягә дә тәэсир ясады. Аеруча 1970–80 елларда татар поэзиясе зур үрләр яулаган иде инде. Ул бигрәк тә кинаяле тел белән

[19] Заһидуллина Д.Ф. Шигырендә – Себер киңлекләре // Мәдәни җомга.– 2004.– № 6 (447), 13 февраль. – Б. 16.

җәмгыятькә тәнкыйди бәя бирүдә, зур фәлсәфи фикерләр белдерүдә, символик-метафорик сурәт тудыруда осталыкка иреште.

Демократия, хәбәрдарлык заманы килү кинаяле, эзоп телен арткы планга чигерде. Шигърият яңа сукмаклар эзли башлады. Әлеге мәсьәлә бигрәк тә поэзиягә килүчеләр өчен актуаль иде. Бу очракта яшь әдәбиятчеләрнең ике мәдәнияттә тәрбияләнүен, урыс поэзиясендәге яңалыкларны да күзәтеп баруын онытмаска кирәк. Ә урыс поэзиясе нәкъ менә 1990 еллар тирәсендә форма уеннары белән мавыгып китте, яңа бер барыш юлын кабат мәйданга чыгарды.

Шушы шартларда татар шигъриятендә, аңа килүче яшьләр иҗатында яңа, үзгә күренешләр пәйда булды. Болар турында сөйләшүне Шәүкәт Гаделша иҗатыннан башлыйсым килә. Чөнки бу иҗат модалы агымнар артыннан китеп түгел, шигъриятнең чишмә башына әйләнеп кайтып, үз кыйбласын, башкаларга охшамаган үз сукмагын билгеләде.

Шагыйрь татар шигъриятенә янә Себер темасын алып килде. Шушы теманы берничә мотив аша тәкъдим итте. Шуларның берсе – ау һәм аучы мотивы. «Йөз яшьлек аучы», «Аучы зары», «Аучы җыры» кебек шигырьләр укучыга яңа, күпмедер дәрәҗәдә экзотик булган дөнья ача. Йөз яшькә җитеп, күзләре күрмәс, колагы ишетмәс булган аучы фаҗигасе, авылдашының бозавын ботарлаган өчен аю атарга мәҗбүр ителгән аучы борчуы лирик геройның аңлаучан-яратулы мөнәсәбәте аша сүрәтләнә. Нәтиҗәдә, безнең әдәбият өчен ят булган аучы – урман-сулар, кош-җанварларны саклаучы, яклаучы, олылаучы – образы пәйда була.

Гомумән, бу иҗатта табигать, нәкъ менә Себер табигате образларына мөрәҗәгать итмәгән, шулар ярдәмендә халәт, ситуация тудырмаган шигырьне табып та булмас кебек. Хәтта Себер турында түгел, Казанга мөрәҗәгать кебек язылган шигырьләрдә дә – чит сурәт:

*Аяз күгең*
*Охшый бүген*
*Улын имезеп ләззәтләнгән*
*Болан күзенә.*

Гомумән, бу иҗатта Себер һәр әсәрдә, тегеләйме-болаймы, катнаша һәм концепт вазыйфасын да башкара. Йә ул шушы тебәккә хас табигать образларында тоемлана, йә шагыйрь, Себер татарларына эндәшеп, мөнәсәбәт белдереп, бәя биреп уза («Сукмактагы кортны изсәң…», «Тартар», «Камышка камыш ышкыла…»). Себер, аның урманы-җәнлеге, табигать баласы булып яшәгән кешеләре укучыга, географик атама булудан бигрәк, кешенең һәм кешелекнең бишеге кебек тоела башлый. Вакыт ягыннан чикләр җуела: Ш.Гаделша шигъриятендә кеше теләсә кайсы заманныкы, теләсә кайсы чорныкы.

Табигать образларының аллегория төсендә кулланылуы да бу иҗатта еш очрый. Үз шигырьләрендә Шәүкәт мәсәл традицияләренә мөрәҗәгать итә: аллегорик образ ярдәмендә кеше холык-фигылен, тормыш ситуациясен тергезүен, эчке мәгънәсен үзе үк әйтеп бирә. Мәсәлән, «Мөгездәге ярык» шигырендә мөгезендәге ярык тынгысызлаган болан хыялы артыннан киткән лирик герой белән тиңләшә, «Шул үгез хәлендә бит, дуслар, мин үзем дә» дип, бу соңгы тезмәдә ачыклап ук үтелә. Яки икенче бер шигырь – «Яшь карчыга»да кош образы буш эшләр белән яшәвен аңлаган кешене аңлата. Мәсәлдән аермалы буларак, шигырьләрдә нәсихәт-мораль түгел, фәлсәфи фикер яңгырый. Соңгы шигырьдә ул түбәндәге юлларга тупланган:

*Хәтерем кычкыргандай булды:*
*– Ничек яшим?*
*Ничек яшәдем?*

Кеше көннәрдән бер көнне үз тормышына күз ташлый да, үкенечкә чума, бу – табигый, ди Шәүкәт фәлсәфәсе. «Ярык мөгез» шигырендә исә хыял артыннан йөгерүнең максатка ирешүгә түгел, үлемгә китерүе ачыклана. «Авыру чебеш кук боегып…», «Җиде торна» кебек шигырьләр дә шушы кимәлдә язылган. Кайчак Яшәеш фәлсәфәсен, Кеше фәлсәфәсен иҗтимагый фикер алыштыра. Мисалга «Урман шәрә, җил туңдыра» шигырен китерергә мөмкин. Тун алыштырган куян образы заманга яраклашкан кеше амплуасында бирелә:

*Заман гына кара төстә –*
*Шуңардан куркам.*
*Мин кемең дип, халкым, нигә*
*Уйланып торам;*
*Ашыгып тун алыштырган*
*Куяның булам.*

Шул рәвешле, табигать образы, бу очракта, җәмгыятькә һәм заман кешесенә бәя бирергә ярдәм итә, бүгенгебез өчен бик тә актуаль мәсьәләне мәйданга чыгара.

Шәүкәт Гаделша иҗатында фәлсәфи шигырьләр да байтак. Иң уңышлы, кызыклы әсәрләр дә шулар. «Болан күзе», «Болан баскан эзләргә…», «Кинәт кенә купты давыл…», «Күп сөйләнсәң», «Күз буяу», «Җилгә элгән ятьмәләрем», «Офыктагы әтәч…», «Сорап куйгалый иде…» кебек шигырьләр шагыйрьнең үз фәлсәфәсе, дөньяны үз кабул итүе булуын күрсәтә. Бу әсәрләрдә дә табигать образлары үзәктә тора. Нәтиҗәдә кеше-табигать образларының янәшәлеге табигать һәм

кеше берлеген ассызыклый, хис-кичерешләр дә, кайгы-фаҗигаләр дә, шатлык-гаҗәпләнүләр дә уртак икәнлекне кат-кат кабатлый. Мәсәлән, «Болан күзе» шигырендә баласын югалткан болан һәм шундый ук кайгы кичергән кеше тиңләштерелә, бу кайгының «Дөньябызны йотарлык бушлык» булуы ачыклана.

Бушлык һәм Тынлык төшенчәләре Ш.Гаделша фәлсәфәсендә Яшәүгә, Матурлыкка, Өметкә… каршы куела. Хәтта Үлем дә, бу халәтләр белән чагыштырганда, табигый бәяләнә. Мәсәлән, «Йөз яшьлек аучы» шигырендә Яшәү – Тынлык, Бушлык каршылыгы гаҗәеп дәрәҗәдә кискен бирелә. «Үлем берни түгел, Шул тынлык куркыныч» дип, лирик герой йөз яшьлек аучы артыннан тагын бер хакыйкатьне кабатлый: кешенең үлеме – буыннар алмашу, ул табигый, ә менә Тынлык халәте – дөньяның үлүе… Шушы халәт кешенең кайгылы минутларында, борчулы мизгелләрендә, үкенеч килгәндә пәйда була. Монысы – вакытлы. Аларны шагыйрь төрле шигырьләрендә күрсәтеп уза. Ә менә өметнең бөтенләй өзелүе, үлгән дөньяда җан асрау – иң куркыныч җәза, иң олы хәсрәт. Шул рәвешле, күнегелгән Яшәү-Үлем антиномиясе Ш.Гаделша иҗатында Яшәү-Бушлык белән алышына.

Кешенең Үлемне җиңелрәк санаган мизгеле «Тук ялкаулык яшелләнеп…» шигырендә үзенчәлекле яңгырый. Лирик герой табигать образлары аша үзе хакында сөйли. Болар – инештә йоклаучы яшеллек, битараф ак болытлар, хәрәкәтсез черки-кигәвен, балыклар, эт теле күк салынган учак, чакмый торган бал корты, эссе тынлык, хәлсез күбәләк. Һәр табигать образы лирик герой күңелендә хәрәкәттән туктаган бер сыйфатны белдерә, нәтиҗәдә кеше – күләгәгә әверелгән мизгел сурәте бөтен тулылыгында күз алдына килә.

Үлемнең мәҗүси фәлсәфәдәгечә акланышы да кызык. «Менә монда болан ауган…» шигырендә шагыйрь Яшәешне ике чиккә – җан ияләренә һәм агачларга аера (болан-усак, куян-куак). Үлем исә – боланның – усакка, куянның – куакка әверелү чиге. Җан ияләренең берсе булган кешене, лирик геройны да үз әверелеше борчый:

*Агач кочып уйланамын:*
*«Мин, егылсам, ни булырмын?»*

Шушы фәлсәфәне шагыйрь оҗмах-тәмуг каршылыгы белән тәмамлый. Әверелешнең кайсы ягы – оҗмах, кайсы ягы – тәмуг булуы гына укучының үзенә уйлап бетерү өчен калдырыла.

Кеше фәлсәфәсе чагылган шигырьләр Яшәешкә экзистенциаль бәя бирә. Кайчан да булса барыбер дөньяның мәгънәсезлеген, кешегә карата явызлыгын аңлыйсың, дип саный шагыйрь. Шуны аңлаган мизгелдә хакыйкатькә төшенәсең. Менә «Башын чуртан судан соңган…» шигы-

ре. Монда дөнья – яртылаш судан чыккан чуртанны катырып калдырган бәке. Шушы дөньяда кешеләр ике төргә бүленә: кемнәрнедер тормыш кызыктырып, әйдәп, кемнәрнедер алдап яшәтә!

Шагыйрь әсәрләрендә халык авыз иҗаты белән бәйләнеш табигать образларына мөрәҗәгать итүдә генә чикләнми. Ш.Гаделша жанрлар белән дә тәҗрибәләр ясый. Әйтеш традицияләренә нигезләнгән, монолог формасындагы «Ботаксыз наратны…», капма-каршы әйтешү кебек язылган «И Вәлиш, Вәлиш…», халык җырына охшатып эшләнгән «Күпме хата, гөнаһларым…» шигырьләре шундыйлардан. Примитивизмга (сүз әдәбият белеме термины буларак кулланыла) йөз тоткан, образларны фольклордагыча кулланган шагыйрь геройларының балаларча самими хисләрен, теләк-омтылышларын, рухи дөньясын күрсәтүгә ирешә, шушы беркатлылык артында шактый катлаулы тормыш ситуациясе дә шәйләнә.

Табигать образлары белән эш иткәндә гадилеккә омтылган шагыйрь аерым бер фәлсәфи әсәрләрдә катлаулы сурәт тудырып уйный. Нәтиҗәдә камил, тәэсирле шигырьләр туа. «Карурманда» шигыренең лирик герое – битарафлык чигенә җиткән, заман, тормыш белән көрәшү юлын тапмый башлаган борчулы кеше. Риторик эндәш мифологик образга – «хәятем җене»нә юнәлтелгән. Лирик герой үзен башкаларга, заманча яшәүчеләргә каршы куя. Ул – заманга яраклаша алмый, тынлыкка, битарафлыкка тарган кеше, кеше шушы халәттән чыгу юлын эзләп урманга качкан. Урман-кое кешенең аң төпкелендәге архаик хәтер мәгънәсенә дә ия. Әйтерсең, яшеренер, көч алыр урын эзләп кеше табигатькә (хәтергә), кешелекнең бишегенә мөрәҗәгать итә ала. Бу – шигырьдә күренеп торган бер фәлсәфи фикер. Әсәр кысаларында тагын бер мәсьәлә – кешенең бәхетен эзләве мәсьәләсе дә куела. Үзең теләгәнчә яшәү – бәхет дигән җавап бирелә. Шигырьнең соңгы юлларында лирик герой төркемгә каршы торыр әмәл һәм сихер сорый: ялгызак фәлсәфәсе пәйда була.

Ш. Гаделша иҗат иткән лирик герой – үзен табигать баласы дип санаучы һәм табигатьне күзәтүче, һәр шигырь тормыш-яшәеш кагыйдәләрен ачып, шул кагыйдәләрне билгеләп язылган. Бу кагыйдәләр өчен урын-вакыт чикләре юк, алар универсаль. Шушы як әлеге шигырьләрнең күпләр өчен кызыклы һәм якын килеп чыгуын тәэмин итә.

Әмма фикер тирәнлеге, үзенчәлекле образлары булган шигырьләрдә форма төгәлсезлеге күзгә бәрелә, аларның кыйммәтен төшерә. Татар шигыре көйлелекне, пафосның гармонияле табылуын ярата. Шәүкәтнең күп кенә шигырьләрендә шушы көй бозыла. Моның бер-ничә сәбәбе бар. Иң зурысы – үлчәмнәрнең сакланмавы. Кайбер очракларда шагыйрь ямьсезлек эстетикасына мөрәҗәгать итә. Бик ма-

тур фәлсәфи фикер салынган «Хәтер», «Язгы көндә» шигырьләре тупас гыйбарәләр, детальләр аркасында оттыра.

Шулай итеп, мәгънәле, үзенчәлекле фәлсәфәсе белән сискәндерүче, табигать образлары ярдәмендә дөньяны антропоморфизм яссылыгында сурәтләүче, татар шигъриятен яңа мотивлар, образлар белән баеткан Ш.Гаделша иҗаты поэзиянең фольклор белән бәйләнешләрне озмичә үсү мөмкинлекләрен күрсәтте. Фәлсәфи эзләнүләр офыгын киңәйтү, форма камиллегенә аерым игътибар бирү авторга үз осталыгын тагын да арттырырга ярдәм итәр иде.

**Азат Сәгыйтов,**
Төмән өлкәсендәге «*Яңарыш*» газетасы беренче баш мөхәррире (2005 ел кадәр)

## Ш.ГАДЕЛША: «…КАЗАН, ТӨМӘН АРАСЫ – МӘГЪНӘМ МИНЕМ, КАНАТЫМ..»[20]

Якташыбыз Шәүкәт Гаделшаның шигырьләрен «Яңарыш»та 1997 елдан бирле бастырып барсак та, аның әле үзе белән якыннан күрешкән юк иде.

Күрештек, сөйләштек, аңлаштык. Чын шигърият яратучы буларак, аның 4 китабында бастырылган шигырьләрен инде яратып өлгергән идем.

«Миңа да чиш әле сереңне – Ничек йөрәккә үтәргә», – дип язган иде Шәүкәт «Яңарыш» гәзите» дигән шигырендә. Әрнегән иде шул шагыйрьнен йөрәге якташлары, авылдашлары тарафыннан моңача танылмый яшәгәнгә күрә. Аңлыйм мин аны. Шуңа күрә дә «Яңарыш»та күп тапкыр бастырдык без аның турында мәкаләләр. Ләкин Люция апа Хәбибуллинадан башка, аны күрүче дә, аның шигырьләре турында язучы да булмады.

Ә Татарстанда күрделәр, таныдылар безнең Себер шагыйрен. 5 нче китабы басылып чыкты – «Аучы җыры». Менә нәрсә яза шушы китаптагы кереш сүзендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Роберт Әхмәтҗан:

«Шәүкәт Гаделша дигән шагыйрьнең иҗатын беренче шигырьләреннән алып күзәтеп барам. Әлеге шагыйрь, беркемгә дә охшамаган гаять үзенчәлекле иҗаты, темалары һәм иҗат алымнарының яңалыгы белән үзенә җәлеп итте. Шигъриятькә ул җиңел генә килде дип булмый, ул аңа «кайта-кайта» килде дияр идем.Чөнки, студент елла-

[20] Сәгыйтов А. Ш.Гаделша: «…Казан, Төмән арасы – Мәгънәм минем, канатым..» // Яңарыш.– 2004.– № 7 (1158), 13 февраль. – Б. 7.

рында ук үзенчәлекле шагыйрь килә дип көткәндә, кинәт, башлангыч «мирасын» төяп, үзенең Төмәненә, аның урман-күлләре, җәнлекләре дөньясына кайтып китте. Әмма бу «югалу» тикмәгә генә булмаган икән, шөкер. Шәүкәт Гаделша бу юлы әйтерсең лә Себер Иленең зәңгәр урманнарын, җәнлекләре дөньясын, могҗизалы төннәрен, нәсел-ыруының фатихасын, йолаларын, гаять бай халык иҗаты мирасын төяп кайтты!

…Шигырьләренең уникальлелеге, алардан яңача сурәт, аһәң, сурәтләү чараларының байлыгы – үзе бер кабатланмас поэтик дөньяны тудыра…

…Шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның атасы ягыннан бабасының сөрелгән Казан татары булуы, әнисе ягыннан бабасының исә Себер ханнары нәселеннән килеп чыгуы мәгълүм шәҗәрә әнә шундый. «Җан тартмаса да, кан тарта», -ди халык. Шәүкәт Гаделша моны сизеп яши, әнә шуңа да аның Себер ханы Күчүм кебек, туган туфрагына аяк терәп яшәргә, горурланып сөйләшергә хакы бар! Моңа мисаллар аның иҗатында тулып ята. Аның лирик герое һәрчак юмарт холыклы, кешеләргә ярдәмчел:

*Бирәм соңгы серәнкәне,*
*Соңгы телемемне.*
*Күрәм кеше күңелләрен,*
*Тыңлап күңелемне.*
*Кызганмыйм да, укенмим дә,-*
*Рәхмәтләнеп калам.*
*Себер татарларын шулай*
*Яраткан бит Аллам.*

Шагыйрь үз ягын, үз тарихың белә генә түгел, ул аны һәр күзәнәге белән сиземли, тоя. Шагыйрьнең рухи табигатен ул яшәгән табигатьтән аера алмыйсың. Шагыйрь табигатьне «өстән» яки «тышкы яктан» гына тасвирлаудан ерак, үзенең туган төбәген, халкы яшәешен, аның тарихын әледән-әле иҗтимагый-сәяси югарылыкка күгәрә, шигырьләр чынбарлыкка якынлаша, чорның чалымнары күз алдында пәйда була:

*Кук томан әчендә «дөп» тә «дөп»,*
*Тышаулы елгырлар килә күк…*
*Җилфердәп китмәсме сөңгедә*
*Күчүмнең ак кыллы бунчагы.*
*Болгана каршымда күк томан.*
*Белмимен: артымы, алдымы?*
*Атларны чүктереп атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Шагыйрь табигатьнең яшерен серләрен ачарга омтыла, моны ул булдыра алуына да ышана. Әмма, мәҗүсилек калдырырга ярамый дигән кебегрәк нәтиҗә ясый. Шигъри мантыйгын Себернең хуҗасы – чын Себер татары дигән нәтиҗә-фикергә китереп ялгый:

*Сизә күңелем, әй, сизә:*
*Ята монда хәзинә.*
*Күчүмнеңме? Кайсы ханның?*
*Әйтә алмыйм хәзергә.*
*Сизсәм дә кайда ятканын,*
*Теләмим кагылырга.*
*Иректән мәхрүм хатынның*
*Ирексез алтыны да.*

Әйе, Шәүкәт Гаделшаның иҗаты хакында, шигъриятенең хикмәтле яклары, гомумән, татар поэзиясендә Шәүкәт Гаделша феномены хакында фикерләр дә булмады түгел. Әмма аны өстән-өстән әйтеп китү бер хәл, ә менә чынлап торып әлеге иҗатны фәнни яктан өйрәнү Себер татарларының поэтик тел җәүһәрләрен өйрәнүгә дә зур өлеш кертер иде. Киләчәктә әлеге эш үз галимнәрен дә табар әле, бәлки…

Менә нинди шагыйрь бит ул – безнең Шәүкәт!

Шушы кыска гына вакыт (2 көн) аралашкан арада аның бик тә кайгырып, сыкранып сөйләгән сүзләре истә калган.

– Эх, бу көннәрне Булат – дус күрә алмады, – диде ул редакциябездә җирле шагыйрьләребез белән очрашып сөйләшкәннән соң. – Без бит бу көннәр турында Булат әкә белән Казанда укыганда әллә ничә мәртәбә хыялланып бәхәсләшкәнебез бар. Укып бетереп, үзебезнең якларга кайтып, иҗат түгәрәкләре оештырып, үзебезнең Себер шагыйрьләре дә үстерәсебез килгән иде безнең. Баксаң, сез монда тик ятмагансыз икән, ничәмә – ничә шагыйрьләр булдыргансыз, дистәләгән китаплар бастыргансыз!

Эх, Булат әкә күрсә бу эшләрне!..

Шагыйрь – шагыйрь инде ул. Талымхан күлендә якташларының аңа яшь чагыннан таныш булган кәсеп – елым тартуларын күрүгә, иҗат кешесенең күнелендә үзе күптән кичергән образлар, вакыйгалар уянган, җыр туган, күрәсең. Шәүкәт шул ук көнне үзенең «Җыр туганда» поэмасын укып бирде. Бик ошады ул безгә. Сез дә укып карагыз, фикерегезне белдереп язарсыз. Ул әсәре аның әле беркайда да бастырылмаган.

Ә шагыйрь Газинур Морат сезгә үзенең Шәүкәт турында язган «Көй чакыру» шигырен тәкъдим итә.



**Диләфрүз Фәхретдинова,**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты, Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## Ш.ГАДЕЛША: «…КАЗАН, ТӨМӘН АРАСЫ – МӘГЪНӘМ МИНЕМ, КАНАТЫМ..»[21]

Бу көннәрдә Ялутор районы, Яңа Атьял авылыннан «Яңарыш»ны укучы Али Хәкимовтан хат килде. Ул газетаның 11 нче санында бастырылган Шәүкәт Гаделшаның «Масаерга иртә әле!» дигән мәкаләсе аның «саруын кайнатуын» белдергән. «Гаделша ревизорның кайда соң иҗат эшләре, кем соң ул? Аның шигырьләрен моңача укучы булдымы? Казанда яшәп Себер халкын яхшы аңлап җитми», – дигән. «Яңарышта кайбер шигырьләре басылып барган шагыйрьләребез дә «мания величия» белән саташып Ш. Гаделшаның мәкаләсенә каршы тошкәннәр.

Танылган шагыйрь редакторыбыз үтенече буенча язган мәкаләсендә беркемне тәнкыйтьләмәгән, ул дусларча киңәш кенә биргән. Нигә моны гаепкә алырга? Гаделшаның шигырьләре белән газетаны укучылар 1997 елдан ук таныша башладылар. 1998 елның 40 нчы санында «Кадерле авылдашым минем» дигән Шәүкәт Гаделша турында мәкаләм дә чыкты. 2000 елның 77–78 саннарында бер бит итеп шигырьләре бастырылды. 2001–2003 елларны газета битләрендә яңа иҗат җимешләре дөнья күрде. Али Хәкимов шикелле «Яңарыш»ның

---

21 Фәхретдинова Д. Ш.Гаделша: «…Казан, Төмән арасы – Мәгънәм минем, канатым..» // Яңарыш.– 2004.– № 18 (1169), 30 апрель. – Б. 7.

ул саннарын укымаган кешеләр өчен без яңадан якташыбыз Шәүкәт Гаделшаның биографиясенә кайтырга булдык.

Гаять үзенчәлекле, уникаль шагыйрь Шәүкәт Гаделша Төмән өлкәсе, Түбән-Тәүде районы, Киндерле авылымда 1949 елны туган. Ул Себернең кырыс, әмма мул табигатьле төбәгендә иленең яшел урманнарын, җәнлекләре дөньясын, могҗизалы төннәрен, нәсел-ыруының фатихасын, йолаларын, гаять бай халык иҗаты мирасын белеп, күреп үскән. Шагыйрь үз ягын, үз тарихын белә генә түгел, ул аны һәр күзәнәге белән сиземли, тоя. Шагыйрьнең рухи табигатең ул яшәгән табигатьтән аера алмыйсың. Шагыйрь табигатьне «өстән» яки «тышкы яктан» гына тасвирлаудан ерак, үзенең туган төбәген, халкы яшәешен, аның тарихын әледән-але иҗтимагый-сәя-си югарылыкка күтәрә, шагыйрьләр чынбарлыкка якынлаша, чорның чалымнары күз алдында пәйда була. Шагыйрь табигатьне – агачларны, суларны, хәтта ташларны җанландыра, илһамлаштыра.

Аның төрле елларда «Ярык мөгез», «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм», «Җилгә моң дыңгычлыйм» дигән шигырь китаплары, «Аучы җыры» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Ул беркемгә дә охшамаган үзенә бертөрле иҗаты, темалары һәм иҗат алымнарының яңалыгы белән үзенә җәлеп итә. Шигърияткә ул җиңел генә килми, ул аңа «кайта-кайта» килә.

Шагыйрьнең туган җире Киндерле авылы табигатьнең нәкъ кочагында урнашкан. Аны Уба, Бизем, Татаурка. Луговое, Черек, Саргачбил, Мирон, Пилорама, Лапкынды, Белое, Караелга һәм башка бик күп матур атамалы урманнар, күлләр, сазлар, елгалар уратып алган. Тирәякта Канчәбер, Кыткүл, Бухарин, Яңа-Казанлы татар авыллары җәелеп киткән.

Шәүкәт абый Киндерле мәктәбендә белем алганнан соң КамАЗ төзелешләренә юл тота. Төзелештә монтер булып эшләү белән беррәтән ул Чаллыда оештырылган әдәби берләшмәгә йөрергә шигырьләр язарга да вакыт таба. Казан дәүләт университетына укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Аннан соң ул Себергә кайта, анда төрле оешмаларда, совхозда җитәкче булып эшли. Ләкин шигърияткә булган олы юлы аны яңадан Казанга алып килә. Ул хәзер Казанда яшәп иҗат итә.

Шәүкәт Сибгатуллинның әтисе яктан бабасы Себергә сөрелгән казан татары, әнисе ягыннан бабасы себер ханнары нәселеннән килгән чын себер татары. Бөек Ватан сугышы ветераны мәрхүм Гаделша абый белән Фәрхия апа Сибгатуллиннар 6 бала тәрбияләп үстерделәр. Шәүкәт абый гаиләдә иң олы бала. Әтисе Гаделша абый бигрәк тыйнак, сабыр, кешелекле, тырыш, намуслы зат иде. Сугышны үтеп чыккан солдатның гомере генә кыска булды, якыннарын ташлап бик иртә китте. Фәрхия апа озак еллар инде уллары белән авылда тора, ә Шәүкәт

абыйның бердәнбер сеңлесе Гөлҗиһан апа гаиләсе белән елдан артык Новосибирск шәһәрендә яши.

Күптән түгел шагыйрьнең калын гына «Аучы җыры» дигән яңа китабы басылып чыкты.

**Диләфрүз Фәхретдинова**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты, Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША: «ЯЗМЫШЫМНЫҢ ДӘРЬЯСЫ – КАЗАН, ТӨМӘН АРАСЫ»[22]

Ел саен үзенең туган ягында яшәүче милләттәшләрен «Яңарыш»ка яздырырга ярдәм итүче шагыйрь Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) бу юлы да Казаннан 10 мең сум акча җибәрде. Рәхмәт Шәүкәт абыйга, ул «Яңарыш»ка нинди генә авырчылыклар килмәсен һәрчак булышырга әзер. Шатлыклы хәбәрләрне дә тиз арада ишетеп, Казан башыннан беренче булып шалтыратып котлый.

Исемдә, 2003 нче елның ноябрендә Киндерлегә кайткач, озак еллар мәктәпне җитәкләүче, Рәсәй Федерациясенең Атказанган укытучысы мәрхүм Маһинур апа Фазлуллина белән очраштык, бу безнең соңгы күрешүебез булган икән. «Икенче кайтканыңда, һичшиксез, миңа килеп китәрсең әле. Икебез утырып Шәүкәт абыең турында газетага әйбәтләп зур мәкалә язарбыз. Ул минем тормыш иптәшемнең якын дусты, Фатих абыең да безгә кушылыр», – дип Маһинур апа чакырып калган иде. Эмма алдагы көнебездә нәрсә көткәнен белеп булмый шул, кышның нәкъ уртасында кешелекле, мәрхәмәтле, балаларга төпле белем бирүгә барлык гомерен багышлаган укытучы мәңгегә яныбыздан китте. 2004 елның азагында авырып, көтмәгәндә иптәше Фатих абый да кинәт вафат булды. Ул да озак еллар мәктәптә балаларны укытты. Маһинур апа белән очрашып Шәүкәт абый турында мәкалә язып өлгермәвебез үкенечкә калды.

«Себер җирендә туып-үсеп Татарстанда зур абруй казанган якташың, Татарстанның язучылар союзы әгъзасы шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның иҗаты турында еш язып тор. Аны бөтен өлкә белергә тиеш», – дип редакторыбыз мәрхүм Азат абый Сәгыйтов гел әйтә иде.

Шәүкәт Гаделшаның шигырьләрен укый башлау белән аның уникальлегенә карап сокланасың. Шагыйрьнең һәр шигырендә кешенең рухи халәте табигать халәтенә ярашлы, тәңгәл рәвештә җанлана. Аның

[22] Фәхретдинова Д. Язмышымның дәрьясы – Казан, Төмән арасы… // Яңарыш.– 2005.– № 31 (1234), 29 июль. – Б. 7.

лирик герое һәрчак юмарт холыклы, кешеләргә ярдәмчел. Шагыйрь табигатьне «өстән» яки «тышкы яктан» гына тасвирлаудан ерак үзенең туган төбәген, халкы яшәешен, аның тарихын әледән-әле иҗтимагыйсәяси югарылыкка күтәрә, шигырьләр чынбарлыкка якынлаша, чорның чалымнары күз алдында пәйда була. Газета укучыларыбызның үтенече буенча шагыйрьнең тагын берничә шигырен тәкъдим итәбез.

**Рашат Низами**

язучыс, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан язучылар берлегенең Хади Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы

## АУЧЫ. ШАГЫЙРЬ. ГУМАНИСТ[23].[24],

*Иркен Төмән!*
*Моңсу Төмән!*
*Юмарт Төмән!*
*Шәүкәт Гаделша.*

Мин Себерне үземчә ярыйсы гына беләм дип саный идем. Чөнки, сәфәрем төшеп, бу якларда өч-дүрт тапкыр булганым бар. Енисей, Тобол елгаларында колач салып йөзгән чаклар да булды. Тайга уртасында – яңа оешып килгән Туртас поселогы. Заманында бiредә без, шабашкага чыккан студентлар, агачтан фин йортлары салдык. Сазлыклар, әкияти-серле тайга, бармак башы тикле эре черкиләр әле дә булса хәтердә. Безгә арзан гына бәягә, ау мылтыгы һәм идәнгә җәешле аю тиресе тәкъдим итүчеләр дә булды. Ни кызганыч: студентның кесә ягы такыр иде шул…

Ниһаять, мин Себерне үзем өчен өр-яңадан ачтым!

Бу хәл Себер татары, Төмән өлкәсендә туып-үскән шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның «Аучы җыры» дигән китабы белән танышканнан соң булды. (Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2004 ел). Китап саллы, күләмле, ул сайланма әсәрләр рәвешендә тәкъдим ителгән.

Кем соң ул Шәүкәт? Аның шигъриятенең төп үзенчәлекләре нәрсәдә? Мин шушы сорауларга җавап табарга телим…

Сүзне китапның исеменә үк бирелгән «Аучы җыры» шигыреннән

[23] Рашат Низами. Аучы. Шагыйрь. Гуманист // Казан утлары.– 2008.– № 7. – Б. 139–142.

[24] Рашат Низами. Аучы. Шагыйрь. Гуманист // Яңарыш.– 2008.– № 32 (1391), 8 август. – Б. 7.

башлап китәсе килә. Күңелнең эчке кичерешләренә, шуның нигезендәге конфликтка корылган бу шигырь нәни бер поэма кебегрәк укыла. Сюжеты бик гади: сунарчы егет сөйгәненең туган көненә сусар (куница) мехыннан «көмеш бүрек» бүләк итмәкче була. Әгәр шуны эшләми икән, кыз аның мәхәббәтеннән баш тартачак… Сөюеннән исергән егет төнгә чаклы эзли сусарны, уйлана-газаплана торгач, ахыр чиктә ул аны карурманга «бүләк» итеп калдыра һәм вәгъдә бирә:

*Озатып бар*
*Син алдымнан.*
*Сиңа бер дә*
*Мин кагылмам.*

Урман сусары белән әнә шулай дусларча, кешелекле саубуллаша егет. Аның бу сыйфатына ничек инде сокланмыйсың ди!

Гомумән, аучы образы шигырьдән шигырьгә үстерелә, яңа бизәкләр белән баетыла. Икенче бер шигырьдә без аучының «йөз яшьлек» (!) икәнлеген дә беләбез…

Әкиятләргә кергән болан образы да китапның буеннан-буена диярлек укучыны «озата» бара. Ул- моңсу да, гамьле дә, горур да, ачулы да. Ә нигә, без – кешеләр – үзебез дә әнә шундый кавемнән түгелмени?

Ярык мөгезле ата болан, ана боланның чакыру авазын куып тоталмыйча, арып егыла… Чып-чын фаҗига лабаса! Автор, әнә шушы «үгез хәлендә» мин дип, тирән гомумиләштерү ясый.

Шунысы гаҗәп: Шәүкәт һәр вакыйга һәм күренешләрнең уртасына, ягъни асылына өермәдәй үтәли узып керә, аны үзенә генә хас телбизәкләр белән сурәтләп, үзенең янача шигъри дөньясын тудыра. Ул берәүгә дә охшамаган. Аның дөньясы кин, колачлы: бөҗәкләрдән алып йолдызларга кадәр…

Образлы фикер йөртү, метафоралар һәм чынбарлыктагы детальләр белән оста эш итү аның һәр шигырен диярлек бизәп тора. Шулай әйтергә яраса, ул үзенең остаханәсендә, фанатик бер галим сыман, яңадан-яңа ачышлар ясый. Фикеребезне ныгыту өчен, кайбер мисалларга мөрәҗәгать итик:

*И зәңгәр күк,*
*Чәчәк булып коел әле!*

*Тал очында уйный йодрык –*
*Кош калдырган кара оя.*

*Кара карга күкрәге*
*Көзге булып ялтырый.*

*Кояш әле бик түбәндә –*
*Кашы гына күренә.*

*... Үрләр артында*
*Тук боланнар күкне сөзәдер.*

*Үле тынлык. Кар ыңгыраша.*
*Шундый куркыныч!*

*Кояш та, ай да бит*
*Тез кебек түгәрәк, һ. б.*

Җитеп торыр булмаса. Көтелмәгән тәэссоратларның муллыгын исбатлап торасы юк бу очракта. Тагын да мөһиме – алар кырыс яисә акварель сурәт булып шундук истә калалар.

Шәүкәтнең дөньясы (шигъри генә микән?) киң, колачлы. Аның иҗаты белән танышканда кемнәрне, ни-нәрсәләрне генә очратмыйсын: тукран, карчыга, кыр үрдәге, торна, аккош, саескан, сыерчык, чуртан, поши, аю, селәүсен, төлке, елан, нарат, карагай һәм башкалар. Алар гади бер рәсем генә түгел, фәлсәфә нуры белән өретелгән әдәби образ-сурәтләр.

Менә гап-гади бер кош-тукран. Ул әле бер, әле икенче агачны бик тырышып- дәртләнеп чукый. Лирик герой сөйгәнен көтеп тилмерә, аның хәле мөшкел:

*Нигә соң килми ул,*
*Нигә Һаман Ялгыз утырам?*
*Агачларны түгеп,*
*Йөрәгемне Чукый тукран.*

Шәүкәт Гаделша – чын табигать баласы. Аның бу сыйфаты иҗатында тулаем чагыла, һәр шигыреннән диярлек саркылып тора. Табигатьне ул җаны-тәне белән кабул итә, шигъри күзләр белән ярата. Моны ул үзе дә таный һәм курыкмыйча әйтеп тә бирә:

*Эт шикелле өрә беләм,*
*Карчыга күк күрә беләм...*

Тагын шунысын да әйтик, табигать җырчысы Пришвин сыман, коеп куйган натуралист кына түгел шагыйребез. Табигатьнең гап-гади күренешләреннән ул тормыш-яшәешебездәге актуаль проблемаларына кадәр күтәрелә, зур гомумиләштерүләр ясый. Анын яшәү формуласы шактый кырыс һәм усал:

*Чак кына аңлый алсам мин*
*Үлән, агачлар телен,*
*Миңа ары яшәр өчен*
*Кешеләр кирәк түгел.*

Табигатьне ярату гына җитми, кирәксә аны төрле рәнҗетүләрдән яклый белергә дә кирәк. Бу җәһәттән «Поши ите» дигән шигырь аеруча характерлы. Авылдашлары поши аткан: «табада да, өстәлдә дә поши ите»… Олысы да, кечесе дә малайны сыйланырга кыстыйлар. Ул ашарга кыенсына, тискәре сүзләр белән үзенчә бунт күтәрә! Шигырьнең азагы исә гыйбрәтле гуманизм белән тәмамлана:

*Поши ауган урыннарда*
*Үсеп чыга сары чәчәк.*
*Шул чәчәкне таптаганны*
*Яшен сугып үтерәчәк…*

Ш. Гаделша иҗатындагы тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик: әсәрләрендә ике агым кушылып китә, синтезлаша – реаль чынбарлык һәм автор фантазиясе. Менә шушы нардан еш кына төрле балкыштагы гаҗәеп фантасмагория барлыкка килә! Моны шулай ук күп кенә мисаллар белән ныгытырга, расларга мөмкин.

«Тагын ауда азан ишеттем» шигыре көтелмәгән яклары белән сискәндерә. Бу исәр сунарчының гамендә ау кайгысы түгел, дөнья кайгысы! Төз чыршыларны ул мәчет манарасы итеп күрә. Өстәвенә, беркем дә тоймастай кичерешләр дулкынында йөзә:

Серле эңгерлеккә чумган Куакларны, ботакларны Коръәндәге хәрефләргә,

Сүрәләргә охшатамын.

Юк, эш моның белән генә бетми әле. Лирик герой шушы күзәтүләреннән тагын да югарырак баскычка күгәрелә: тумышыннан надан, денсез икәнлегенә нәфрәте кузгала, мылтыгын җиргә сугып ватмак була. Ә үзе, бүре баласыдай, һаман әле караңгылыкка карый…

Чыннан да, кеше күңеле – карурман!

Шәүкәтнең дүрт-биш иҗекле калыпка көйләнгән шигырьләре чичәннәр сөйләменә охшаш. Сюжетлы шигырьләре барлыгын да билгеләп үтик. Аның байтак кына шигырьләре балладага тартым. Әмма автор тыйнаклык күрсәткәнме, китапта «баллада» дигән сүзне бер дә очратмадым.

Шагыйрь бик күп шигырьләренә истә калырдай кабатланмас исемнәр куша белгән. Әйтик, шундыйлардан: «Каен – яшел шар», «Көнем – упкын», «Балыкчы хатын», «Черкине сагынам», «Аю хәлендә калам», «Чалдун теле»…

Чалдун димәктән, бу сүз җирле сөйләштә «Себер татары» дигәнне аңлата. Гомумән, үзенең шигырьләрендә Шәүкәт Себер татарлары теленә генә хас диалект сүзләрне бик иркен һәм кыю куллана: чөрәгәй, марта, серәнкә, хорей, кучкер, яртыясак, агун, чәпче һәм башкалар. Контекста алар ансат аңлашыла.

Язганнарымнан, Шәүкәт Гаделша гел табигать турында гына яза икән, дип аңлашылмасын. Ул тарихи темаларга да еш мөрәҗәгать итә һәм безне Күчем хан, Ермак яшәгән дәверләргә йолкып алып керә. Бүгенге көннең «мескенлеге» хакында чаң кага:

*Атларны чүктереп атланыр*
*Берәр ир Себердә калдымы?*

Мин бу темага сүзне озайтырга җыенмыйм. Чөнки китапка кереш сүз язган күренекле шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов әлеге буразнаны тирәннән ерып чыккан. Кабатланасым килми. Р. Әхмәтҗанов үзенең әдәби мәкаләсен болай дип тәмамлый:

«Шәүкәт Гаделшаның шигърияте легендалар вә дастаннар иле – Себернең җир-суына, урман-күлләренә, киек-җәнлек дөньясына, ыруглары рухына Шигъри Дога булып ишетелә!»

Бу мәкаләмдә мин дә нәкъ менә шул хакта сөйләргә тырыштым түгелме? Шөкер, безнең фикерләр тәңгәл, аваздаш икән.

Әйе, шагыйрь Себер киңлекләрен, аның күпкырлы хәятын киң полотналы манзара рәвешендә укучыга ачып бирә. Барысын күздә тоткан хәлдә, мин моны бер дә икеләнмичә Шәүкәт Гаделша феномены дип атар идем. Шуңа да бу каләм әһеленең үзен «Мин – хан!» дип игълан итүен «аңларга» да мөмкин. Юк, Шәүкәт, «Мин Себеремне яратам!» дип шау килми, сөрән салмый. Купшы сүзләрдән ерак ул. Ләкин аның туган ягына булган хөрмәте-мәхәббәте-горурлыгы иҗатыннан саф чишмә суыдай һәрдаим челтерәп, саркылып тора.

Заманында Салисә Гәрәева «Уралым» дигән шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган иде. Ул да әнә шулай үзенчәлекле итеп безгә Урал-тау образын ачып биргән иде…

Укучы: «Нәрсә Ш. Гаделшаның шигырьләрендә кимчелекләр бердә юкмени?» – дип сорарга мөмкин. Бар барын, ләкин болар, минем уйлавымча, вак-төяк кенә.

Мәсәлән, кайбер шигырьләрендә «караштыргала-каршыларга» кебек кытыршы, уңышсыз рифмалар да очрап куя. Аерым шигырьләрендә ритм ягы аксаган урыннар да юк түгел. Шикләнмим, киләчәктә ул боларга игътибар итәчәктер.

Шагыйрь Шәүкәт Гаделшаның төп үзенчәлеге нәрсәдә? дигән сорауга мин үземчә җавап таптым шикелле.

Күтелмәгән шигъри ачышлар. Драматизм. Каршылыклы, киеренке хисләр гармониясе. Кырыс матурлык, чынбарлык. Фәлсәфи-лирик агым. Авыр чакларда да рухын төшермәгән бунтар шәхес…

Бер сүз белән әйткәндә, Ш. Гаделша шигъриятенең төп үзенчәлеге – аның кабатланмас шагыйрь булуында икән.

Моңлы сазың кулыңнан төшмәсен, шагыйрь дустыбыз!

Язмамны Ш. Гаделшаның ижатына хас бер шигыре белән төгәллим.

**Чалдун теле**

*Юк. Көлкече, мескен түгел*
*Чалдун анамның теле.*
*Ул бит татар телебезнең*
*Иң серле, моңлы күле.*

*Ничек аны сай дип әйтим –*
*Төбенә җиткәнем юк.*
*Ничек аны тар дип әйтим, – Ярыннан үткәнем юк.*

*Кайтсам – аның бәпкәсе мин,–*
*Туп-туры чумам, йөзәм.*
*Табигатькә, борынгылыкка Якынаюны сизәм.*

*Эчәм, эчәм – эчкән саен*
*Сусавым арта бара.*
*Күзләр, йөзем, күкрәкләрем*
*Монда күпчеп кабара.*

*Тыңлап телнең яңгырашын*
*Тәмләп елап ашмын.*
*Фәрештәләр монда гына Чайкыйлардыр тамагын.*

*…Ничек мескен булсын*
*Теле чалдун анамның.*
*Күл корыса Себеремдә,*
*Сүнәр теле татарның.*

**Гөлнур Вәлиева,**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты,
Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## ГАЛИМӘНЕҢ ЯҢА КИТАБЫ[25]

Соңгы елларда шигърияткә ныклап аяк баскан, үз стиле, юнәлеше булган Түбән Тәүде районы, Киндерле авылында туган Шәүкәт (Гаделша) Сибгатуллин иҗаты белән галимнәр активрак кызыксына башладылар. Шигырьләрендә җирле тел элементлары, авторның Себер татарларына хас кырыс, шул ук вакытта юмарт, ярдәмчел, табигать җанлы холкы да чагылгангамыдыр, алар күңелгә аеруча якын, өйрәнәсе дә җиңел, рәхәт. Ф.С.Сәйфуллина, Л.Б.Хәбибуллина, Г.Х.Муллачанова әзерләгән диссертация, методик кулланмаларда Ш.Гаделша иҗатына шактый урын бирелде.

Һәм менә чираттагы китап: Тубыл пединститутында белем бирүче филология фәннәре кандидаты Лилия Хәрис кызы Фәизованың кандидатлык диссертациясеннән материалларны эченә алган монографиясе – «Язмышның дәрьясы – Казан-Темән арасы…»

Китапта Ш.Гаделша иҗатының тел байлыгы, фольклор белән бәйләнеше, әдәби-фәлсәфи юнәлеше анализланган. Һәр өч бүлек тә җиңел, аңлаешлы телдә язылган. Монография профессорлар Ф.З.Яхин һәм Ф.С.Сәйфуллина редакторлыгында шагыйрь ярдәме белән дөнья күрде. Шәүкәт ага тәкъдир итү кичәсенә үзе килде.

Кичә Тубыл пединституты рус-татар бүлеге студентлары һәм укытучылары белән бергәләп үтте. Аны профессор Ф.С.Сәйфуллина алып барды. Иң элек студентлар күренекле кунакның шигырьләрен яттан сөйләп киттеләр, аңа җыр бүләк иттеләр. Лилия ханым диссертациясен язу тарихы, китапны бастыру проблемалары, эчтәлеге белән таныштырып китте, Шәүкәт Гаделшага ярдәме өчен чиксез рәхмәтле булуын белдерде.

– Татар әдәбиятыбызны өйрәнүегез бик куанычлы, – дип башлады үз сүзен Шәүкәт ага. – Укытыгыз, анысы өчен рәхмәт.

Тарихыбызны ныклап өйрәнүче белгечләр булуын да теләр идем мин. Атамалар кайдан килеп чыкканлыгын ныклап тикшерәсе бар әле безнең. Аларның килеп чыгышы, хәзер, минемчә, дөрес күрсәтелми.

«Яңарыш» газетасы – татар тормышын чагылдырып барган бер көч. Анда да шигырьләр күп бастырыла. Ләкин һәркем шигырь язу белән мавыкмасын, аның өчен талант та кирәк бит әле. Әгәр талантыгызны сизмисез икән, үз хисләрегезне проза рәвешендә белдерегез –

---

[25] Вәлиева Г. Галимәнең яңа китабы // Яңарыш.– 2008.– № 17 (1376), 25 апрель. – Б. 3.

«парча» дип атала ул. Кешенең кайда туган, кайчан укыган, эшләгәне турында язарга кирәкми, аның башкалардан аерым сезгә ошаган сыйфатын күрсәтегез. Ә газетага язу, уку сезнең телегезне чарлый, саклый.

Киләчәктә арагыздан дипломантлар, тарихчылар үсеп чыгар, сезнең алда эшлисе эшләр күп эле, бик әзерлекле, белемле яшьләр кирәк безгә, – дип мөрәҗәгать итте ул студентларга.

– Кафедрабыз бик матур эшләп бара. Үзебезнең, яшь белгечләребез үсеп чыкты. Күп эзләнәләр, укыйлар, өйрәнәләр. Мондый китап бастыру – ул зур хезмәт, тырышлык сорый. Аны яратмыйча эшләп булмый. Бу очрашуның да нәтиҗәсе булыр, студентларыбыз арасыннан да галимнәр – әдәбият, тарихыбызны өйрәнүчеләр чыгар, чыкмый калмас, – дип күтәренке рухта кичәне йомгаклады Флера ханым Сәйфуллина.

Язмамны китапның авторы Лилия Харис кызы турында берничә сүз әйтмичән тәмамлый алмас идем. Лилия – Аромаш районы, Көсәйкүл авылыннан Тубыл пединститутына югары белем алырга килгән, укып, диссертация яклаган тырыш, үз эшен ахырына җиткерергә омтылучы, үҗәт, батыр, чибәр кыз. Тормыш иптәше Радик белән биш яшьлек Ләйсәнне тәрбиялиләр. Ләйсән матур итеп татарча да, русча да сөйләшә белә, укый да, яза да инде. Яшь гаилә ипотекага квартирын да, кредитка автомашинасын да ала. Лилия үзе машина йөртүче һөнәрен дә үзләштергән. Шундый тормыш белән бергә атлаучы, матур яшәүче кыю яшьләребезгә сокланмый мөмкин түгел. Студентларга да үрнәк, юнәлеш бирүче алар.

**Рауфа Кангазина,**

иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты, Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## ХАТЫНЫМА РӘХМӘТЕМ ЧИКСЕЗ[26]

**Тагын ни әйтим**

(Нәиләгә)

*Күптән масаер иде*
*Кукрәгемдә кычыткан,–*
*Әле ярый бәхеткә*
*Томанлыктан син чыккан.*

[26] Кангазина Р. «Хатыныма рәхмәтем чиксез» // Яңарыш.– 2008.– № 7 (1366), 15 февраль. – Б. 2.

*Курка синнән сихерче,*
*Мәкер корып йөрүче.*
*Канатларым сынганда*
*Син генә ялгап бирүче.*

*Күктән берни кирәкми –*
*Сине биргәне җиткән.*
*Миндәй бәхетле ир-җан*
*Дөньяда юктыр бүтән.*

Шәүкәт Гаделшаның хатынына багышлап язган бу шигырен укыгач, тәэсирләнеп кәгазь битенә текәлеп озак утырдым. Күләме дә зур түгел, ә сүзләрдә күпме мәгънә! Мәдхиянең эзе да юк, бары тик күңел түреннән чыккан саф хисләр һәм шул ук вакытта горурлану да. Күңелемә килгән беренче теләк – шагыйрьнең бар дөньясын үзгәртеп, яшәү мәгънәсен аңлата белгән, илһам биргән ханымны читтән генә булса да күреп карыйсым килде. Көтмәгендә теләгем дөньяга ашты да. Декабрь аенда Казанда үткән Бөтендөнья татар конгрессының 4 нче корылтаена баргач, Шәүкәт абый безне кунакка алып кайтты. Ишекне мөлаем йөзле, тыйнак, сабыр холыклы хатын ачты. Сибгатуллиннар гаиләсе белән танышуыбыз сый тулы өстәл артында барды. Сөйләшкәндә «к» хәрефен катырак әйтүе, Наилә апаның казан яки себер татары түгеллеген белдерде. Әйтүе буенча, тумышы белән ул Пенза ягыннан, әмма Бакуда яшәгәннәр. Этисе Бөек Ватан сугышында Калининградны яулаганда каты яраланып госпитальгә эләгә. Бернинди документы булмаган солдатны врач «өметсезләр» исемле-генә Михаил дип язып тора. Әмма, көтмәгәндә, ул барын да шаккатырып, савыгып аякка баса һәм өстәвенә яңа исемле дә була. Үткән гасырның 60–70 нче елларында Россиядә уку дәрәҗәле санала. 1976 нчы елда Наилә Михаил кызы Казан дәүләт мәдәният институтына укырга керә. Бүгенге көндә ул шәһәрнең «Идел» 7 нче музыка мәктәбендә эшли һәм 80 нче мәктәптә 12 ел инде куратор вазифасын үти, фортепиано буенча дәресләр алып бара. Наилә апа турында күбрәк белер өчен Шәүкәт абыйдан ничек танышканнары белән кызыксынам.

– Миңа тормыш итәр өчен төпле хатын-кыз кирәген аңлый идем. Күңел дөньясы сокланырлыкны таба алмау сәбәпле, 34 яшькә кадәр өйләнергә ашыкмадым. Наилә белән шагыйрь Рафис Корбанның өендә Яңа ел каршылаганда таныштык. Тыйнак, сүзен үлчәп сөйләүче, киң күңелле кыз күзгә үк бәрелеп торды, өстәвенә яше дә минекеннән калышмый, буе да миңа туры килә – туйны озакка сузмадык. Аннары кызыбыз Мәдинә туды. Торырга урын булмады, бик авыр яшәдек. 4 елдан улыбыз Ясир дөньяга килде.

Яшәү шартыбыз шул ук хәлдә иде, торак та, акча да, рәтле эш тә юк… Наиләнең бер дә зарланганы, миңа шартлар куйганы булмады. Белмим, ничек түзгәндер…

– Иратның тормыш баскычыннан югары күтәрелүендә хатынының роле зур, диләр. Сез бу фикер белән килешәсезме?

– Әлбәттә. Юкка гына халык «көлдергән дә, бөлдергән дә – хатын» дип әйтми. Наиләмә рәхмәтем чиксез. Без, ирләр, бигрәк тә себер татарлары, җылы сүзләрне якыннарыбызга әйтергә кызганабыз, әмма алар безнең күңел түребездә. Кыскарак итеп әйтсәм – бүгенге көндә нинди казанышларым бар, аларның барысында да Наиләнең өлеше зур.

– Мәдинә, холкы белән әнисенә ошаган, ахры?

– Әйе. Балаларда күбрәк аның тәрбиясе, шуңадыр үскәндә безгә артык проблема китермәделәр. Икесе дә, мәктәптә яхшы укыдылар. Мәдинә хәзер экология институтында 3 нче курста аспирантурада укый, шунда эшли дә. Шул ук вакытта университетның чит телләр факультетында инглиз телен үзләштерә. Инглиз телендә иркен аралаша, хәтта фәнни мәкаләләр яза. Ясиргә 20 яшь. Ул энергетика университетында укый. Җәйге каникулларында ООО «Арекс» фирмасында үз һөнәре буенча эшләп ала, тырыш, оста куллы, дип хезмәттәшләре мактап та куялар үзен. Инглиз телендә яхшы сөйләшә, укуны тәмамласа, тәҗрибә тупларга чит илгә җибәрергә дә исәп.

– Шәүкәт абый, тудырган түгел, туендырган җир күңелгә якынрак, диләр бит, шулай да Себер ягына сагынасызмы?

– Минем бар тойгы-хисләрем шигырьләремдә. Җавабымны алардан табарсыз

2008 нче ел. Гаилә елы дип игълан ителде, бар күңелдән сезгә гаилә бәхете, җан тынычлыгы һәм бу зур, заманча җиһазланган фатирыгызны тутырып, балаларыгызның сезгә берсеннән-берсе матур, сәламәт, итагатьле оныклар бүләк итүләрен телибез.

**Диләфрүз Фәхретдинова,**
иҗади хезмәткәр, «Яңарыш» газетасы журналисты,
Россия журналистлар Союзы әгъзасы

## ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША: «БУ БИТ МИНЕМ ТУГАН ЯГЫМ; ЯШИ ШУНДА ТАТАР ХАЛКЫМ»[27]

Күптән түгел Казаннан Себергә, туган ягына, Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы, «Яңарыш» газетасының ярдәмчесе, дусты

[27] Фәхретдинова Д. Шәүкәт Гаделша: «Бу бит минем туган ягым; яши шунда татар халкым» // Яңарыш.– 2008. — № 18 (1377), 2 май. – Б. 4.

«Карт аучылар сөяк чаба – / Өлешләргә бүләләр./ Итне түгел, гуя күчләп/ Гөнаһларын өяләр» («Старые охотники рубят кости/ – Делят на доли./ Не мясо, кажется, в кучи/ Складывают – свои грехи», – продолжается рассуждение лирического героя. Осознавая греховность охотничьего ремесла, герой Ш. Гадельши все же подчиняется закону самосохранения. Но день не становится теплей, так же трещит сосна, внизу – белесый туман, и лирическому герою кажется, что за пригорком, настреляв много, снимают шкуры лосей.

Таким образом, поэт развил в современной татарской поэзии тему Сибири, которая раскрывается через ряд мотивов. Один из них – мотив охоты и охотника. В таких стихотворениях, как «Йөз яшьлек аучы» («Столетний охотник»), «Аучы зары» («Жалоба охотника»), «Аучы җыры» («Песня охотника»), перед читателем открывается необычный, экзотический мир леса, создается несколько чуждый для нашей поэзии образ охотника – защитника лесов и животного мира.

Некоторые стихи Ш. Гадельши («Менә монда болан ауган» («Вот здесь пал олень»), «Башын чуртан судан сонган…» («Из воды щука высунула голову…»)) приближают его взгляды к мировоззрению экзистенциализма, где особенное отношение лирического героя к смыслу жизни подводит к идее о ее бессмысленности, враждебности по отношению к человеку.

В стихах Ш. Гадельши, которые можно отнести к пейзажной лирике, скрыт философский смысл. Стихотворения «Болан күзе» («Олений глаз»), «Болан баскан эзләргә» («На следы оленя»), «Кинәт кенә купты давыл» («Очень резко поднялся вихрь»), «Сорап куйгалый иде…» («Иногда спрашивал…»), «Күл йөрәге» («Сердце озера»), «Карчык зары» («Жалоба старухи») являются отражением философских размышлений поэта о смысле жизни. Пустота и оглушающая Тишина в стихах Ш. Гадельши противопоставляются Жизни, Красоте, Надежде: даже смерть по сравнению с этими понятиями кажется естественнее.

Сибирский топос, представленный в стихотворениях поэтов, приобретает разнообразные смысловые оттенки. Одна из особенностей лирики Б. Сулейманова и Ш. Гадельши – не только олицетворение пространственных образов, но и включение их в систему субъектных отношений. Кроме того, конкретизируя пространство лирического переживания, поэты указывают на связь поэтического образа с реальным топосом – Сибирским краем, который является значимой координатой, как в жизни самих поэтов, так и в переживаниях их лирических героев.

У Б. Сулейманова топос выносится в сильную позицию, т. е. в заглавие произведения. Примерами могут служить стихотворения «Сопра» («Супра» – название родной деревни автора), «Тобол» («Тобольск»), «Түбән Варта» («Нижняя Варта»), «Обьта боз киткәндә» («Ледоход на Оби»), «Самотлорда җәй уртасы» («Середина лета в Самотлоре»), «Төнъяк, тундра» («Север, тундра»), «Салехардка килгәч» («По приезде в Салехард»), где проявляется авторское отношение к некоторым сибирским городам и селениям, которые так или иначе оставили свой след в судьбе поэта. Очень часто в стихах Б. Сулейманова встречается использование топоса «Сибирь», тем самым воссоздается собирательный образ родного края: «Ты родилась в моем сердце,/ до того как меня родила моя мать./ Сибирь, Сибирь, ты единственная на земле,/ Кто достоин моей любви». Или же: «Не говорите/ о моей Сибири:/ «Раньше была проклятой землей»/. Пусть это так,/ Поймите,/ Это моя родная земля,/ О, родная!».

В отдельных стихах топос Сибири конкретизируется: появляются названия больших и малых городов и деревень, которые связаны с биографией поэта. Так, в стихотворении, посвященном родной деревне Сопра, автор перечисляет сибирско-татарские деревни, такие, как Баеш (Баишево), Рәнцек (Ренчики), Киндерле (Киндери), утверждая, что корни его народа здесь, в названиях этих деревень хранится древняя история татарского народа.

В произведениях другого поэта, Ш. Гадельши, топонимы выносятся в сильную позицию реже. Например, в стихотворении «Нинди Төмән?» («Какая Тюмень?») топос «Тюмень» не только использован в названии, но и как эпифора повторяется в каждой строчке стихотворения: «Свободная Тюмень!/ Задумчивая Тюмень!/ Щедрая Тюмень!/ Быстрая Тюмень!/ Моя Тюмень – ворота родного края». Данные строки созвучны с тукаевским «Пар ат» («Пара лошадей»), где прославляется город Казань. Многократный повтор топоса в сочетании с разными определениями-эпитетами показывает, насколько близок автору этот город. Сибирь воспринимается поэтом не только как географическое название, она является колыбелью его родного народа. В творчестве поэтов в характеристике топоса Сибири намечен ряд пространственных

оппозиций. Во многих стихах Сибирь, как «свое», противопоставляется «чужому», т. е. другим местностям. Особенно выделяется противопоставление Сибирскому топосу топонимов Татарстана. Это связано с тем, что, во-первых, Казань воспринимается поэтами как литературная столица, а вовторых, судьбы обоих поэтов так или иначе связаны с Казанью.

В творчестве Б. Сулейманова стихи, посвященные Казани, занимают особое место, так как мечта стать поэтом, стремление войти в мир татарской литературы связаны именно с этим городом. Целый цикл стихов посвящен этой земле, где топос выведен в сильную позицию: «Казан» («Казань»), «Иделдә» («На Волге»), «Күптәнме җәй иде Казанда» («Давно ли было лето в Казани»), «Күренми шул Себер Казаннан» («Да, не видна Сибирь из Казани»), «Казаннан китәр алдыннан» («Перед тем, как уехать из Казани»), «Казанда яз» («В Казани весна») и многие другие. В них отражается восхищение поэта столицей татарской культуры, чувство причастности к ней, но вместе с тем в душе лирического героя всегда хранится образ родного края.

Такую же смысловую оппозицию топосов «Казань» и «Сибирь» можно проследить и в творчестве поэта Ш. Гадельши. Например, в стихотворении «Пышылдый Себердә» («Шепчет в Сибири») посредством анафоры выражено противопоставление двух топосов: «Шепчет в Сибири/ Камыш озера Бурэн:/ – Поспешил, поспешил…/ Шепчет в Казани/ Камыш озера Кабан:/ – Ошибся, ошибся…». Иногда в творчестве Ш. Гадельши (например, в стихотворении «Ике халәт» («Два состояния»)) используется топос «Казань», оформленный в тексте уже в словосочетании «моя Казань», которое указывает на то, что в душе лирического героя произошли некоторые изменения, он уже воспринимает Казань своей, родной.

В стихах Ш. Гадельши также проявляется оппозиция «родина» – «место проживания». Обращение к родовой памяти, наполнение событий настоящего вневременным смыслом проясняет значимость родины, глубину смысла, заложенного в данном понятии. В стихотворении «Язмышымның дәрьясы» («Широта судьбы моей») посредством использования топосов автор заявляет: «Широта судьбы моей – это расстояние между Казанью и Тюменью». Топосы «Казань» и «Тюмень» здесь имеют значение ограничения местности, так как это два очень значимых, самых главных для поэта города.

Таким образом, пространство Сибирского края, его географический ландшафт, историческая судьба сибирско-татарского народа наложили свой отпечаток на формирование особого смыслового топоса в поэзии Б. Сулейманова и Ш. Гадельши.

В стихотворениях этих поэтов неотъемлемым внутренним свойством является историзм, который в литературоведении рассматривается как художественное осмысление конкретно-исторического содержания той или иной эпохи, а также ее неповторимого облика и колорита.

Прослеживая творческий путь Б. Сулейманова, нетрудно уловить ту особенность, что во многих стихах последних лет его лирический герой полон философских размышлений об участи своего народа, его прошлом, настоящем и будущем. Подобные стихи поднимают его творчество на высоту известных национальных поэтов, таких, как Х. Туфан, С. Хаким, Г. Афзал, И. Юзеев, Р. Файзуллин. В последние годы он пишет также публицистические статьи о самоопределении народа, сохранении языка как основного признака нации, проблемах национального образования в регионе.

Стремление глубже понять современные проблемы приводит Б. Сулейманова к изучению прошлого своего народа, оценке его роли и места в истории человечества. В этом плане интересно стихотворение «Мин төп себер татарымын чыгышым белән…» («Я коренной сибирский татарин по происхождению…»), где отражается жизненное и творческое кредо поэта и общественного деятеля Б. Сулейманова. Он утверждает, что сибирские татары – коренные жители Сибири, с этой мыслью связана основная идея его творчества и идеалы в общественно-политической деятельности.

Мысли о настоящем и будущем народа поэт также связывает с уже ушедшими в историю событиями, таким образом в его стихах появляются исторические аналоги. Для Б. Сулейманова историческая Сибирь ассоциируется с каторгой, местом отбывания срока лишения свободы. Сравнивая царскую Россию с современной Сибирью, автор выявляет лучшие стороны сегодняшних достижений. Исторический хронотоп в творчестве поэта раскрывается также в тесной связи с сибирским топосом. Так, в стихотворении «Тобол», в частности обращаясь к городу Тобольску, поэт пишет, что «До октября в России/ Славился своими тюрьмами/ Старый Тобольск…»; «Когда через тебя в тихую Сибирь,/ проходили декабристы/ Кровь их здесь пролилась…»; «А ты, Тобольск,/ Кажется, вырос/ Из земли, где покоятся каторжане». Оппозиция «прошлое – сегодняшнее» в этом случае служит для положительной оценки современности: новостроек, красивого вида города, счастливой жизни горожан.

Раскрывая противоречия сегодняшней жизни, Б. Сулейманов нередко обращается к историческому прошлому. В стихотворении «Әйтмәгез Себерем хакында» («Не говорите о моей Сибири») описывается состояние души лирического героя, который погружается в философские раздумья о прошлом.

В стихах многих современных поэтов часто упоминается государство Булгар и одноименный город как святые места для тюркских народов. В этом отношении и творчество Б. Сулейманова не является исключением. Размышления его лирического героя у развалин Великих Булгар связаны с историей, воскрешением великого прошлого, он приходит к выводу о том, что у всех тюркских народов общие корни. Такие стихи, как «Иделдә» («На Волге»), «Уйный җилләр нинди кылларда» («Играют ветры на каких струнах»), созвучны с тукаевским «Кичке азан» («Вечерняя молитва») и некоторыми стихами Г. Афзала, М. Шабаева, И. Юзеева, Р. Хариса. Можно отметить, что образ родного края объединяет в единое целое разные чувства и мысли поэта: идеи патриотизма, сплочения народов, ответственности, которые в конечном счете в творчестве Б. Сулейманова выливаются в философскую и эстетическую концепцию.

Во многих стихотворениях Ш. Гадельши как роковое время расценивается потеря сибирскими татарами своей государственности. Топос Сибири здесь воспринимается как трагический хронотоп. Эта особенность ярко проявляется в таких стихотворениях поэта, как «Хәзинә» («Богатство»), «Күңел елый» («Душа плачет»), «Булмас бүтән уңай вакыт» («Не будет другого удобного случая»), «Ни диим» («Что сказать») и др. Прошлое Сибири – печаль сегодняшних дней, заявляет поэт. В стихотворении «Сазлык» («Болото») поэт размышляет о будущем страны, где основной идейный замысел произведения вложен в последние строчки стихотворения, которое заканчивается риторическим вопросом: «Такое болото только одно ли,/ Много ли их?/ Кто знает?/ Утонет ли народ в счастье/ В такой заболоченной стране?» Таким образом, события прошлого поэтом оцениваются с позиций современных представлений. В стихотворении Ш. Гадельши «Бармы ирләр?» («Есть ли мужчины?») исторический герой хан Кучум предстает в роли национального идеала. В таких стихах соединение исторических образов с реальными событиями и судьбами формирует представление о взаимосвязи прошлого и настоящего нации.

Трагическая история края высвечивается в творчестве Ш. Гадельши через изображение топоса и порождает противоречия в оценке поэта. Например, в стихотворении «Себер диләр аны, Себер…» («Сибирью называют ее, Сибирью…»), с одной стороны, подчеркиваются богатство края, древность его истории, героизм прошлого, с другой – досадность некоторых исторических страниц, неизвестность будущего: «О, сибирский татарин, что сказать?/ Лишь для того, чтобы только Ермака, Кучума/ Оставить в истории,/ Родился ты на этот свет?». В таких стихах сибирский топос является смысловым, организующим центром текста. Обращаясь к Сибири, поэт как бы хочет «достучаться» до сибирских

татар, которые безмолвствуют, когда грабят их леса, у бескрайней некогда тайги появился чужой хозяин, который неумолимо истребляет ее.

Таким образом, в творчестве сибирско-татарских поэтов в масштабе хронотопа происходит постоянное совмещение мотивов «современного» и «исторического», «индивидуального» и «всеобщего», «однодневного» и «вечного». Историзм мышления позволяет поэтам поднять проблему самоопределения человека в мире. Историческое время для рассмотренных здесь поэтов Сибири заключает в себе особый сакральный смысл, который базируется на вневременных нравственно-эстетических ценностях. В произведениях Ш. Гадельши и Б. Сулейманова высвечены позитивные и негативные тенденции развития общества, затрагиваются многие актуальные проблемы, присущие региону.

**Фаизова Лилия Харисовна**

## СЕБЕР-ТАТАР ШАГЫЙРЕ Ш.ГАДЕЛША ИҖАТЫНДА СТИЛИСТИК ФИГУРАЛАР КУЛЛАНЫЛЫШЫ[37]

Әдәби әсәрнең бөтен тәэсир көче аның тел байлыгы аша бирелә, шуның белән ул укучының күңеленә үтеп керә. Һәр шагыйрь әсәрләренең теле аша үзенең уй-фикерләрен башкалардан аермалы итеп әйтеп бирергә, шул ук вакытта аңа кадәр кеше күңеленең һичкем күрмәгән, белмәгән якларын ачарга омтыла. Халкыбызның рухын чагылдыручы бай мирасыбызны тирәнтен өйрәнеп, нечкә сиземләгән һәм шул күңел хәзинәсен яңа шартларда, сүз сәнгатенең яңа югарылыгына күтәреп яңгырата алган шагыйрь укучыларга яңадан-яңа яклары белән ачыла бара.

«Матур әдәбият милли телнең барлык синтаксик җегәрен дә тулы кулланырга тырыша. Әдипләр, гадәттә, табигый, нормаль тезелгән җөмләләр белән язалар. Бу бигрәк тә драмада, прозада ачык күренә. Олы художниклар гадәти сүзләр белән төзелгән гадәти синтаксик конструкцияләрнең дә зур шигъри мөмкинлекләре булганлыгын раслыйлар.

Шуның белән бергә фикерне сурәтле, сәнгатьчә йогынтылы итеп әйтү нияте белән җөмлә төзелешенә үзенчәлекләр дә кертәләр, терле фигуралар белән баеталар», – дип яза ф.ф.д., профессор Ф.Хатипов. Димәк, әдәби әсәрнең уңышы тулысынча язучы-шагыйрьнең гади сүзне дә үтемле, сәнгатьле итеп бирә алуына бәйле.

[37] Фаизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш.Гаделша иҗатында стилистик фигуралар кулланылышы // Занкиеввские чтения: материалы Всероссийской научно-практической конференции. – Тобольск: ТГПИ им. Д.И. Менделеева, 2007. – С. 63–65.

Себер-татар шагыйре Ш.Гаделшаның шигъри әсәрләрен җентекләп өйрәнү барышында аның кабатлау алымнарын яратып куллануына игътибар итәргә мөмкин. Хикәяләү интонациясенә кабатлаулар шактый үзенчәлекле яңгыраш бирәләр. Кабатланучы сүзләрнең, тезмәләрнең нинди урында килүенә карап, аларны төрле исем белән билгеләп йөртәләр. Ш. Гаделша ул кабатлауларны сөйләмне бизәү өчен генә түгел, ә мәгънәне көчәйтү, укучының игътибарын шул кабатлау алымы аша әйтергә теләгән фикергә юнәлтү өчен куллана.

Кабатлауларга нигезләнгән стилистик фигура – **янәшәлек** Ш.Гаделша шигырьләрендә бик еш күзгә күренеп китә. «**Янәшәлек** дип тиңдәш синтаксик конструкцияләрнең бер-берсенә янәшә (параллель) куелуын атыйлар» (Заһидуллина, 2004). Димәк, янәшәлекнең нигезендә охшашлык ята. Бу җәһәттән ул чагыштыруларга да якын тора. Төрле күренешләр гүяки бер-берсе янына, янәшә куелып карала. Шул рәвешчә, җөмләләр бер-берсен көчәйтеп киләләр, янәшә торганда аларның мәгънәсе тирәнрәк ачылып китә.

*Яз* – бөтен тереклек дөньясына ниндидер җанлану, өмет китерүче, кышкы йокыдан уятучы ел фасылы. «Март төне» шигырендә Ш.Гаделша язның якынлашуын беренче булып инстинктив рәвештә хайваннар сиземләвен күрсәтә: әле язның башы гына, чөнки карлар да эремәгән, авыл йоклый (бу очракта уңышлы кулланылган метонимияне дә күрә алабыз), якты нурын сибеп ай яна, яшь җилкенчәкләр тыныч кына тыңлашып ята, ә менә яшь тана абзарда тыныч кына тора алмый, ыңгыраша. Түбәндәге юлларда янәшәлек алымының әһәмияте гаять зур:

*Карга чумып **йоклый авыл,***
*Күктә чәчрәп **ай яна.***
*Сузып-сузып **ыңгыраша***
*Аргы очта **яшь тана.***

Табигать үзенекен итә, яз килүен мәчеләр дә сизәләр. Бу юлларда – һәркайсы күзгә ташланып һәм колакка хушаваз булып ишетелгән җанлы тормыш, язгы уяну билгеләре:

***Түбәләрдә** дәртле тетрәү, –*
***Мәче туе тәгәри.***
***Усал карчык** таяк тотып*
***Йөгерә өе тирәли.***
*Тәрәзәгә маңгай терәп –*
*Күрше **бабай** сөйләнә... («Март төне»)*

Бу юлларда да янәшәлек сурәтлелекне арттыру, катлауландыру өчен, әсәргә хис-тойгы өстәү, образлылыкны көчәйтү, сөйләмнең тәэсир куәтен үстерү өчен бик файдалы чара булып тора.

Капма-каршы мәгънәле җөмләләрнең параллель килүен тәшкил иткән икенче бер алымны **антитеза** дип атыйлар. «Ләкин монда бер төрле күренешләр түгел, капма-каршы сыйфатлы картиналар алына, каршылык күп вакытта антонимик, кискен аермалы сүзләр белән белдерелә. Алар бер җөмлә эчендә түгел, төрле җөмләләрдә урнашалар. Фикер, шулай итеп, рәсемдәге кебек, контраст фонда ачыла, каршылыклы янәшәлек эффекты файдаланыла. Грекча антитеза (antithesis) каршы кую дигәнне белдерә». Кайбер шигъри әсәрләр бөтенләе белән антитеза алымына нигезләнә ала. Мәсәлән, Ш.Гаделшаның «Болан күзе» шигыре шундыйлардан:

| | |
|---|---|
| *Күл буенда уйный* | *Урман итәгендә* |
| *Сабый болан.* | *Ана болан.* |
| *Аның күзләренә* | *Аның күзләренә* |
| *Дөнья тулган.* | *Ниләр тулган?* |
| *Ап-ак болыт,* | *Күрә алсагыз әгәр:* |
| *Кояш,* | *Кайгы, яшь юк, –* |
| *Яшел үлән,* | *Дөньябызны йотарлык бушлык!* |
| *Чишмә,* | |
| *Чык сафлыгы ингән.* | *(«Болан күзе»)* |

Шигырьнең беренче строфасын укыганнан соң укучының күз алдына матур күл буенда уйнап йөргән сабый болан пәйда була. «Күзләренә дөнья тулган» дигән бер юл белән автор сабый боланга тулы характеристика бирә алган. Шагыйрь өчен дөнья ул – болыт, кояш, яшел үлән, чишмә һ.б. Сабый болан, яшәү символы буларак, шушы барлык төшенчәләрне үзенә туплаган. Әсәрнең дәвамында сабый боланга каршы куелган «ана болан» образы кертелә. Ул инде тормышта күпне күргән, ачысын-төчесен татыган, дөньяда куаныч, яратудан башка ерткычлык та барлыгын яхшы белә. Шул рәвешле, сабый боланга ана болан образының капма каршы куелуы әсәрдәге беренче антитезаны тудыра. Шигырдәге икенче каршылык тагын да тирәнрәк, ул антонимик сүзләр рәвешендә бирелә: бу сабый болан күзендә чагылган дөнья һәм ана болан күзенә тулган шушы дөньяны йотарлык **бушлык.** Бу очракта инде яшьлек – олылык, тәҗрибәсезлек – тәҗрибәле булу каршылыгы белән бергә **тормыш, яшәү, дөнья** һәм **үлем, тынычлык,** бушлык төшенчәләренең каршылыгы да тасвирлана.

Шагыйрьнең «Ике халәт» шигыре дә капма-каршы күренешләрне (халәтләрне) янәшә куюга нигезләнгән:

*И, Казаным!*
*Шатлык килде!*
*Нинди генә рәхмәтләрем*
*Әйтим үзеңә!*
*Аяз күгең*
*Охшый бүген*
*Улын имезеп ләззәтләнгән*
*Болан күзенә.*

*И, Казаным!*
*Кайгы килде…*
*Нинди генә усал сүзләр*
*Әйтмим үзеңә?*
*Аяз күгең*
*Охшый буген*
*Чебен күреп киерелгән*
*Елан күзенә.*
*(«Ике халәт»)*

Кеше тормышы, кеше табигате – каршылыклар иле. Күңел хәзер бер төрле, ә икенче мизгелдә – башка төрле. Әсәр барышында төрле җөмләләр эчендә урнашкан «шатлык –кайгы», «рәхмәтләр – усал сүзләр», «әйтим – әйтмим» антонимнары, капма-каршы мәгънә белдергән «болан күзе – елан күзе» сүзтезмәсе ярдәмендә төзелгән, авторның югары зәвыгы бөркелеп торган шигъри юллар укучының үйзиһенен биләп ала, йөрәгенә үтеп керә.Түбәндәге антитезалар шулай ук контраст фонда тойгыны көчәйтүгә ярдәм итә:

*Мулла бабам куылганда*
***Алтынын күмгән,** имеш.*
*Чалдон бабам **ачтан үлгән,***
*Камыш чәйнәгән килеш.*
*(«Сазлык»)*
*Күзләрем **еламсырый,***
*Ирен **елмая,***
*Маңгаем җыерчыгы*
*Тирән **уйлана…***
*(«Беренче китабымдагы портретыма»)*

Фикерләрнең я тегесе, я монысы гына аерым алып язылган булса, гади теркәү килеп чыгар иде. Болай берсен икенчесе янына янәшә китереп кую, бер сыйфатның яки халәтнең нкенчесен инкарь итүе бәрелешү барлыкка китерә, шигъри юлларның тәэсир көче арта.

Беренче мисалда Ш. Гаделша әтисе ягыннан бабасы Һишам хәзрәтнең бик бай булуын, ә энисе ягыннан Алим бабасының бик тә фәкыйрь себер татары булуын күрсәтү максатыннан «мулла бабам – чалдон бабам», «алтынын күмгән – ачтан үлгән» контрастларыннан файдалана. Шигъри юлларга кертелгән «чалдон» диалекталь сүзе «себер татары» мәгънәсендә кулланыла, шагыйрь иҗатында бу сүзнең «чалдун» дигән формасы да очрый. Мәсәлән:

*Рәхмәт, туганнарым!*
*Минем* ***чалдуннарым!***

*(«Яртыясак»)*

*Юк. Көлкеле, мескен түгел*
***Чалдун*** *анамның теле.*

*(«Чалдун теле»)*

Мисалга китерелгән икенче строфа тулысынча метонимияләргә нигезләнгән. Шагыйрь күренешне туры мәгънәдәге сүз белән белдермичә (шагыйрь **«мин»** еламсырыйм, елмаям, уйланам» дип әйтми), ул күренеш белән бәйләнешле (мисалда **«мин»нең** әгъзалары – күзләр, иреннәр һәм маңгай җыерчыгы) нисбәт детальләре ярдәмендә бәян итә. «Еламсырый – елмая – уйлана» төшенчәләренең капма-каршы куелуы лирик геройның халәте буталчык, аңлаешсыз булуын укучыга җиткерә.

Ш. Гаделша иҗатында антитеза алымына күпсанлы мисаллар китерә алабыз: **«карт** идем – булдым **егет»,** «әгәр **берәрсе егылса** арып, җирне **икенче күтәреп алыр», «шарак шаулап** торган җирдә **йолкыш бушлык** күренә лә» һ.б. Бу поэтик алым шагыйрьнең әсәрләрен кабатланмас итә, төп фикерне бирүдә уңышлы чара булып тора.

Димәк, югарыда китерелгән мисаллар телебезнең нәфис бизәкләрен саклау һәм баету юнәлешендә себер җирендә туып үскән шагыйрь Ш.Гаделша иҗатының әһәмияте гаять зур булуын раслап тора.

**Фаизова Лилия Харисовна**

## СЕБЕР-ТАТАР ШАГЫЙРЕ Ш. ГАДЕЛША ИҖАТЫНДА ХАЛЫКЧАН ПОЭТИКА[38]

Шигъриятнең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше мәсьәләсе күп галимнәрне кызыксындыра. Бу проблеманы яктыртуга шактый күп хезмәтләр дә язылган. Себер-татар шагыйре Ш. Гаделшаның тирән мәгънәле, үзенчәлекле фәлсәфәсе белән сискәндерүче, татар шигъриятен яңа мотивлар, образлар белән баетучы иҗаты поэзиянең фольклор белән тыгыз бәйләнешен раслап тора. «Шәүкәт Гаделша иҗатында язма әдәбият традицияләре белән янәшә, халык авыз иҗаты традицияләре көчле агым булып бара. Күп очракларда соңгысы алдырып алып та китә», – дип яза язучы, тәнкыйтьче Галимҗан Гыйльманов».

[38] Фаизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш.Гаделша иҗатында халыкчан поэтика // Тумашевские чтения: Актуальные проблемы тюркологии: материалы Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 80-летию академика Д.Г. Тумашевой (г. Тюмень, 19 октября 2006 г.). – Тюмень: Изд-во Тюменского государственного университета, 2007. – С. 237–245.

Безнең фикер буенча да, Ш. Гаделша иҗаты әдәби традицияләргә нигезләнгән булса да, анда фольклор элементларына гаять зур урын бирелә. Шагыйрь туган телен хөрмәт итә, аның кадерен аңлый, шул телдә сакланган әкиятләрне, ышануларны, йолаларны хәтерендә тотып, әсәрләренең тукымасына кертә, кирәк урыннарда шигырь юлларын җирле сөйләм сүзләре белән баета. Бу фикерне әдипнең шигырьләрендә еш очраган «сыктау» – елау, «серәнкә» – шырпы, «томшык» – борын, «бичә» – хатын, «әкә» – агай кебек диалектизмнар дәлилләп тора.

Халык теле гәүһәрләрен иренмичә, җентекләп җыю белән һәр шагыйрь шөгыльләнә. Бу– җитди һәм мөһим эш. Ләкин һәрвакыт иҗат иткән мәкаль-әйтем, поэтик бизәк, төрле тасвир чараларын әзер килеш, үзгәртмичә куллану нәтиҗәсендә бер генә шагыйрь дә сүз сәнгате остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган. Ш. Гаделша бу хакта, бәлки, уйланмагандыр да. Шигъри талант, поэтик тукыманы үзенчә «чигүләргә» тырышу, сүзгә таләпчән булу, әсәрнең идея-эчтәлеге, сәнгатьлелек дәрәҗәсе халыктагыны үзгәртеп алуны таләп итәләр. Шагыйрь вакыт-вакыт шигъри юлларын мәкаль-әйтемнәр белән төзи:

*Аерылганны аю түгел*
*Авыр уйлар ашаган.*
*(«Авыру чебеш күк боегып…»)*

Халыкта: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», – дигән мәкаль бар. Ш. Гаделша, әсәрнең идея-эчтәлеге таләп иткәнчә, бу мәкальне үзгәртеп кенә калмый, ә яңа поэтик бизәкләр өстәп, эчтәлеген тәңгәл килә торган мәгънәләр белән куертып, шигъри хис-тойгыны күпкә арттырып җибәрә.

Мәкаль-әйтемнәр һәм җырларның әдәбиятка тәэсире турында: «… җир йөзендә мөстәкыйль бер халык бар икән, ул халык әйтемсез һәм җырсыз яши алмый. Фольклорның борынгы һәм әле бүген дә заманча яңгыраган бу төрләре туган телнең, милли фикерләүнең аерылгысыз бер өлеше булып торалар», – ди фольклорчы-галим Ф. Урманчеев. Шулай, Ш. Гаделша мәкаль-әйтемнәрне әсәр тукымасын чигүләү, «нурландыру» һәм төрле лексик мәгънәле сүзләрдә бирелгән яки бирелеп бетмәгән төшенчәләрне көчәйтү, үткенәйтү, укучы күңеленә үтемле итү максатында да куллана. Алар әсәрдәге лирик геройның тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешен, шактый зур вакыйгаларны сурәтләү-тасвирлауга ярдәм итә:

*«Укны мылтык җиңде» дип,*
*Тәүге тапкыр язылган.*
*(«Төлке һәм тарих»)*

Шагыйрь үзе дә мәкаль-әйтемнәр иҗат итә. Бу – хикмәтле сүз әйтү алымы.

*Тәртәгә җигелмәгән ат*
*Тибешә, тешләшә.*
*Сөймәгән, сөелмәгән зат*
*Кешедән читләшә.*

*(«Тәртәгә җигелмәгән ат…»)*

Мисалда шактый катлаулы күренешләрнең гомумиләштереп бирелүе сәбәпле бу шигъри юллар мәкаль формасын ала.

Ш. Гаделша сүзнең мәгънәсенә, аның тылсымлы көченә, сәнгатьлелек дәрәҗәсенә җитди игътибар бирә. Шагыйрьнең эстетик идеалы, поэтик фикерләве халык теленә барып тоташа. Аның гадилеге, аһәңле яңгырашы әдип өчен соклангыч өлге булып тора, телнең кабатланмас бизәкләре аңа кыйммәтле табышлар китерә. Шагыйрь иҗатының халыкчанлыгын билгеләгән поэтик гәүһәрләр арасында, мәкаль-әйтемнәр белән беррәттән, аеруча сизелерлек сәнгать көченә ия булган халыкчан фразеологик берәмлекләрнең әһәмияте гаять зур.

Зур акыл ияләренең поэтик фикерләве нәтиҗәсендә барлыкка килеп, борынгы чорларда ук телебезгә кереп, хәзергәчә сакланган фразеологик әйтемнәрне Ш. Гаделша шигырь тукымаларында еш куллана. Болар – җан, күңел, йөрәк сүзләре ярдәмендә ясалган түбәндәге тотрыклы төзелмәләр:

*Урманнарым*
*Җанын биреп яткан*
*Сугым кебек тибенә…*

*(«Элек тә бит, самолетлар очса…»)*

*Җан чыгарып яткан поши*
*Җылысына сыенам.*

*(«Поши аткач»)*

*Кемнәр шулай туган җирнең*
*Җан җелеген актаралган?*

*(«Аллам ишетмәгән»)*

Мисалдагы «җанын бирү», «җанын чыгару» кебек фразеологик әйтемнәр «үлеп бару» мәгънәсендә бирелсә, «җан җелеген актару» төзелмәсе туздырып, ватып, җимереп ташлау мәгънәсендә кулланыла.

Халык телендә берәр авыр кайгы, үлем-җитем, фаҗигалар кичерүдән, я кызганудан йөрәкнең җәрәхәтләнүен сурәтләүче «йөрәк телгәләнү» әйтеме «йөрәгемне төнлә телә» формасында әсәргә килеп керә:

*Күпме кайгы-хәсрәтләрем*
*Йөрәгемне төнлә телә.*
*(«Күпме хата, гөнаһларым…»)*

Ш. Гаделша халык иҗатына хас поэтик фразеологияне эшкәртүдә аеруча зур осталык күрсәтә. Халык телендә йөри торган бик каты рухи борчылуны белдергән «йөрәк бавырын ашау», тирән борчылу я бер-бер күңелсез хәбәрдән йөрәкнең кагып авырта башлавын образлы аңлату максаты белән кулланылган «йөрәк кузгалу» тәгъбирләрен автор себерчә мәгънәдәш «йөрәк тамыры тартылу» әйтеме белән алмаштыра:

*Йөрәк тамыры*
*Шартлап тартылды.*
*(«Ышык бирләрдә»)*

Ш. Гаделша иҗатына фразеологик берәмлекләр әзер килеш кенә килеп керми. Аларның кулланылышы әсәрнең идея-эчтәлегенә, чорга, шагыйрьнең эстетик идеалына, үзе яшәгән вакыттагы халыкның тормыш-көнкүрешенә, эчке дөньясына, рухи халәтенә бәйле. Алдагы мисалда «йөрәгем эреде» традицион төзелмә белән янәшә, шушы фразеологик берәмлек һәм «күңел имрәнү» әйтемнәре синтезының нәтиҗәсе буларак килеп чыккан себер татар теленә хас «күңел йомшанды» тәкъбире белән автор уңышлы файдалана:

*Нигәдер күңлем йомшанды, йөрәгем эреде*
*Сукмакка басарга куркамын.*
*(«Сагая карт урман»)*

Мәгънәдәш фразеологик тәкъбирләрне шигъри юлда янәшә куеп ул шигъри сөйләмнең эстетик-экспрессив көчен, мәгънәсен, эмоциональлеген тирәнәйтүгә ирешә.

«Һәрбер милләт, һәрбер халыкның үз йолалары, гореф-гадәтләре буыннан-буынга күчеп, борын заманнардан бирле яшәп килә. Себер татарларында бүгенге көнгә кадәр мәҗүсилек, ислам дине һәм башка халыклар белән аралашып яшәү тәэсирендә туган гореф-гадәтләр, йолалар, традицияләр сакланып калган», – дип яза Ф.С. Сайфуллина. Шулай, халыкның тел байлыгын, борынгыдан килгән ырым-ышануларын, йолаларын хөрмәт итү, халык авыз иҗаты әсәрләреннән мисаллар

бирү Ш. Гаделша әсәрләренең дә тәэсир көчен арттыра. «Чаптым балта каенга…» шигырендә мәҗүсилек заманнарыннан сакланып калган йолаларның берсе – «яңгыр теләү» йоласы автор тарафыннан сурәтләнә:

*Чаптым балта каенга,–*
*Агач күккә тотынды.*
*Кай арада агылып,*
*Күккә болытлар тулды.*
*«Яңгыр, яу! Яу!*
*Тәти кашык бирермен.*
*Ак каенның тәненнән*
*Юнтып-каеп бирермен.*
*Яңгыр, яу! Яу!*
*Тәмле ботка бирермен.*
*Тәмле каен суына*
*Болгап-бутап бирермен».*

*(«Чаптым балта каенга»)*

Изге теләкләр, сүз көче һәм тәмле ризыклар тәкъдим итү белән табигатькә ялваруга, яңгыр сорауга кайтып кала торган мондый йоланы себер төрки халыкларның күбесендә бүгенге көннәргәчә саклануын күрергә мөмкин.

Мәҗүсилек чоры ышануларының тагын да берсе – кешенең, нинди дә булса тереклек җанының үлгәннән соң билгеле бер үсемлеккә күчүе шагыйрьнең алдагы әсәрендә искә алына:

*Менә монда болан ауган –*
*Ята-ята усак булган.*
*Менә монда куян ауган –*
*Ята-ята куак булган.*

*(«Менә монда болан ауган…»)*

Буыннан буынга күчеп килгән ышануларны хөрмәт итеп, аларны лирик геройның халәтен ачуда файдалануның гүзәл чагылышын Ш.Гаделшанын, «Яңа уй» шигырендә дә күрә алабыз:

*Козгынны атарга*
*Кушмый бит картлар.*
*Нигә соң бу коштан*
*Алар куркалар?*
*Буыннан буынга*
*Күчкән бу тыю…*

*(«Яңа уй»)*

Козгын – гадәттә зиратларда үскән каеннарда оя коручы зур кош. Картларның аңа төбәп атарга кушмавының төп сәбәбе – себер татары фикеренчә, кеше аңында бу кошның үлгәннәр рухы белән ассоциатив күренеш тудыруында дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Шагыйрь иҗатында мәҗүсилек чорыннан сакланып калган йолалар белән беррәттән, ислам диненә бәйле йолалар да чагылыш таба. Шундыйларның берсе – үлгән кешегә «Ясин» укыту йоласы. Ләкин автор бу йоланы үзенчәлекле куллана. Түбәндәге мисалда сүз улгән кешене күмеп, мулладан «Ясин» укыту турында түгел, ә хайванның (пошиның) сөякләрен җыеп, күмеп, җилдән «Ясин» укыту турында бара:

*Язга чыккач, бакча саен*
*Поши сөякләрен җыям.*
*Җилдән ясин укыттырып*
*Бер чокырга күмеп куям.*
*(«Поши ите»)*

Ш. Гаделша шигъриятенең халык авыз иҗаты белән бәйләнешен шигъри юлларында кулланылган сынамышлар да раслап тора. Мәсәлән, бүгенге көндә дә көндәлек тормышта очраган «ризыкны пычак очыннан ашасаң – усалланасың» сынамышы аның иҗатында да чагылыш тапкан:

*Кермэсме, дип, усаллык,*
*Ашыйм пычак очыннан.*
*(«Кайвакытта язмышым… »)*

Әсәрдә лирик герой үзенең йомшак, мәрхәмәтле булуына ачуланып, тормышта усалрак булу да кирәк дигән фикергә килә һәм күңеленә усаллык, кырыслык кертү теләге белән пычак очыннан ашап карый.

«Ашны гадәттән тыш тозлау йөрәктә мәхәббәт ялкыны кабынуның билгесе» дигән сынамышны да автор мәхәббәт шигырендә оригиналь файдалана:

*Онытылып*
*Шулпага*
*Тозны артык салмасмы…*
*(«Юк инде, юк…»)*

Бу очракта фикерне читләтеп әйтү алымы отышлы кулланыла: чынында лирик герой яраткан кызының шулпага тозны артык салуы турында өметләнми, ә кызның күңелендә аңа карата мәхәббәт хисенең тууы турында хыяллана.

Ш. Гаделша иҗатында фольклорның тәэсире әкияти образлар кулланылышында да сизелә. Мәсәлән, халык әкиятләрендә батырга төпсез коедан югарыга күтәрелергә ярдәм иткән Сәмруг кош образы алдагы шигъри юлларга ниндидер серлелек өсти:

*Инде Сәмруг кошы бул да*
*Югарыга күтәр мине.*
*Менгән чакта хәлең бетсә,*
*Ашатырмын йөрәгемне.*
*(«Рухыма»)*

Шагыйрь әкиятләрдәге татар халык иҗатына хас символик образларны байтак шигырьләрендә төп сюжетка бәйләп бирә. Мәсәлән, алтын тарак, алтын балык, су анасы кебек әдәби әкиятләрдән алынган образлар әдипнең берничә шигырендә очрый:

*Су анасын син*
*Буген борчыма.*
*Эзләсен төптән*
*Алтын таракны…*
*(«Бозны чукыма»)*

*Гомер үтте. Алтын балык*
*Картыма тоттырмадың.*
*(«Карчык зары»)*

*Күрсә, алтын балыкны да*
*Алсын әйдә, җәлләмим.*
*(«И Мөдәррис әкә!»)*

Төрки халыкларның фантастик әкиятләрендә еш очраган мәргән образына татар шагыйрьләре яратып мөрәҗәгать итә. Мәргән – оста укчы, төрле кара көчләргә каршы торучы көчле, батыр, ярдәмчел егет. Әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан мәргән образының матур үрнәге булып шагыйрь М. Җәлилнең «Алтынчәч» драматик поэмасының үзәгендәге Җик-мәргән образы тора.

Ш. Гаделша да иҗатында бу образга мөрәҗәгать итә:

*Шикләнмәскә*
*Кирәк, дидем;*
*Миндәй мәргән*
*Сирәк, дидем.*
*(«Аучы җыры»)*

Мисалдагы шигъри юлларда «мәргән» төшенчәсе «оста атучы» мәгънәсендә генә кулланылган.

Шагыйрьнең табигать күренешләре һәм кеше сыйфатлырыныцң тискәре якларын тасвирлаганда халык әкиятләренә, мифларына таянып эш итүен дию, аждаһа кебек символик образлар ярдәменә килүе раслый:

*...Тар сәкедә килмешәк*
*Дию кебек гырылдый.*
*(«Себер авылы тарихыннан»)*

*...Ул аҗдаһа да*
*Булып куяла...*
*(«Йокларга тырыш»)*

Ш. Гаделша ижатында себер татарларының мифларына бәйләнешле образлардан файдалануны да очратырга мөмкин. Мәсәлән, шундыйларның берсе – мәцкәй образы:

*Көлсәгез, көлерсез, дусларым,*
*Бу сәер чагымнан.*
*Себернең мәцкәен – тынгысыз*
*Черкине сагынам.*
*(«Черкине сагынам»)*

«Бу образ күп кенә халыклар мифологиясендә очрый. Бурятларда – маяс хара, грузиннарда – мац-или, Обь угорлары мифологиясендә – мис, монголларда – мичит, алтайлыларда – мечин. Мәцкәй белән бәйле миф-ышанулар шулай ук кытайларда да бар», – дип яза ф.ф.к. М.С. Азисова.

Мәцкәй образы себер татарларының ышануларында әһәмиятле урын алып тора. Мәцкәйнең төп үзенчәлекле сыйфаты – аның сихер-че рухы булуы. Маймыл белән кеше арасындарак торган бу мифик затның җиргә тиеп торган озын кызыл теле бар. Төннәрен ул, утлы шар рәвешенә кереп, очып йөри, кан белән туклана. Башта мәцкәй тавык, этләрнең, сыерлар, атларның – өй хайваннарының канын эчә, соңрак кешегә дә ияләнә. Мәцкәйнең икенче үзенчәлекле сыйфаты – төннәр буе очып йөргәннән соң, яңадан кеше кыяфәтенә керә алуы.

Мәцкәйләр нинди генә образда бирелсәләр дә: кешеме, маймылмы, я утмы – барысына да хас бер үзенчәлек бар – алар канечкеч затлар. Алдагы мисалда черкине «мәцкәй» ди атау аның да кан белән туклануына бәйле.

Шул рәвешле, фольклор әсәрләренә хас образларга мөрәҗәгать итү шагыйрь иҗатының образлылыгын, сәнгатьлелеген арттыру, мәгънәсен көчәйтүдә уңышлы алым булып тора.

**Хәйруллин Илһам**

## ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША – ХАЛЫКЧАН ШАГЫЙРЬ[39]

Әдәбиятны халыкның йөз аклыгы, аның рухи халәте һәм мәдәниятның үсеш дәрәҗәсенең күрсәткече, диләр. Татар әдәбиятының мең еллык тарихы бар дибез һәм аның белән чиксез горурлык хисе кичерәбез. Милли әдәбиятыбыз шул рәвешле бай тәҗрибә туплап, буыннан буынга тапшырыла килә.

70 нче елларда татар әдәбиятына салмак кына, ләкин талантлы һәм үзенчәлекле шагыйрь Шәүкәт Гаделша (Шәүкәт Гаделша улы Сибгатуллин) иҗат дөньясына аяк баса. Шәүкәт Гаделша тумышы белән Түбән Тәүде районы Киндерле авылыннан.

Әдип бер гасырлык татар шигъриятендә үз урыннан лаеклы алган һәм үзенчәлекле, кабатланмас шагыйрь исемен яулауга ирешә. Татар тәнкыйтендә аның иҗатына зур кызыксыну уяна: Булат Сөләймановның иҗади дәвамчысы, дип билгеләнелә.

Шагыйрь Ш. Гаделшаның иҗаты күңелгә якын. Кабатланмас үз стиле булган әдип: аның иҗатында ниндидер аңлатырдай түгел, һәрвакыт кабул итмәслек сагыш хисен табарга мөмкин. Әлеге хистә без ананың баласына һәм баланың ата-анасы йортына карата сагынуын, өлкән кешенең үткән гомере хакында уйлануын күрәсең. Шулай ук әдип кешелек тарафыннан табигатькә карата эшләнгән вәхшилекләрне күрергә, инсаннарга уйланырга кирәклеге турындагы өндәмәләрне укырга булыр иде.

«Себер – халкымның асыл бишеге», – дип яза шагыйрь. Чыннан да, Шәүкәт Гаделша иҗатында Себер темасы зур урын алган. Шигырьләрендә авторның халкыбызның тарихы, хәтере һәм милли үзаңын күтәрү мәсьәләләре чагылыш таба. Себер – шагыйрь тарафыннан географик урынчалык буларак кына түгел, ә татар халкының яшәеш бишеге дип тәкъдим ителә. Мисалга «Черкине сагынам» шигырен китереп булыр иде:

*Черкине тыңласам тынлыкта*
*Оета тирән моң.*
*Хәтерем урманын, күз йомып,*
*Үтәләй күрәмен.*

---

[39] Хәйруллин И.Р. Шәүкәт Гаделша – халыкчан шагыйрь // Сулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч. – практ. конф. «Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы. Тюмень: Печатник, 2014. С. 85–87.

Аның шигъриятендә Себер табигатенең торышы һәм аны саклый алмавы өчен лирик каһарманның рухи борчылуы чагылыш табып, әдипнең менә шушында инде иҗат дәрьясының яңа ясыллыгы – «кеше-табигать» бәйләнеше билгеләнә. Образлар системасының үзенчәлекләре Ш. Гаделшаның үзе Себер җирлегендә тууы белән аңлатып булыр иде, ягъни аның туган төбәге табигатенә карата битараф булмавын ассызыклыйсы килә:

*Югалды барыр ноктам.*
*Сүнде соңгы өмет.*
*Качып ятам урманда,*
*Кайгырьш, яшем түгеп.*
*Салкын кыш наратларны*
*Йомычкалый, телә.*
*Йөрми җәнлек, очмый кош -*
*Оясында үлә.*

Ш. Гаделшаның иҗаты гомер кичергән аксакалларның фәлсәфи уйлануларын дип тә кабул ителергә хаклы:

*Бирәм соңгы серәнкәне,*
*Соңгы телемне.*
*Күрәм кеше күңелләрен.*
*Тыңлап күңелемне.*

Шулай да шагыйрьнең төп темаларның берсе булган – пейзаж лирикасына киңрәк тукталасы килә. Үсешкә ирешкән татар әдәбиятында әлеге юнәлеш яңача тасвирланышы белән XX гасырның 60–70 елларында тагын да балкып чыга.

Пейзаж лирикасында шагыйрь урманны Себер табигатенең җыелма образы итеп тәкъдим итә, шулай ук иҗатында урман дөньясының аерылгысыз өлеше – үсемлекләр һәм хайваннар сурәтләнә.

Пейзаж лирикасына алып килгән яңалыгы: фәлсәфи лирика белән бәйләү иҗат итү. Ш. Гаделша шигъриятендәге кошлар образы икенче төрле төсмер ала. Шул рәвешле, минемчә, баллада жанрына бик тә якын килә. Шагыйрь табигать образларын файдалану мөмкинлекләрен арттырып, үз шигырьләренең яңа эчтәлек белән баетты.

Шәүкәт ага шигъри әсәрләрендә, җәнлек образын сурәтләп, ана булу идеясын тормышка ашыра. Иҗатында аеруча зур урынны болан образы тора. Шәүкәт Гаделшаның җәнлекләрне тасвирлаган шигырьләре – ул халыкның яшәеш фәлсәфе. «Һәрбер җәнлекнең үлеме – тормышның туктап калуы», – дип фикер йөртә шагыйрь. «Сагая карт

урман», «Элек тә бит, самолетлар очса…». «Урманнарга кабам», «Заман агачлары» һ.б. шигырьләрендә урман – җәнлекләр һәм үсемлекләр өчен яшәү тирәләлеге, әгәр ул (урман) бетсә, алар да эзссез югалачаклары-на ишарә ясый. Экология мәсьәләсе актуаль булып кала бирә, шуңа күрә, шагыйрь фикеренчә әйтсәк, җәнлекләр белән яндырылган урман – яшәешнең юкка чыгуы белән тиң. «Поши аткач»:

*Шундый салкын. Нарат шартлый.*
*Эт селәгәе боз булган.*
*Җан чыгарып яткан поши*
*Җылысына сыенам.*

Лирик герой уйга кала, үзен хәзер кем дип санарга? Аучымы? Үтерүче-вәхшиме? Әлеге сорауларны бөтен Галәмгә җиткереп, гәрчә Аллага ыпланмаса да, үзе дә белмичә, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә.

Шагыйрь Себер темасын үз әсәрләрендә берничә яссылыкта яктырта. Шуларның берсе – ау һәм аучылык. «Йөз яшьлек аучы», «Аучы зары», «Аучы җыры» кебек шигырьләрендә урманның экзотик дөньясы тасвирлана, шулай ук безнең күз алдына аучы образы бөтенләй икенче яктан тәкъдим ителә: ул – урман сакчысы һәм җәнлекләрне яклаучы.

Якташым иҗатына күзәтү ясауны, шагыйрьчә әйтсәк, «Казан белән Төмән арасы – минем язмышымның киңлеге»нә тукталмасам, гөнаһ булыр иде.

Төмән шәһәре шагыйрь өчен кече Ватанның башлангычы. Мәсәлән, «Нинди Төмән?» шигырендә Төмән топонимы исемдә генә түгел, ә эпифора буларак һәр юлда диярлек кабатлана:

*Иркен Төмән!*
*Моңсу Төмән!*
*Юмарт Төмән!*
*Кызу Төмән!*
*Минем Төмәнем – Туган ягым капкасы!*

Әлеге шигъри юлларның Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыре белән аваздаш булуын татар шигърияте белән таныш булган кеше таныр. Төмән топонимы төрле эпитетлар белән бизәп, шагыйрь өчен әлеге каланың ни дәрәҗәдә якын булуын аңларлык.

Шәүкәт аганың язмышы татар милләтенең мәркәзе булган Казан шәһәре белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Ш. Гаделшаның лирик герое ике шәһәр арасында өзгәләнүе һәм үзенең катлаулы тормыш юлы хакында фикерле. Ни гаҗәп: шагыйрьнең иҗатында лирик геройның туган ягын сагынуы – туган җире алдында үзен гаепле санавы белән тәңгәлләшә:

*Авылдашларым җылым тарта,*
*Күл буенда җыйналып,*
*Кулларымны тыгып кесәгә,*
*Читтә торам оялып…*

Лирик герой һәрвакыт эчке таркалышта: ул туган җирен сагына, табигатьнең пычрануы өчен борчыла, ләкин шул ук вакытта үткәнгә кайту юклыгын да аңлый, гомер сөргән аксакалларга кул биреп исәнләшә дә алмый, чөнки ул алар өчен чит-ят кешегә әверелгән, ул хәзер – кайткан кеше, шәһәрнеке.

*Нишләргә? Куллар шома, хәлсез,*
*Үлгән чабак төсендә.*
*Шундый куллар белән кайтканны*
*Монда халык чит итә.*

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: беренчедән, Шәүкәт ага үз иҗатында мул итеп сурәтләү чараларын куллана: анафора («И, Казаным!»), эпифора («Нинди Төмән?»), рефрен («Әүхәт энемә хат», «Беренче кар», «Күпме хата, гөнаһларым», «Уян», «Черки»); икенчедән, ул халыкка аңлаешлы һәм шул ук вакытта тирән фәлсәфәгә корылган шигырь язучы; өченчедән, үз әсәрләрендә Себердә яшәүче татарларның мифологиясен урынлы куллана белүе белән үз иҗатына чиксез кызыксындыру уята; дүртенчедән, аның иҗаты буенча Тубыл дәүләт педагогика институты аспиранты Лилия Харис кызы Фәизова кандидатлык диссертациясен яклый.

Бүгенге көндә шагыйрь Казан шәһәрендә яшәп иҗат итүен дәвам иттерә, ул дистәгә якын китап авторы: «Ярык мөгез», «Ядрә тигән», «Сөмән кадыйм», «Җилгә моң дыңгычлыйм», «Аучы җыры», «Чоңгыл».

**Харрасова Рифа Фатхрахмановна**

## Ш. ГАДЕЛША ПОЭЗИЯСЕНДӘ ТӘҮГЕ ҺӘМ СОҢГЫ СТРОФАЛАР ЭМОЦИОНАЛЬЛЕГЕ[40]

Шигъри әсәрнең тәэсир көче аның ритмик яңгырашына, эчтәлек һәм форма мөнәсәбәтенең дөрес сайлануына, эпиграфларының яңалыгына һәм отышлы табылуына, лексик катламның байлыгына һәм фикер куәсенә, аерым сүзләрнең доминанта позициясенә, тема-

[40] Харрасова Р.Ф. Ш. Гаделша поэзиясендә тәүге һәм соңгы строфалар эмоциональлеге // Сулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч. – практ. конф. «Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы. Тюмень: Печатник, 2014. с. 93–97.

проблемаларның актуальлегенә, образларның байлыгына, сөйләмнең метафоралылык дәрәҗәсенә һәм башка эреле-ваклы элементларга барып тоташа.

Кулланылыш максаты белән үк эмоциональ сөйләм булырга тиешле әдәби әсәр теле укучыга төрлечә йогынты ясый. Язучы бигрәк тә бүгенге буш сүз, купшылык, үтә төчелек, үгет-нәсихәт белән генә үзенә якынайта алмый, яңа заман аннан тирән мәгънә, һич югы тәгаен сурәтләнгән картиналар, шул картиналарның гомуми җирлегендә ачык күренеп торган буяулар – игътибарны үзенә тартып-тартып алырлык әдәби детальләр көтә.

Нәфис сөйләмнең үз сыйфатлары, алымнары бар. Бигрәк тә шигърияттә эчке хисләрне, үзара мөнәсәбәтләрне белдерү чаралары төрле, әмма аларның барысы да бердәй актив түгел. Иҗатында төп урынны эпитетлар алып торган шагыйрьләр аеруча күп очрый, асмәгънәне бик нык яшереп бирүчеләр һәм тыгыз метафоралыкка ирешү өчен көч күп куючылар да юк түгел, һәр төр троплар белән оста эш итүдә танылганнарны атарга мөмкин. Тезмә формадагы сөйләмгә оста булып та, эчтәлек белән яңалык алып килмәүчеләр, башкаларның уңышларын гына кабатлаучылар, кайбер отышлы образларын берәмләп, чүпләп кенә үз текстларына кертүчеләр бар, һәм шул сәбәпле, кызганыч ки, плагиатор дип атарга ныклы нигез табалмый гаҗизләнәсең.

Чын шагыйрь иҗатыннан теләсә кайсы тел-сурәтләү чарасьш табарга мөмкиндер дип уйлыйм, әмма ул барыбер теге яки бу әдәби алымнарга, тел-сурәтләү чараларына өстенлек бирәчәк. Зур талант иясе булган, әлегәчә әдәбият тарихында тиешле бәясен алып бетермәгән Шәүкәт ага Гаделша да – телнең барлык мөмкинлекләрен файдаланып иҗат итүчеләрдән. Аның язганнарыннан татарлык рухы бөркелеп тора, Себер моңнары ишетелә, күз карашы җитмәс киңлекләр тоемлана.

Шәүкәт Гаделша әсәрләренең югары эмоциональлек дәрәҗәсе аның заман әдәбияты ирешкән биеклекләрдән торып иҗат итүенә бәйле. Ул – ишарәләр остасы, ә бу исә – табигый талант билгесе. Шагыйрь кайбер әсәрләрен кәеф-халәткә бөтенләй бәйләнешсез тоелган хәбәрләрне ирештерүдән башлый:

*Бер урамда*
*Тыныч кына*
*Йөри идем.*
*(«Бер урамда»)*

Әлеге тынычлыкны, гадәтилекне нәрсәдер бозарга тиешлеген гади укучы алдан тоемламаска да мөмкин. Гаделшаның дөньясы мондый тынлыкта, мондый гадәти халәттә озак яши алмый:

*Кинәт…*
*Балкыш!!!*

Беренче юлның өчнокта белән тәмамлануы ниндидер зур бер көчне буып тора кебек. Ул ташкын да, буран да, ташлар яңгыры да булырга мөмкин. Бу очракта исә көчле балкыш булып чыга. Алга таба автор табигый гына итеп:

*Көлеп барган*
*Кызны күрдем,–*

дип яза. Шагыйрь җәяне бер тарткан, бер бушатыш алган сунарчыга охшаган:

*Боз булсам мин,*
*Шул минутта*
*Эрер идем.*

Шулай итеп, хисләр көчеше укучының үзен дә һәрвакыт уйда, ниндидер бер башкалар тарафыннан көчләп тагылганрак та, әмма шул ук вакытта теләп тә алынган кебек киеренкелектә тота.

*Һәм артыннан*
*Гөрли-гөрли*
*Йөгерер идем, –*

дип тезә алга таба лирик мин.

Юлчының игътибарына очраклы гына алынган балкыш күренеше ахыр чиктә, ассоциатив юл белән, персонажның; ерак яшерелгән уй-кичерешләрен ача: ул үз тынычлыгыннан, тормышының бертөслелегеннән туйган булып чыга. Лирик миннең, күңелен дулкынландырырга хәтта яшь кызның бер көлүе җитә!

Шәүкәт Гаделшаның бик күп шигырьләре ассоциатив янәшәлекләрдән, тышкы хәрәкәт һәм тирәлектән алынган теге яки бу предмет аркылы геройның эчке дөньясына ишарә итеп алулардан башлана. Ишарәле тәүге юллар ярдәмендә күңел тибрәнешләрен җыйнак һәм оригиналь тезмәләр ярдәмендә тасвирлау зур осталык сорый. Болай иҗат итү динамик психологизм тудыра. Әлеге алым тибрәнешләрнең күбрәк тышкы чагылышына игътибар юнәлтә торган эсәрләрдә ешрак очрый:

*Югалды барыр ноктам.*
*Сүнде соңгы өмет.*
*Качып ятам урманда,*
*Кайгырып, яшем түгеп.*

«Урманда» шигырендә тәүге строфаның яртысын тәшкил иткән ике юл, кешенең терексезлек хәленә төшә баруын күрсәтү өчен, тыныч кына әйтелсә дә, асылда бик тирән хисләр кичергәнен җиткерә. Алга таба кышкы урман тирәлегеннән алынган янәшәлекләр кешене биләп алган халәтнең озак дәвам иткәндә нәрсәгә китерәсен фаразлап бирә сыман:

*Салкьш кьпп наратларны*
*Йомычкалый, телә.*
*Йөрми җәнлек, очмый кош –*
*Оясында үлә.*

Югарыдагы юлларны укучының, яше чьшмый гына, җаны өзелгәндәй була, һәрхәлдә, шагыйрь аннан шушыңа охшаш хисләр өмет итеп яза сыман.

Ш. Гаделша шигырьләренең тәүге ике юлында ук ниндидер тирән фикер, әсәрнең лейтмотивын җиткерүне максат итми. Ул бигрәк тә лирик миннең, тышкы тирәлектән күреп алган образлары, җанын айкап узган тормыш вакыйгалары һәм аны тетрәндергән күренешләр аша укучыда хис-кичерешләр уятуга керешүне кулайрак күрә:

*Йөгерә ата болан*
*Куакларны ярып…*

«Мөгездәге ярык» әсәрендә төп фикер соңгы строфага калдырылган, тәүгесендә әле аны аңлауга таба беренче адымнар гьша ясала. Иң ахырда автор:

*Җанына тынгы бирми*
*Мөгездәге ярык.*
*Иң ахырдан автор:*
*… Шул үгез хәлендә бит,*
*Дуслар, мин үзем дә.*
*Ахры, ярык булган*
*Хыял мөгезендә, -*

дип әйтер.

Шигъри әсәрнең эмоциональлек дәрәҗәсе, беренче чиратта, шагыйрь субъективлыгына барып тоташа, һәм нәкъ менә әлеге субъек-

тивлык аерым строфаларны һәм тулы текстны бербөтен итеп оештыра. Талантлы язучылар лирик әсәрләрдә шулай ук уенга, хыялга бик күп урын калдыра. Әйтик, Ш. Гаделша текстта виртуаль образлар белән эш итә, тормыш күренешлүрен кинокадрлар кебек ниндидер эзлектә күздән кичердертә:

*Йөрәкне суытып,*
*Буреләр уламый.*
*Каенны сөлкетеп,*
*Кертлекләр уйнамый.*
*Куяннар йөгерми,*
*Яшь талны кимерми.*
*Аръякта аланда*
*Пошилар күренми.*
*Чинатып тычканны,*
*Телкеләр казынмый.*
*(«Йөз яшьлек аучы»)*

Югарыда булмаган эшләрне санаган кебек аңлашылса да, автор асылда ерак үткәнне видеоязмада чагылдырып бирә. Шулай итеп, тормыштан алган күренешләр параллелизмы белән беррәттән, үткән һәм бүгенге янәшәлеге дә тудырыла.

«Ике халәт» шигыренең тәуге строфасында шагыйрь:

*И, Казаным!*
*Шатлык килде!*
*Нинди генә рәхмәтләрем*
*Әйтим үзеңә!,*

- ди. Күргәнебезчә, әлеге шатлыкның реаль эчтәлеге юк, һәм без алдан ук автор аны ачачакмы, әллә сер итеп калдырачакмы икәнне белмибез. Шигырьнең башка строфалары Ш. Гаделшаның һәрвакытта да реаль һәм тәгаен тормыш материалын конструкцияләү, кәгазьгә төшеру белән генә чикләнмәвен сөйли:

*Аяз күгең*
*Охшый бүген*
*Улын имезеп ләззәтләнгән*
*Болан күзенә.*
*И, Казаным!*
*Кайгы килде…*
*Нинди генә усал сүзләр*
*Әйтим үзенә?*
*Аяз күгең*
*Охшый бүген*
*Чебен күреп киерелгән*
*Елан күзенә.*

Югарыда соңгы строфалар,

бер яктан, шагыйрьдә хыялга бирелү сәләтенең зурлыгын күрсәтә; икенче яктан, алар чиктән тыш образлы. Укучыны үзенчәлекле ассоциацияләр белән шаккаттырып кына калмый Ш. Гаделша, әлеге юлларда тормыш күренешләреннән гомумиләштерелгән зур фикерләр яшеренгән. Шатлыкның һәм кайгының сурәте башка, ди язучы, аңа мөнәсәбәт тә төрле.

Газетада басылган шигырьләрнең күбесе укучыны бу серле дөньяга кертә алмый, эстетик зәвыгын тәрбияләми. Мин бу хакта редактор Азат әфәнде Сәгыйтовка әйткәч:

– Килешәм синең белән, – диде. – Шигырьләр көн саен килеп тора. Аларны төзәтергә, авторга җавап бирергә вакытыбыз да, штатыбыз да юк. «Чиле-пешле» әйберләрен бастырмый торсаң, шалтыраталар, язалар, редакциягә киләләр. Безнең күңел йомшак – биреләбез. Укучыларыбыз бит. Бездәге шигырь язучылардан шигъриятне яклап, газетада үзең чыгыш ясамассың микән?

Бер кочак шигырь дәфтәрләре тоттырды. Бик хәйләкәр Азат абый. Шигырь сөючеләрнең күңелләрен мин сындырыйммы инде? Шигырь язу, бәлки, аларның иң төп юанычыдыр, ә өлкәннәрнең – гомер озайту ысулыдыр?

Ниндидер хис, теләк белән сүзләрдән рифмалы, ритмлы тезмә булдыра алу – бу шигырь язуның иң түбән баскычы гына әле. Редакциягә җыелган дәфтәрләр арасында бу баскычка да менә алмаган авторлар да шактый икән: М.Ибраһимова, Ә.Галимов, Б.Нәүрузов һ.б. Мин аларның язмаларыннан бер шигырь дә «әвәли» алмадым. Рифма, ритмны өйрәнә алган чакта да, чын шигырь чыгара алмаслар шикелле.

Менә Нигъмәтуллин Рөстәм, Хәйруллина Гөлнур шигырьләрендә рифма да, ритм да бар. Шигырьләрен Төмәндә китап чыгарган кайбер авторларныкыннан ким дип әйтмәс идем. Барысында да «шул ук – сүз, шул ук – күз, шул ук – йөз» сыман. Шуңа күрә һәр авторга аерым тукталасым килми.

Безнең Төмән поэзиясе яңа туып килә генә. Матурлыкны, вакыйгаларны үзенчә, беркемгә дә охшамаган итеп сурәтләргә тырышулар юк әле. Бизәк-орнаментлар, метафора, эпитетлар, чагыштырулар һәм башка поэтик чаралар бик сирәк кулланыла. Әдәби тәртипләр, традицияләр үзләштерелми. Күп очракта: «урман, чытырман – шигырь костырам».

Әйе, үзең танып белгән дөньяны яратудан, халкыңның, дусишләреңнең, туганнарыңның язмышын уйлап борчулардан шагыйрь-

[45] Шәүкәт Гаделша. Масаерга иртә әле! // Яңарыш.– 11 март 2004. – Б.5.

лек башлана. Һәркемдә шигъри хис ята. Бу – табигый хәл. Тик чын шагыйрь сирәк туа. Ул дөньяны фәкать үзенчә генә күрә, үзенчә генә тыңлый, ишетә. Үзенең көтелмәгән сурәтләре фикерләү, уйлау рәвеше, сөйләме белән укучыны куандыра, ләззәтләндерә, сискәндерә. Чын шагыйрь күпме талантлы булса да, күп укый, каләмдәшләре белән аралаша. Иҗатын камилләштергәннән камилләштерә. Шулай милләтебезнең рухи байлыгына беркадәр кыйммәтлек өсти.

Чын шагыйрь, берәр нәрсә языйм әле, дип өстәлгә утырмый – аңа аһәң Югарыдан килә. Ә Түмән өлкәсендә үзләрен шагыйрь итеп тоючылар «буа буарлык» икән. Китаплар да чыгарып өлгергәннәр. Бу авторларның күбесе өлкәннәр. Җыентыкларында тупланган шигырьләрне якынча гына шигырь дияргә була. Дистәләр еллар татар поэзиясеннән читтә торып, шигъриятнең асылын да онытып, алар шулай үзләренең барлыгын белдерергә булганнардыр. Чын шигъриятне аңларга тырышып та карамаганнар.

Китап чыккач, аны ирең, хатының, авылдашың гына укымый бит. Шигырьне аңлаучылар, белгечләр дә кызыксына. Менә шулар инде синең «буш куык» икәнеңне күрә. Китабыңны укып та тормый, ташлый.

Әйдә, җаны теләгән – елан ите ашаган, ди. Язсыннар, китап та чыгарсыннар дияр идең дә... Булмый шул. Әдәбиятнең дәрәҗәсе, китапның абруе төшүен тели микән соң татар зыялылары?

## ПЕРЕВОДЫ СТИХОВ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ НА РУССКИЙ ЯЗЫК

Поэтэсса, переводчик, издатель, член Союза писателей XXI века, Союза писателей Республики Татарстан, литературного фонда России, Союза российских писателей Вера Хамидуллина (г. Набережные Челны), перевела два стихотворения поэта, опубликованные в книге «Водоворот» («Чоңгыл», 2006)[46]:

***

*Мине сыйпысы җилләр*
*Мине төтенгә төрә.*
*Мине саклыйсы этләр*
*Миңа котырып өрә.*

*Иртә-кичен офыкта*
*Шул ук бер балык башы.*
*Явраклап йолкый-йолкый,*
*Минем гомерне ашый.*

*Өзгәләнмим, зарланмыйм,*
*Тик авыр сулап куям.*
*Чөнки мин бу дөньяга*
*Рөхсәт сорамый туган.*

***

*Меня ветра должны ласкать,*
*Меня кружить должны туманы.*
*Должны собаки охранять,*
*Но лают, лают, как ни странно.*

*Вечерней, утренней зарей*
*Качает рыба плавниками,*
*Разор творит в житье моем,*
*И водоросли вырывает.*

*Мне возмущаться не резон.*
*Ложусь на дно с тяжелым вздохом.*
*Без спросу на земле рожден*
*Немой и мелкою рыбёхой.*

---

[46] URL: http://www.litkonkurs.com/?dr=45&tid=241362&pid=0 (дата обращения: 14.06.2019)

***

*Ерак китмәдем, мин монда гына –*
*Яшәү белән үлем арасында.*
*Сукыр язмышымны тартып бара*
*Болытларның агы, карасы да.*

*Ап-ак болыт, йөзен чынмы ап-ак?*
*Кара болыт, син дә чынмы кара?*
*Арлы-бирле йөреп, эзлисезме*
*Күктән чыгып качыр өчен ара?*

*Без үләнгә, чыкка әйләнәбез*
*Сез яудырган яңгыр, кар астында.*
*Сез качсагыз, безне кем юандырыр*
*Яшәү белән үлем арасында.*

***

*Далеко не ушел, я здесь рядом –*
*Между жизнью и смертью в пробеле.*
*Слепо крест свой тащу, раз так надо.*
*Облака надо мной черно-белы.*

*Честно-честно лик облака белый,*
*Честно черное облако чёрно?*
*Да и ходят туда-сюда смело,*
*Нет меж ними на небе зазора.*

*Мы в траву и росу превратимся,*
*Мы пройдемся дождем и снегами.*
*За участьем к кому обратиться*
*Между жизнью и смертью над нами?*

**Перевод М. Шостиной**[47]

[47] Из века в век. Поэзия народов кириллической азбуки. – Москва-Казань: ООО МАГИ Из века в век, 2010. – С. 434–435.

***

*Ерак китмәдем, мин монда гына –*
*Яшәү белән үлем арасында.*
*Сукыр язмышымны тартып бара*
*Болытларның агы, карасы да.*

*Ап-ак болыт, йөзең чынмы ап-ак?*
*Кара болыт, син дә чынмы кара?*
*Арлы-бирле йөреп, эзлисезме*
*Күктән чыгып качар өчен ара?*

*Без үләнгә, чыкка әйләнәбез*
*Сез яудырган яңгыр, кар астында.*
*Сез качсагыз, безне кем юандырыр*
*Яшәү белән үлем арасында.*

***

*Облака надо мной почернели.*
*Честно крест свой тащу, раз так надо.*
*Далеко не ушёл, я здесь рядом –*
*Между жизнью и смертью в пробеле.*

*Так ли кипельно облако бело,*
*Так ли чёрное облако черно?*
*Чёрно-белое вьюжится тело*
*И по небу кружится проворно.*

*Мы в траву и росу превратимся,*
*Мы пройдёмся дождём и снегами.*
*За участьем к кому обратимся*
*Между жизнью и смертью над нами?*

# ЦИТАТЫ
# О ТВОРЧЕСТВЕ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ
# (ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША ИҖАТЫ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘР)[48]

Шәүкәт Гаделша иҗаты миңа калса, татар шигъриятендә уникаль бер сәхифә, вакыйга булып саналырга лаек. Булат әкә Сөләйман дөньядан кичкәч (урыны җәннәттә булсын), Шәүкәт татар шигъриятендә иксез-чиксез Себернең бердәнбер вәкаләтле вәкиле булып калды. Ләкин берүк соңгы могиканы булырга гына язмасын иде.

***Газинур Морат,***

Шагыйрь. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 2005

Шунысы куанычлы: татар шигъриятендә өр-яңа, гаять үзенчәлекле, уникаль шагыйрь Шәүкәт Гаделша китаптан китапка үсә, ныгый, тирәннән ачыла, укучысына якыная бара. Аның тынгысыз карашы, тәвәккәл сунарчы кебек, ерак-еракка, яңа иҗат офыкларына төбәлгән.

***Роберт Әхмәтҗан.***

Шагыйрь. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 2004

Шәүкәт Гаделша – җаны, тәне, каны белән чын Себер егете. Безнең шигърияттә табигатьнең (бу урында урман табигатьнең дип әйтү дөрес булыр) нечкәлеген сизгер тоеп, аның сулышын тоеп яза алучылар, һай, сирәктер. Табигать аңа, үзен аңлаучы шагыйрьгә илһамны бөртекләп, учлап кына түгел, илаһи уптым итеп күпләп биргән.

***Госман Садә,***

Шагыйрь. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 2000

Ә шагыйрь турында дуслары-кордашлары Г. Морат һәм Р. Зәйдуллаларның бик матур фикерләр әйтеп язып чыкканы хәтеремдә. Ш. Гаделша иҗаты турында сөйләшү – шагыйрьләр остаханәсе утырышы да бик җанлы узган иде, ансын да онытмыйм. Фикерләр кызыклы, әмма бердәм иде: бүгенге татар шигырендә – Себер исеме белән тансык, матур шигъри дөнья тудырган үзенчәлекле шагыйрь Шәүкәт Гаделша да бар. Яңа китабын укыгач та, шул фикерем ныгыды: әйе, шагыйрь – бар, һәм ул дәвам итә. Игътибар итик, укыйк без аны! Ә «Себер – үзебезнеке» ул! Безнеке.

***Рәдиф Гаташ,***

Шагыйрь. Татарстанның Х.Такташ исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 2003

[48] Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Дүртенче китап = Писатели нашего детства: Библиографический справочник. Книга четвертая. – Казан: Мәгариф, 2008.– 255 б.

Сорау туа: каян килә соң Шәүкәткә бу көй-аһәң? Тамак төбе белән көйләнә торган җыру-шигырь? Әлбәттә, анасының имезгән сөтеннән, эчкән суыннан, үскән урманыннан, авыл картларының, бер өйгә җыелып, төн буе җыру көйләп утыруларыннан… Төрки бабаларыбызның мәҗүси ышануларыннан, борынгы шаман йолаларыннан, «күк теле»ннән, «урман теле»ннән, «киек теле»ннән килә… Шәүкәт шигырендә гел шул: әле урман шавы, әле су чылтыравы, әле тау иңрәве, әле яралы үрдәк яисә ятим болан кычкыруы… Ул, башкалар кебек, дөньяны күреп кенә, аны матур, төгәл, җете сурәтләргә төшереп кенә калмый, ул аны «ишетә»… Ул табигатькә, димәк, чынлыкка, дөнья асылына якынрак тора. Ниһаять, ул көй белән аңлаша һәм аңлата ала: елый, сулкылдый, иңри яисә шат аһәң белән көлә, елмая… Әмма һәр очракта да ниндидер тетрәндергеч дәрәҗәдә моңлы һәм шомлы көй гипнозын сизми мөмкин түгел.

***Галимҗан Гыйльманов.***

Язучы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 1998

Шигъри дөньясы аның үзенчә – себерчә.

***Мөдәррис Әгъләм.***

Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. 1997

## СТИХИ, ПОСВЯЩЕННЫЕ ШАУКАТУ ГАДЕЛЬШЕ

### ШӘҮКӘТКӘ[49]

*Элек Себергә сөргәннәр,*
*Ул – Себердән серелгән.*
*Казанны яулый алмаган,*
*Ул Казанга бирелгән.*

*Шигърият дөньясында*
*Ул олы бер хан хәзер.*
*Аның янында без, Рафис,*
*Малай-шалай, маңка бер!*

*Ул бик җитди, аны инде*
*Кызыктырмый юк-бары…*
*Элек «Ильич уты» булса,*
*Хәзер Шәүкәт утлары…*

*Кайчак ауга чыккан була,*
*Киек-мазар ата ул…*
*Тидералмый… Һичьюгында*
*Шигырь алып кайта ул…*

*Үзе Казанда торса да,*
*Җанында Себер йөри.*
*Ул суза торган чыбыкта*
*Ток түгел, шигырь йөри…*

*Ул – тормышның һер гаменә*
*Түзәр һәм чыдар егет!*
*Рафис белән мине кушсаң,*
*Бер Шәукәт чыгар кебек…*

*Галимҗан Гыйльманов,*
*2003*

---

[49] Галимҗан Гыйльманов. Шәүкәткә // Күңелем сурәте. – Казан: «Рухият», 2003. – Б. 149.

## ИЛТӘ АЛГА[50]

*Шәүкәтнең ихлас ярдәмен*
*Күп милләттәшләр тоя,*
*Мәрхәмәтлеге белән ул*
*Үзенә һәйкәл куя!*

*Чит кайгыларны үз итү*
*Аның канына сеңгән,*
*Аңына вә халәтенә*
*Ходай кодрәте иңгән!*

*«Аучы җыры» китабында*
*Чагыла Себер үзе,*
*Шагыйрьнең рухи нурыннан*
*Яктыра тормыш йөзе!*

*Татарны татар итәргә*
*Әйдәүче ул һәм яучы –*
*Яманлыкны бетерүдә*
*Хөрмәтле, сизгер аучы!*

*Илһамланып гомер сөрү –*
*Аның гадәте, эше;*
*Миллилектә, изгелектә*
*Яшәү мәгънәсе, көче!*

*Салават күпере, гүя,*
*Ике арада Шәүкәт;*
*Андый заттан куәт ала*
*Җир-милләт, хәтта дәүләт!*

*Себер моңы, Идел җыры –*
*Ике канаты аның;*
*Гаделлек, бердәмлек өчен*
*Дөрлесен, шагыйрь, җаның!*

*Изге гамәл чорлар аша*
*Илтә алга зат аңын!*

*Заһит Акбүләков, 2004*

---

[50] Заһит Акбүләков. Илтә Алга // Яңарыш.– 2004.– № 18 (1169), 30 апреля. – Б. 7.

## **КӨЙ ЧАКЫРУ**[51]

*ШӘҮКӘТКӘ*

*Күчем ханның күченнән ул,*
*Төмән дигән тияктән.*
*Бу Казанга тик адашып*
*Килеп чыккан киектәй,*

*Гел сагаеп яшидер күк,*
*Гел сагынып яшидер.*
*Шуңа һәр кош ахир аңа,*
*Һәрбер җәнлек яшьтидер.*

*Һәр киекнең көен белә,*
*Көе китсә – көенә.*
*Ул юксынып яшидер күк*
*Себернең черкиен дә.*

*Җанында ау комарлыгы*
*Алса әгәр уянып,*
*Чөй язуын укыгандай*
*Укый эзен куянның.*

*Кошлар эзен укый күктән,*
*Укый үлән ымын да.*
*Бер мәҗүси шаман сыман,*
*Көй чакыра ырымлап.*

*Көй чакыра... Әле кем дә*
*Көйләмәгән үзгә көй...*
*Күзе буйлап ялгыз болан*
*Чабып узды гүяки...*

*Газинур Морат,*
*2005*

[51] Газинур Морат. Көй чакыру // Төнге әверелеш: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 352.

## СИН БИТ СЕБЕР ТАТАРЫ![52]

*Казанда яшәүче Себер шагыйре*
*Шәүкәт Гаделшага*

*Мин Себердә йөрим, Шәүкәт,*
*Синен туган иләндә.*
*Себеренне бик күрәсем*
*Килгән иде минем дә…*

*Монда Себер киңлекләре*
*Еракларга тарала.*
*Шигырләрен, искә төшә,*
*Кая гына карама!*

*Син – Казанда, мин – Себердә:*
*Йөримен Себер буйлап.*
*Йөрим менә себерелеп,*
*Себердә сине уйлап.*

*Син бөтен булмышын, беләң*
*Себернеке, билгеле.*
*Син – Себернең, бер баласы,*
*Син – Себернең, бер гөле.*

*Гөл күчереп утыртканны*
*Яратмый шул – сула шул.*
*Сулмаса да саргая шул,*
*Саргая да сына шул…*

*Моның, шулай икәнлеген*
*Беләм, Шәүкәт, үземнән.*
*Нишлисең, яшәлгән инде,*
*Күнегелгән, түзелгән…*

*Себергә караганда да*
*Безнең Казан кырысрак.*
*Тиз сындыра ул, булмасаң*
*Башкалардан корычрак…*

---

[52] Миңнуллин Р.М. Син бит Себер татары! // Татарларым: милли шигырьләр / Роберт Миңнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б. 114–115.

*Ә син Казанда ятасың,*
*Себереңне сагынып…*
*Бер дә кайтасың килмиме*
*Кошлар кебек кагынып?!*

*Чыннан да, сагынасыңмы?*
*Себер һаман тартамы?*
*Ятма әле, понимаешь,*
*Син бит Себер татары!*

*Юкса Казанныкы булып*
*Беткәнсең бит син бигрэк.*
*Синсез монда Себер ятим,*
*Кайт иленә, сибиряк!*

*Роберт Миңнуллин, 04.10.2009*

## СТИХИ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШЫ, ПОСВЯЩЕННЫЕ ДРУЗЬЯМ И ЗЕМЛЯКАМ

### ЯШЬТӘШЕМ ФАТИХКА[53]

*Озаккамы туган якта*
*Гәп-сүзсез йөрүләрем?*
*Заман сөяк итте, ахры,*
*Телләрем шул ирләрнең,*
*Нурлы күзләр, сөремсез йөз*
*Күрергә мин сусадым.*
*Рәхәтләнеп, күзгә карап,*
*Килә сорыйсыларым.*
*Балык ничек? Иртә-кичен*
*Ауларга тыгыламы?*
*Капкыннарга төлке-мазар*
*Бик теләп сугыламы?*
*Каплап куйган каегыгыз*
*Сезне көтеп сыктыймы?*
*Урман, кыздай күз уйнатып,*
*Серләшергә кыстыймы?*
*Ничек анда таң атканда*
*Сулый наратлар шавы?*
*Юкәдәнме, ефәктәнме*
*Атларыгыз тышавы?*
*Туган авыл урамнарын*
*Ялгыз башым мин үтәм.*
*Капка төптә тәмәкеле*
*Берәр ирне күр икән.*
*Нишли ирләр? Ниләр уйлый,*
*Качып капка артына?*
*Җырларыма көч, моң кирәк*
*Капкаларны ачарга?*

[53] Шәүкәт Гаделша. Яңарыш.– 1998.– № 104 (628), 29 декабрь. – Б. 2.

## «ЯҢАРЫШ» ГӘЗИТЕ [54, 55],

*«Яңарыш»ка –*
*Яратып, ярым шаяртып*

*Син дә, мин дә – «ярты ясак»,*
*Татар гәзите «Яңарыш»,*
*Чынлап күкрәргә, яшьнәргә,*
*Дускаем, синең бара эш.*

*Көнләшеп, күрәм күп өйдә,:*
*Балкыйсың өстәл-түрләрдә.*
*Миңа да чиш әле сереңне –*
*Ничек йөрәккә үтәргә.*

*Йөзен күренсә күзенә,*
*Кәфернең чырае сытыла.*
*Чал урман, кояш, кызыгып,*
*Сине укырга сузыла.*

*Синең дә, минем шикелле,*
*Бик узгә килеш-килбәтең.*
*Әмма син туган мәңгелек*
*Итәргә татар милләтен.*

*Сине мин әкияттәге*
*Сәмрух кош итеп күрәмен.*
*Иңеңә утырып урыйм бер*
*Борынгы татар җирләрен.*

*2002*

---

[54] Шәүкәт Гаделша. «Яңарыш» гәзите // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 116.

[55] Шәүкәт Гаделша. «Яңарыш»ка – яратып, ярым шаяртып // Яңарыш.– 2002.– № 99–100 (1038–1039), 13 декабрь. – Б. 1.

## ЯЗ, СЕҢЛЕМ! ЯЗ![56, 57],

*«Яңарыш» хезмәткәре*
*Диләфрүз Фәхригә*

*Ничек анда – Төмәнемдә*
*Яңгырлары, бураны?*
*Тирә-юньгә мәчетләре*
*Нур чәчрәтеп торамы?*

*Татар габе, чишмәләнеп,*
*Урамнарда гөрлиме?*
*Милләтебез зыялары*
*Мәэюсләнеп йөрмиме?*

*Сайрамыймы татлы йомак,*
*Якташларны йоклатып?*
*Сүрелмиме үзгерәшкә,*
*«Янарышка» мохтаҗлык.*

*Яз әле, яз миңа, сеңлем.*
*Менә шулар турында.*
*Ныгый барган каләмеңне*
*Манып иман нурына.*

*Җирле татар хәл-хисләрен*
*Йөрәк белән анлыйсың,*
*Үзгәрешләр чоңгылының*
*Уртасында кайныйсың.*

*Көнләшәм дә синнән – кайчак*
*Кызганып та куямын:*
*Хатын-кызга бик авыр ла*
*Мәшәкате дөньяның.*

*Сабыеңа төнлә карап*
*Елауларың азмы соң?*
*Милләт белән бергә чыныгу –*
*Сеңлем, синең язмышың!*

---

[56] Шәүкәт Гаделша. Яз, сеңлем! Яз! // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 114–115.

[57] Шәүкәт Гаделша. Яз, сеңлем! Яз! // Яңарыш.– 2003.– 31 январь. – Б. 3.

*Кояшы да, ае да бар*
*Киң Себернең күгендә.*
*Инде менә иман балкый –*
*Күк өметләрәк күренә!*

*Өмет, өмет… Көннен-көн ул*
*Ымсындыра көчлерәк.*
*«Яңарыш» та, син үзен дә*
*Туган якка бик кирәк.*

*Яз мина, яз әле, сеңлем!*
*Йөрәгемне айкаттыр!*
*Синнен килгән хатлар гына*
*Мине, йолкып, кайтарыр.*

*…Бәлки кирәгем дә юктыр*
*Газиз туган ягыма,*
*Синдәй, сеңлем, фидакарьләр*
*Анда булган чагында?*

*2003*

## И ФАТИХ[58, 59],

*Син дә, Фатих, сизәсендер:*
*Ничек тиз үтә вакыт?!*
*Әле кайчан гына сазда*
*Без чөрәгәйләр аттык.*

*Чөрәгәйләр «пыр-пыр» оча,*
*Ядрә тими дә тими.*
*Маһинурың эчтән генә*
*Бездән көлгәндер инде.*

*Сиңа миндә ачу кайный*
*Ауга кыз алганыңа,*
*Яратышып булмыймыни*
*Безнең авылда гына.*

58 Шәүкәт Гаделша. И Фатих // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 119–120.

59 Шәүкәт Гаделша. И Фатих // Яңарыш.– 2005.– № 31 (1234), 29 июль. – Б. 7.

*Үзең киттен аргы күлгә*
*Кызыңны калдырдың да.*
*Баш очында очмый үрдәк –*
*Бакылдый анда-монда.*

*– Сөбханалла, нинди кич! – дип,*
*Кыз сүз башларга тели.*
*Нинди акылсызлык! – миңа*
*Комачаулавын белми.*

*Кинәт кызга ташланам да*
*Куе үләнгә егам.*
*– Үрдәкләрне куркытасын,*
*Селкенмә! – дип, кычкырам.*

*Шунда куак арасыннан*
*Елмаеп килеп чыктың.*
*Әремгә яуган яңгырдай*
*Йөрәге тибә кызның.*

*Сине күргәч, и куандым! –*
*Комачаудан коткардың.*
*Үрдәк атмый калам бит дип,*
*Качкандай китеп бардым.*

*Вакыт үтә-үтә лә бит*
*Чөрәгәй тизлегендә.*
*Саф, самими чакларыбыз*
*Хәтернең иң түрендә!*

*Их, кайтырга иде берчак*
*Яшьлекнең шул көненә!*
*– Кызың коч та шунда кал, – дип,*
*Сиңа әйтәсем килә.*

*2003*

## ГАЗИНУР МОРАТКА[60]

*Шигырьдәге мәргәнлегең*
*Йөрәгемне көйдерә.*
*Сунардагы сабыйлыгың*
*Безне дуслар иттерә.*

*Ядрә тигән чөрәгәйләр*
*Егылып төшкән арада,*
*Нинди уйлар өлгерәләр*
*Миләреңне чагарга?*

*Күзләреңне яшерергә*
*Җитми синдә осталык.*
*Тама мылтык түтәсенә*
*Күз яшьләрең «тып» та «тып».*

*Тыпырчынган үрдәкләрнең*
*Сугар чакта башына,*
*Каушап калып, кылтырыйсың,*
*Кояш, күк, су каршында.*

*Каннан куркып күз чылаткан*
*Чыкмый иде сунарга –*
*Син чыгасың канлы йоннан*
*Утлы шигырь сыгарга.*

*Кызганамын сине ауда –*
*Сабый инде, сабый – син!*
*Шигъриятнең бер алыбы*
*Ничек була алдың син!*

*2003*

[60] Шәүкәт Гаделша. Газинур Моратка // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 53–54.

# СИН ГЕНӘ[61, 62],

Себер кызы, тел белеме
професcоры Х.Алишинага

*Көнбатыштан җил исә…*
*Көнчыгыштан җил исә…*
*Аптырашта калдыңмы,*
*Себер кызы Хәнисә!*

*Шушы җиллер чуалып*
*Ямьсез көйләр тудыра;*
*Сиңа… сөйгән халкыңны*
*Ятим итеп тойдыра.*

*Сине күреп, кылтырый*
*Ят күлмәкле хакыйкать:*
*Әйе, аны, Хәнисә,*
*Тукмакларга бик кирәк.*

*Сиңа ходай иңдергән*
*Бар кодрәтен Себернең,*
*Уятырга йокыдан*
*Халкын туган җиреңнең.*

*Бастылар, кыерсыттылар…*
*Калырбыз күк моңсыз да.*
*Коткаралса, коткарыр*
*Син тудырган могҗиза.*

*…Дәверләрдән җаныңа*
*Яшь сыркыла – һай ачы!*
*И Себер татарының*
*Иң олы Аппакасы!*

*2004*

[61] Шәүкәт Гаделша. Себер кызы, тел белеме профессоры Х.Алишинага // Яңарыш.– 2004.– № 6 (1153), 6 февраль. – Б. 1.

[62] Шәүкәт Гаделша. Син генә // Чоңгыл: Шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.– 160 б. – Б. 88.

## И МӨДӘРРИС ӘКӘ![63]

*Әйтеп куя кайчак әкә:*
*Шигърияткә тоз җитми.*
*Чытырманлы шигырьләрең –*
*Без көткән шул тоз бит, – ди.*

*Классик түгел мин, дусларым.*
*Классик – Мөдәррис Әгьләм.*
*Аңа бүләк итәм әле*
*Бүдәнәләр – бер бәйләм.*

*Чәчәк, үләннәргә төреп*
*Ачыткан таң чагым да бар.*
*Асрап кыргый урманнарда,*
*Симерткән сугым да бар.*

*Тели икән – төлкеләрдән*
*Шундук тун да әмәллим.*
*Күрсә, алтын балыкны да*
*Алсын әйдә, жәлләмим.*

*Килсен генә, керсен генә*
*Мин «чалдон»ны күрергә.*
*Шигырьләрем сыйпалырга*
*Каршысына йөгерә.*

*Өстәлемә утырганда*
*Безгә бар да нипочем!!!*
*Аңа балны төртә-төртә,*
*Калта-калта тоз ашыйм.*

*2006*

[63] Шәүкәт Гаделша. И Мөдәррис әкә! // Чоңгыл: Шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2006. – Б. 62.

## БИБЛИОГРАФИЯ

(в хронологическом порядке)

## ИЗДАННЫЕ КНИГИ

1. Ярык мөгез: шигырьләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 1997.– 69 б.
2. Ядрә тигән: шигырьләр. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1998.– 80 б.
3. Сөмән кадыйм: шигырьләр. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2000.– 144 б.
4. Җилгә моң дыңгычлыйм: шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003.– 127 б.
5. Аучы җыры: шигырьләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 2004.– 383 б.
6. Чоңгыл: шигырьләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 2006.– 160 б.
7. Иман капка ачканда: шигырьләр. – Казан: «Илһам» нәшрияты, 2011.– 112 б.
8. Табигать баласы: шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: ТанДим, 2014.– 488 б.
9. Себерем – үз җирем: шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: «Ак Бүре» нәшр., 2019.– 175 б.

## СТАТЬИ О ТВОРЧЕСТВЕ ПОЭТА ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ, ОПУБЛИКОВАННЫЕ В ПЕРИОДИЧЕСКОЙ ПЕЧАТИ


1. Сөләйманов Б. Хәерле юл сиңа, якташ! // Татарстан яшьләре.– 1969.– № 136 (5134), 13 ноябрь. – Б. 4.
2. Әгъләм М. Себер моңы // Шәһри Казан.– 1997.– 17 гыйнвар. – Б. 5.
3. Фәхретдинова Д. Кадерле авылдашым минем // Яңарыш.– 1998.– № 40 (564), 15 май. – Б. 2.
4. Әгъләм М. Шигырь атлы ядрә тисә // Мәгърифәт.– 1998.– 17 ноябрь. – Б. 5.
5. Сәдә Г. Себер кадәр Себер сыя шигырьгә // Илһамият.– 2000.– № 25 (271), 30 июнь. – Б. 5.
6. Хабибуллина Л.Б. Шәүкәт Гаделша иҗаты // Яңарыш.– 2002.– 1 февраль. – Б. 3.
7. Акмал Н. Безгә балык эләкми… // Мәдәни Җомга.– 2003.– 14 март. – Б. 13.
8. Зәйдулла Р. Куркытмагыз кошлар авазын: 2002 ел шигъриятенә бер караш // Казан утлары.– 2003.– № 7. – Б. 152.

9. Фәхретдинова Д. Җилгә моң дыңгычлыйм // Яңарыш.– 2003.– № 75–76 (1118–1119), 19 сентябрь. – Б. 7.
10. Гаташ Р. Шигырьдәге Себер дә – үзебезнеке // Яңарыш.– 2003.– № 85–86 (1128–1129), 24 октябрь. – Б. 7.
11. Сәгыйтов А. Р.Корбан: «Иҗат чишмәгез саекмасын!» // Яңарыш.– 2004.– № 6 (1153), 6 февраль. – Б. 1, 2.
12. Сәгыйтов А. Ш.Гаделша: «…Казан, Төмән арасы – Мәгънәм минем, канатым..» // Яңарыш.– 2004.– № 7 (1158), 13 февраль. – Б. 7.
13. Заһидуллина Д. Шигырендә – Себер киңлекләре // Мәдәни җомга.– 2004.– 13 февраль. – Б. 16.
14. Сәгыйтов А. Әдипләребезне беләсезме? // Яңарыш.– 2004.– 2 апрель. – Б. 4.
15. Фәхретдинова Д. Ш.Гаделша: «…Казан, Төмән арасы – Мәгънәм минем, канатым..» // Яңарыш.– 2004.– № 18 (1169), 30 апрель. – Б. 7.
16. Фәхретдинова Д. Язмышымның дәрьясы – Казан, Төмән арасы… // Яңарыш.– 2005.– № 31 (1234), 29 июль. – Б. 7.
17. Сафиуллина Н. И туган тел // Яңарыш.– 2006.– 7 июль. – Б. 3.
18. Кангазина Р. «Хатыныма рәхмәтем чиксез» // Яңарыш.– 2008.– № 7 (1366), 15 февраль. – Б. 2.
19. Вәлиева Г. Галимәнең яңа китабы // Яңарыш.– 2008.– № 17 (1376), 25 апрель. – Б. 3.
20. Фәхретдинова Д. Шәүкәт Гаделша: «Бу бит минем туган ягым; яши шунда татар халкым» // Яңарыш.– 2008. — № 18 (1377), 2 май. – Б. 4.
21. Низами Р. Аучы. Шагыйрь. Гуманист // Казан утлары.– 2008.– № 7. – Б. 139–142.
22. Низами Р. Аучы. Шагыйрь. Гуманист // Яңарыш.– 2008.– № 32 (1391), 8 август. – Б. 7.
23. Батулла Р. Егетләр бар // Мәдәни җомга.– 2008.– 8 август. – Б. 15.
24. Хәбибуллина Л. Шигърият белән тәрбияләү // Яңарыш.– 2009.– № 37 (1448), 11 сентябрь. – Б. 7.
25. Сафиуллина Н. Моңлы бала – өлкән абый // Яңарыш.– 2009.– № 38 (1449), 18 сентябрь. – Б. 1, 3.
26. Сәгыйтова А. Очрашулар дәвам итә // Яңарыш.– 2010.– № 12 (1475), 26 март. – Б. 1.
27. Фәхретдинова Д. Шагыйрь белән туган җирендә очрашу // Яңарыш.– 2010.– № 27 (1490), 9 июль. – Б. 1.
28. Фәхретдинова Д. Иҗади кыйбласына тугры калып… // Яңарыш.– № 2 (1569), 2012.– 13 январь. – Б. 7.
29. Фәхретдинова Д. Татар шигъриятендә гаять үзенчәлекле шагыйрь // Яңарыш.– 2014.– № 37 (1708), 12 сентябрь. – Б. 7.

30. Фәхретдинова Д. «Кайнап чыккан моңнарымны кайсы җилгә тагыйм соң?» // Яңарыш.– 2018.– № 6 (1884), 9 февраль. – Б.3.

## УПОМИНАНИЯ

1. Вәлиева Г. Казанышларга бай ел // Яңарыш.– 2007.– № 52 (1359), 28 декабрь. – Б. 1, 7.
2. Кангазина Р. Ул Себердә туган // Яңарыш.– 2008.– № 22 (1381), 30 май. – Б. 3.
3. Фәхретдинова Д. «Хәтер чакыруы» проектынның йомгыклау тантанасы // Яңарыш.– 2014.– № 12 (1683), 21 март. – Б.2.
4. Ветрова М. Чисты их имена, и горек голос, и дух высок на вечны времена // Светлый путь.– 2014.– 5 ноября. – Б. 2.
5. Фәхретдинова Д. Туган якның бер почмагы // Туган як әдәбияты (Литература родного края): учебное пособие для учаәихся 5–11 классов / на тат. яз /Л.Б. Хабибуллина / под ред. Х.Ч. Алишиной. 2-е изд., доп. и перераб. – Тюмень: Типография «Печатник», 2015.– 448 с. – С. 160–161.
6. Кангазина Р. Шәүкәт Гаделша шигырьләрен яратучы егет // Яңарыш.– 2017.– № 8 (1834), 24 февраль. – Б. 7.

## СТАТЬИ О ТВОРЧЕСТВЕ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ, ОПУБЛИКОВАННЫЕ В КНИГАХ

1. Гыйльманов Г. Шагыйрьнең урманы // Ярык мөгез / Ш. Гаделша. – Казан: Татар кит. нәшр., 1997. – Б. 3–10.
2. Гыйльманов Г. Көйгә кайту // Ядрә тигән / Ш. Гаделша. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1998. – Б. 73–76.
3. Морат Г. Чалдун // Җәяүле кошлар / Г. Морат. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2002. – Б. 202–209.
4. Әхмәтҗанов Р. Җирсү // Аучы җыры / Ш. Гаделша. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 5–10.

## НАУЧНЫЕ ТРУДЫ О ТВОРЧЕСТВЕ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ И ПУБЛИКАЦИИ В НАУЧНЫХ ИЗДАНИЯХ

1. Фаизова Л.Х. Шагыйрь Ш. Гаделшаның ижат үзенчәлеге // Сулеймановские чтения-2005: Материалы YIII межрегиональной научно-практической конференции / Под ред.Сайфулиной Ф. С., Яркова А. П. – Тюмень: ИПЦ «Экспресс», 2005.– 201 с.

2. Фаизова Л.Х. Шагыйрь Ш. Гаделшаиҗатында лирик әндәшләр // Сулеймановские чтения-2006: материалы IX Всероссийской научно-практической конференции /под ред. Яркова А. П. – Тюмень: ИПЦ «Экспресс», 2006.– 160 с.
3. Муллачанова Г.Х. Художественный мир татарской поэзии Сибирского региона (1990–2005 г.г.): автореф. дис. …канд. филол. наук:10.01.02 / Муллачанова Гузалия Халиловна. – Казань, 2006.– 27 с.
4. Сайфулина Ф.С. Сибирский топос в татарской поэзии второй половины XX столетия (по творчеству Б.Сулейманова и Ш. Гадельши) // Омский научный вестник.– 2006.– № 10 (49). – С. 141–144.
5. Фаизова Л.Х. Особенности творчества сибирского татарского поэта Шауката Гадельши: дисс.канд. филол. наук:10.01.02 / Фаизова Лилия Харисовна. – Тобольск, 2006.– 140 с.
6. Фаизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш. Гаделша иҗатында чагыштыруларның төп вазыйфасы // Сулеймановские чтения: материалы X Всероссийской научно-практической конференции(Тюмень, 18–19 мая 2007 г.) /под ред. Яркова А. П. – Тюмень: СИТИ-ПРЕСС, 2007.– 130 с.
7. Фаизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш.Гаделша иҗатында стилистик фигуралар кулланылышы // Занкиеввские чтения: материалы Всероссийской научно-практической конференции. – Тобольск: ТГПИ им. Д.И. Менделеева, 2007. – С. 63–65.
8. Фаизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш.Гаделша иҗатында халыкчан поэтика // Тумашевские чтения: Актуальные проблемы тюркологии: материалы Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 80-летию академика Д.Г. Тумашевой (г. Тюмень, 19 октября 2006 г.). – Тюмень: Изд-во Тюменского государственного университета, 2007. – С. 237–245.
9. Сайфулина Ф.С. Трансформация национального образа мира в творчестве современных поэтов Сибири // Ученые записки Казанского университета. Сер. Гуманитарные науки.– 2007. – Том 149, Кн. 4. – С. 135–142.
10. Сайфулина Ф.С. Татарская литература Тюменского региона: история и современность: автореф. дис. … докт.филол.наук:10.01.02 / Сайфулина Флера Сагитовна. – Казань, 2008.– 50 с.
11. Фәизова Л.Х. Язмышының дәрьясы – Казан-Төмән арасы… (Себер-татар шагыйре Шәүкәт Гаделша иҗаты). – Казан: Идел-пресс, 2008.– 128 б.

12. Фәизова Л.Х. Себер-татар шагыйре Ш. Гаделша иҗатында заман проблемалары бирелеше // Сулеймановские чтения: материалы Всероссийской научно-практической конференции. – Тобольск: ТГПИ им. Д. И. Менделеева, 2008.– 305 с.
13. Фаизова Л.Х. Шагыйрь Ш. Гаделшаиҗатындакабатлаулар // Сулеймановские чтения: материалы Всероссийской научно-практической конференциис международным участием. – Тобольск: ТГПИ им. Д. И. Менделеева, 2009.– 217 с.
14. Хәсәнова Ф. Татар шигърияте: үткәне һәм бүгенгесе // Казан утлары.– 2009.– № 10. – Б. 153.
15. Хабибуллина Л.Б. Шәүкәт Гаделша иҗаты // Сулеймановские чтения: материалы и доклады Всероссийской научно-практическойконференции. – Тюмень: Изд-во Тюменского государственного университета, 2012.– 240 с.
16. Харрасова Р.Ф. Ш. Гаделша иҗатында субъект структурасының үзенчәлегә // Сулеймановские чтения: материалы XVI-й Всероссийской научно-практической конференции. – Тюмень: Издательство Тюменского государственного университета, 2013. – с.
17. Хәйруллин И.Р. Шәүкәт Гаделша – халыкчан шагыйрь// Сулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч.-практ. конф.«Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы. – Тюмень: Печатник, 2014. – С. 85–87.
18. Харрасова Р.Ф. Ш. Гаделша поэзиясендә тәүге һәм соңгы строфалар эмоциональлеге // Сулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч. – практ. конф.«Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы. Тюмень: Печатник, 2014. – С. 93–97.
19. Сибгатуллина М.Ш. ШаукатГадельша: о некоторых страницах жизни поэтаСулеймановские чтения (семнадцатые): Всерос. науч. – практ. конф.«Культурное и этническое многообразие тюркского мира» (Тюмень, 30–31 мая 2014): Труды и материалы. – Тюмень: Печатник, 2014. – С. 72–73.
20. Фаизова Л.Х. Поэтический мир сибирско-татарского поэта Шауката Гадельши: тематическое разнообразие, языковое богатство и народность // Вестник ЧГПУ.– 2014.– № 6. – С. 269–278.
21. Юсупова Г.Р. Шәүкәт Гаделшәнең «Урманнаргакабам» шигыренә анализ // Сулеймановские чтения (девятнадцатые): Всерос. науч.-практ. конф. с межд. участием «Сохранение татарского языка, фольклора, традиций и обычаев в современных

условиях» (г. Тюмень, 20 мая 2016 г.): Труды и материалы /под общ. ред. д-ра филол. наук, проф. Х.Ч. Алишиной. – Тюмень: Печатник, 2016. – С. 157–159.
22. Загидуллина Д.Ф. Принципы организации субъектной сферы в лирике ШаукатаГадельши // Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски / Д.Ф. Загидуллина. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. – С. 146–155.

## УПОМИНАНИЯ

1. Фәхретдинова Д. «Мин себер татарымын» дигән яңа шигырьләр җыентыгына Төмән шагыйрьләренең иҗаты // Тумашевские чтения: Актуальные проблемы тюркологии: материалы Всероссийской научно-практической конференции, посвященной 80-летию академика Д.Г. Тумашевой (г. Тюмень, 19 октября 2006 г.). – Тюмень: Изд-во Тюменского государственного университета, 2007. – С. 245–247.
2. Бабшанова Г.Н. Художественная концепция личности в прозе сибирско-татарских писателей XX века: Занкиев Я.К., Сулейманов Б.В.: автореф. дисс. … канд. дилол. Наук: 10.01.02 / Бабшанова Гульнур Нургалиевна. – Тобольск, 2009.– 24 с. – С. 5.
3. Кузнецова Ю.А. Литературное наследие сибирских татар // День науки: зб. наук. праць II Міжнар. наук.-практ. конф., 17–18 листоп. 2011 р. / за заг. ред. Ю. О. Шепеля. – Дніпропетровськ: Біла К.О., 2011.– 120 с. – С. 53.
4. Габделхакова Г.М. Себер җирле әдәбиятының вәкиле буларак Якуб Зәнкиев иҗатының татар әдәбиятында тоткан урыны // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: сборник статей ито-говой научно-практической конференции научных со-трудников Института Татарской энциклопедии АН РТ (г. Казань, 25–26 июня 2014 г.) / Ин-т Татар. энциклопе-дии АН РТ. – Казань: «Фолиант», 2014. – Вып. 6.– 524 с. – С. 415.
5. Галиуллин Т.Н. Халыкнын иҗат мәҗмугасы// Сулеймановские чтения (девятнадцатые): Всерос. науч.-практ. конф. с межд. участием «Сохранение татарского языка, фольклора, традиций и обычаев в современных условиях» (г. Тюмень, 20 мая 2016 г.): Труды и материалы /под общ. ред. д-ра филол. наук, проф. Х.Ч. Алишиной. – Тюмень: Печатник, 2016. – С. 106.

6. Кирамова Х.Х. Этнокультуралы мәктәп шартларында себер-татар әдипләренең иҗатын өйрәнү// Сулеймановские чтения (девятнадцатые): Всерос. науч.-практ. конф. с межд. участием «Сохранение татарского языка, фольклора, традиций и обычаев в современных условиях» (г. Тюмень, 20 мая 2016 г.): Труды и материалы /под общ. ред. д-ра филол. наук, проф. Х.Ч. Алишиной. – Тюмень: Печатник, 2016. – С. 269.
7. Насибуллина Н.Ш. Типология и систематизация художественных образов в поэзии Роберта Миннуллина / Н.Ш. Насибуллина. – Казань: ИЯЛИ, 2016.– 184 с.– (серия «биб лио тека журнала «Фәнни Татарстан»; 6-я книга) – С. 53.

## СТИХИ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ, ОПУБЛИКОВАННЫЕ В ПЕРИОДИЧЕСКИХ ИЗДАНИЯХ И СБОРНИКАХ

1. Татарстан яшьләре.– 1969.– № 136 (5134), 13 ноябрь. – Б. 4.
2. Идел 17. Яшьләрнең әдәби альманахы. – Казан: Татарстан кит. нәшр., 1985. – Б. 52.
3. Идел.– 1993.– № 4. – Б. 64–65.
4. Шәһри Казан.– 1997.– 17 гыйнвар. – Б.5.
5. Мәдәни җомга.– 1997.– 14 февраль. – Б. 7.
6. Мәдәни җомга.– 1998.– 30 октябрь. – Б. 7.
7. Яңарыш.– 1998.– № 40 (564), 15 май. – Б. 2.
8. Яңарыш.– 1998.– № 104 (628), 29 декабрь. – Б. 2.
9. Шәһри Казан.– 2000.– № 25 (271), 30 июнь. – Б. 5.
10. Мәдәни җомга.– 2000.– 4 август. – Б. 7.
11. Мәдәни җомга.– 2002.– 5 июль. – Б. 7.
12. Яңарыш.– 2002.– 1 февраль. – Б. 3.
13. Яңарыш.– 2002.– № 99–100 (1038–1039), 13 декабрь. – Б. 1.
14. Казан утлары.– 2002.– № 6 (956). – Б. 72–75.
15. Казан утлары.– 2003.– № 6. – Б. 44–46.
16. Яңарыш.– 2003.– 9 май. – Б. 6.
17. Яңарыш.– 2003.– 18 июль. – Б. 5.
18. Яңарыш.– 2003.– 31 январь. – Б. 3.
19. Яңарыш.– 2003.– № 75–76 (1118–1119), 19 сентябрь. – Б. 7.
20. Яңарыш.– 2003.– № 85–86 (1128–1129), 24 октябрь. – Б. 7.
21. Яңарыш.– 2004.– № 6 (1153), 6 февраль. – Б. 1, 2.
22. Яңарыш.– 2004.– № 7 (1158), 13 февраль. – Б. 7.
23. Казан утлары.– 2004.– № 5 (979). – Б. 5–7.

24. Казан утлары.– 2005.– № 6 (992). – Б. 82–85.
25. Яңарыш.– 2005.– № 31 (1234), 29 июль. – Б. 7.
26. Илһамият.– 2006.– № 23 (569), 14 июль. – Б. 11.
27. Сүнмәс утлар балкышы. Мең санлы хәзинәдән (Сияние огней неугасимых. Избранные произведения из 1000 номеров «Казан утлары» на татарском языке). – Казань: «Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы, 2006. – Б. 649.
28. Мин – Себер татарымын!: Шигырьләр / Төз. һәм кереш сүз авт Р.Х.Корбан. – Казан: Татар кит. нөшр.. 2006.– 160 б. – Б. 63–92.
29. Казан утлары.– 2007.– № 7. – Б. 98–100.
30. Яңарыш.– 2007.– 25 апрель. – Б. 5.
31. Яңарыш.– 2007.– 5 октябрь. – Б. 4.
32. Яңарыш.– 2008.– № 19 (1378), 9 май. – Б. 8.
33. Яңарыш.– 2008.– № 32 (1391), 8 август. – Б. 7.
34. Яңарыш.– 2008.– № 41 (1400), 10 октябрь. – Б. 7.
35. Яңарыш.– 2009.– № 46 (1457), 13 ноябрь. – Б. 7.
36. Казан утлары.– 2009.– № 9 (1043). – Б. 51–55.
37. Из века в век. Поэзия народов кириллической азбуки. – Москва-Казань: ООО МАГИ Из века в век, 2010. – С. 434–435.
38. Яңарыш.– 2012.– № 2 (1569), 13 январь. – Б. 7.
39. Яңарыш.– 2012.– № 19 (1586), 11 май. – Б. 15.
40. Яңарыш.– 2012.– № 23 (1590), 8 июнь. – Б. 15.
41. Яңарыш.– 2012.– № 45 (1612), 9 ноябрь. – Б. 15
42. Яңарыш.– 2013.– № 2 (1621), 11 январь. – Б. 15.
43. Мәдәни җомга.– 2013.– 12 июль. – Б. 7.
44. Яңарыш.– 2013.– № 33 (1652), 16 август. – Б. 7.
45. Яңарыш.– 2013.– № 37 (1656), 13 сентябрь. – Б. 7.
46. Яңарыш.– 2013.– № 50 (1669), 13 декабрь. – Б. 7.
47. Яңарыш.– 2014.– № 37 (1708), 12 сентябрь. – Б. 7.
48. Мәдәни җомга.– 2014.– 14 ноябрь. – Б. 7.
49. Яңарыш.– 2016.– № 11 (1785), 11 март. – Б. 7.
50. Яңарыш.– 2016.– № 37 (1811), 9 сентябрь. – Б. 7.
51. Яңарыш.– 2018.– № 39 (1917), 15 июнь. – Б. 7.
52. Яңарыш.– 2018.– № 34 (1912), 24 август. – Б. 3.
53. Яңарыш.– 2018.– № 39 (1917), 28 сентябрь. – Б. 3.
54. Яңарыш.– 2018.– № 24 (1902), 26 октябрь. – Б. 7.
55. Яңарыш.– 2019.– № 2 (1932), 11 январь. – Б. 7.
56. Яңарыш.– 2019.– № 11 (1941), 15 марта. – Б. 2.
57. Яңарыш.– 2019.– № 28 (1958), 12 июль. – Б. 7.

## ПУБЛИЦИСТИКА ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ

1. Шәүкәт Гаделша. Сорау-Җавап // Мәдәни җомга.– 2000.– 14 январь. – Б. 17.
2. Шәүкәт Гаделша. Масаерга иртә әле! // Яңарыш.– 2004.– 11 март. – Б. 5.
3. Шәүкәт Гаделша. Уйлары изге // Яңарыш.– 2004.– 16 апрель. – Б. 7.
4. Шәүкәт Гаделша. Үзем турында үзем // Балачак әдипләре. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Дүртенче китап = Писатели нашего детства: Библиографический справочник. Книга четвертая / Р.Н. Даутов. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 45–46.

## СТИХИ, ПОСВЯЩЕННЫЕ ШАУКАТУ ГАДЕЛЬШЕ

1. Гыйльманов Г. Шәүкәткә // Күңелем сурәте. – Казан: «Рухият», 2003. – Б. 149.
2. Морат Г. Көй чакыру // Төнге әверелеш: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2005. – Б. 352.
3. Миңнуллин Р.М. Син бит Себер татары! // Татарларым: милли шигырьләр / Роберт Миңнуллин. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2012. – Б. 114–115.
4. Акбүләков З. Илтә Алга // Яңарыш.– 2004.– № 18 (1169), 30 апреля. – Б. 7.

## СТИХИ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ, ПОСВЯЩЕННЫЕ ДРУЗЬЯМ И ЗЕМЛЯКАМ

1. Шәүкәт Гаделша. Яшьтәшем Фатихка // Яңарыш.– 1998.– № 104 (628), 29 декабрь. – Б. 2.
2. Шәүкәт Гаделша. «Яңарыш»ка – яратып, ярым шаяртып // Яңарыш.– 2002.– № 99–100 (1038–1039), 13 декабрь. – Б. 1.
3. Шәүкәт Гаделша. «Яңарыш» гәзите // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 116.
4. Шәүкәт Гаделша. Яз, сеңлем! Яз! // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 114–115.
5. Шәүкәт Гаделша. Яз, сеңлем! Яз! // Яңарыш.– 2003.– 31 январь. – Б. 3.
6. Шәүкәт Гаделша. И Фатих // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 119–120.
7. Шәүкәт Гаделша. И Фатих // Яңарыш.– 2005.– № 31 (1234), 29 июль. – Б. 7.

8. Шәүкәт Гаделша. Газинур Моратка // Җилгә моң дыңгычлыйм: Шигырьләр. – Казан: «Идел-пресс» нәшр., 2003. – Б. 53–54.
9. Шәүкәт Гаделша. Син генә // Яңарыш.– 2004.– № 6 (1153), 6 февраль. – Б. 1.
10. Шәүкәт Гаделша. Син генә // Шәһри Казан.– 2004. – Март.
11. Шәүкәт Гаделша. Син генә // Чоңгыл: Шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.– 160 б. – Б. 88.
12. Шәүкәт Гаделша. Син генә // О времени и о себе…: Страницы жизни, творчества и научной деятельности / Х.Ч. Алишина. – Тюмень: Типография «Печатник», 2007.– 56 с. – С. 24.
13. Шәүкәт Гаделша. И Мөдәррис әкә! // Чоңгыл: Шигырьләр / Шәүкәт Гаделша. – Казан: Татар. Кит. Нәшр., 2006. – Б. 62.

## ШАУКАТ ГАДЕЛЬША В ЭНЦИКЛОПЕДИЯХ, СПРАВОЧНИКАХ, УЧЕБНЫХ ПОСОБИЯХ

1. Хабибуллина Л.Б. Туган як әдәбияты = Литература родного края: учеб. пособие для учащихся 5–11 кл. на татар. яз. В 2 ч. / Л. Б. Хабибуллина; науч. ред. Х. Ч. Алишина. – Тюмень: Изд–во ТюмГУ, 2002.– 43–49 б.
2. Сәйфуллина Ф.С. Төмән өлкәсе татар әдәбияты. – Тубыл: Тубыл дәүләт пед. институты нәшр., 2004.– 9–21 б.
3. Татары земли сибирской (Тюменская область). Словник / Автор-составитель Х.Ч. Алишина. – Казань: Магариф, 2005. – С. 55.
4. Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Дүртенче китап = Писатели нашего детства: Библиографический справочник. Книга четвертая. – Казан: Мәгариф, 2008.– 255 б.
5. Сборник программ и методических пособий для школ Тюменского региона с этнокультурным компонентом образования / составители К.С. Садыков, Ф.С. Сайфулина, М.С. Хасанова. – Тобольск: Тобольская государственная социально-педагогическая академия им. Д.И. Менделеева, 2009.– 187 с.
6. Татарская энциклопедия: в 6 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, ответ. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2010. – Т. 5: Р-С-Т.– 736 с. – С. 312.
7. Хабибуллина Л.Б. Туган як әдәбияты (Литература родного края): учебное пособие для учащихся 5–11 классов / на тат. Яз. / под ред. Х.Ч. Алишиной. 2-е изд., доп. и перераб. – Тюмень: Типография «Печатник», 2015. – С. 329–338.

**СОДЕРЖАНИЕ**

Предисловие ........ 3

Биография ........ 6

О себе ........ 11

Материалы о творчестве поэта, впечатления, воспоминания, рецензии, опубликованные на татарском языке в периодической печати и книгах ........ 12

Материалы о творчестве поэта, опубликованные в научных изданиях ........ 93

Публицистика Шауката Гадельши ........ 150

Переводы стихов Шауката Гадельши на русский язык ........ 152

Цитаты о творчестве Шауката Гадельши ........ 155


Стихи, посвященные Шаукату Гадельше ........ 157


Стихи Шауката Гадельши, посвященные друзьям и землякам ........ 162

Библиография ........ 170

# КНИГИ ШАУКАТА ГАДЕЛЬШИ




















**В тюменском издательстве «Печатник» увидели свет следующие книги серии «Жизнь замечательных людей» (Күренекле шәхесләр):**

**Азат Сагитов** – первый редактор областной татарской газеты «Янарыш» / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2011. –75 с. – (Жизнь замечательных людей).

**Диляра Тумашева** – выдающийся тюрколог XX столетия : ст., воспоминания / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2011. – 73 с. – (Жизнь замечательных людей).

**Люция Хабибуллина** – первый исследователь истории школ и литературы сибирских татар / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2011. –186, [12] с. – (Жизнь замечательных людей).

**Рашида Бакиева** – заслуженный учитель школы Российской Федерации / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : [Янарыш], 2012. – 72, [2] с. – (Жизнь замечательных людей).

**Фаузия Бикшанова** – ветеран нефтегазового комплекса Западной Сибири / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2012. – 29, [3] с. – (Жизнь замечательных людей).

**Амир Юскаев** – сельский корреспондент газеты «Янарыш» / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень: Печатник, 2013. – 103 с. – (Жизнь замечательных людей).

**Булат Сулейманов** – основоположник литературы сибирских татар / авт.–сост. Х.Ч. Алишина, Г.Н. Ахметова. – Тюмень : Печатник, 2013. – 119, [3] с. – (Жизнь замечательных людей).

**Хамит Ярми** – доктор филологических наук, первый татарский ученый-фольклорист / авт.–сост. Х. Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2014. – 64, [3] с. – (Жизнь замечательных людей).

**Клим Садыков** – педагог, учёный, общественный деятель. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография “Печатник”, 2015. – 176 с.

**Ришад Зиганшин** – депутат, руководитель, общественный деятель. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография “Печатник”, 2015. – 85 с.

**Эрнест Валеев** – государственный советник юстиции 1 класса, генерал-полковник, депутат Государственной Думы Федерального Собрания РФ. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель, редактор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2016. – 123 с.

**Сагит Сагитов** – поэт, общественный деятель, Почетный работник газовой промышленности. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Авторы-составители Алишина Х.Ч., Валишина Г.И. – Тюмень: типография "Печатник", 2017. – 132 с.

**Хамит Неатбаков** – Герой Советского Союза. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель, редактор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2017. – 86 с.

**Юрий Конев** – доктор социологических наук, профессор, народный депутат. Жизнь замечательных людей. Автор-составитель – д.ф.н., профессор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2017. – 172 с.

**Гали Шарафутдинов** – педагог, директор школы, ветеран труда, общественный деятель. Жизнь замечательных людей. (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2017. – 150 с.

**Люция Хабибуллина** – выдающийся деятель татарской культуры и образования, заслуженный педагог, ветеран войны и труда Жизнь замечательных людей (Куренекле шэхеслэр). Автор–составитель Х.Ч. Алишина. – Тюмень : Печатник, 2018. –194 с.

**Булат Сулейманов и его наследие в отечественной культуре** (Жизнь замечательных людей. Күренекле шәхесләр). Автор-составитель, редактор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2019. – 456 с.

**Айдер Меметов** – выдающийся сын крымскотатарского народа (Жизнь замечательных людей. Күренекле шәхесләр). Автор-составитель, редактор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2019. – 153 с.

**Тимир Карманов** – видный педагог Ярковского района, ветеран Великой Отечественной войны. Жизнь замечательных людей (Күренекле шәхесләр). Автор-составитель, редактор Алишина Х.Ч. – Тюмень: типография "Печатник", 2019. – 150 с.

ЖИЗНЬ ЗАМЕЧАТЕЛЬНЫХ ЛЮДЕЙ
КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР

# ШӘҮКӘТ ГАДЕЛША

**Ответственный редактор**
Доктор филологических наук профессор **Х.Ч. Алишина**

**Составители** – Х.Ч. Алишина, М.Ш. Сибгатуллина
**Корректор** – Х.Ч. Алишина
**Технический редактор** – С.Б. Корженевский
**Компьютерный дизайн и верстка** – С.И. Ходырев

Сдано в набор 29.08.2019 Подписано в печать 20.09.2019
Формат 60х84/16 Усл. печ. л. 11.5 Печать офсетная.
Гарнитура: Times New Roman
Тираж 200 экз. Заказ № 1609

Отпечатано в типографии «Печатник»
Тюмень, ул. Республики, 148, корп. 1/2.
Тел. (3452) 20-51-13, тел./факс (3452) 32-13-86